PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2016 АПРЕЛЬ № 4

Сөембикә

ISSN 0869-1398

ИЛНЕҢ БАШ ЯУЧЫСЫ
ир-ат ягы – сатып алучы

ҖАННАН САРКЫЛГАН МОҢ
шагыйрь мәхәббәте

ДИЛӘ НИГЪМӘТУЛЛИНА СЫЙЛЫЙ:
наршәраблы куырма



Эльмира ВАСИЛЬЕВА:

«КЫЕНЛЫКЛАР БЕЗНЕ ЧЫНЫКТЫРА ГЫНА...»

PRESSA.RU



БЕРГӘ ЧАКТА... Бу мизгелләр күп тә түгелдер, бәлки — атналарны тыгызлаган бетмәс-төкәнмәс эш, мәшәкать ыгы-зыгысында гаилә белән үткәргән бәхетле минутлар һаман сирәгәя, кыскара барадыр. Әмма аларның һәрберсе кадерле, һәркайсы безгә тормышның ямен-тәмен тоеп яшәрлек көч, җан җылысы бирәдер. Бу тансык вакытны һәркем үзенчә үткәрә – алар мәгънәле, күңелле, онытылмас якты булсын өчен әллә ни кирәкми дә кебек...

МИНЕМ ГАИЛӘМ – МИНЕМ ДӘҮЛӘТЕМ





Сәфәровлар гаиләсе

Казан

Соңгы вакытта тормыштан зарлану, гаеплеләргә төртеп күрсәтү кебек чирнең баш калкытуы күзәтелә башлады. Әлбәттә, бөтен дөньясы акчага корылган заманда һәркемнең дә яхшырак яшисе, зуррак уңышларга ирешәсе – кыскасы, бәхетле буласы киләдер. Ләкин тормыш тәҗрибәсен җитәрлек туплаганнар белә – бәхет өчен еш кына бөтенләй икенче кыйммәтләр кирәк икән бит. Андый кыйммәтләр бүгенге җәмгыятьтә тиешенчә бәяләнмәскә яки бөтенләй булмаска да мөмкин. Алар бары тик син яшәгән тирәлектә, нәселдә яки гаиләдә генә сакланып калырга мөмкин. Бөтен гаилә белән бергәләп пешерә торган кияү пәрәмәче, мәсәлән, безнең нәсел өчен шундый кыйммәтләрнең берсе. Әбигә аны пешерергә кайнанасы Мөхмүзә әбекәй өйрәткән. Әби үз чиратында безне өйрәтте, без – кызларыбызны... Ул көнне безнең гаиләдә әйтеп аңлатып булмаслык бердәмлек хөкем сөрә. Әби-бабайдан алып кечкенә оныкларга кадәр катнашкан күңелле мәшәкать гаиләне тагын да татурак, бер бөтенрәк итә. Тормыш менә шундый бәхетле мизгелләрдән торганда гына кеше үзен бәхетле саный аладыр ул.















Ә сез БЕРГӘ ЧАКТА ниләр эшлисез, сезнең гаиләне нинди эш-гамәлләр, үзенчәлекле бәйрәмнәр, берәүдә дә кабатланмый торган, әмма башкаларга да үрнәк булырдай матур йолалар берләштерә? Яңа фотопроектыбыз шундый мизгелләрне яктыртуга багышланган.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2016

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Директор-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Директор урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррире:
Сөмбел Гаффарова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Эльмира Васильева
Фото: Ксения Богданова

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 7.04.2016 ел.
Заказ М-895.
Тираж 6860.

Учредитель:
Акционерное общество «ТАТМЕДИА»



ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы: 73002

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в АИКБ «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002



PRESSA.RU



Р. Килдебәков. «Тукайның мәхәббәт лирикасы битләреннән».



ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА – 130 ЕЛ

Габдулла ТУКАЙ

Булмаса


Кем белер кадреңне, җаным,
дәртле күңел булмаса?
Наз итәр кемнәргә гөл – каршында былбыл
булмаса?

Сурәтеңнең иң чыны, бел: шагыйрьнең
күңлендәдер;
Көзгеләрдән чын төсеңне күрмисең –
ул булмаса.

Бирмәде Ләйлә кеби мәхбубәгә дөнья бәһа;
Ул болай бер кыз гына – каршында
Мәҗнүн булмаса.

Һич килештермим синең төсле
гүзәллек шаһына,
Ичмасам, бер хисле шагыйрь дә килеп
кол булмаса.

PRESSA.RU





БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА





24

АЛТЫ АВЫЛНЫҢ АЛТЫНЫ
Э. Закирова

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ





8

ХАТЫН-КЫЗНЫҢ ӨЧ КӨЗГЕСЕ
Л. Әбүдәрова



20


БУЛДЫРАСЫҢ, МАРИЯ!
М. Авзалова



16

КӨТЕЛГӘН БҮЛӘК
К. Идрисова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ



28

ЕГЕТЛӘРЧӘ!
Л. Кәшфиева

30

ТАТАР КЫЗЫ СЫНАТМАС!
Й. Шәрапова

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



40 **БАДАХШАН КЫЗЫ**
А. Юнысова

ЯШӘЕШ 



50 **«ШАГЫЙРЬ МӘХӘББӘТЕ»**
ОПЕРА ТАРИХЫ
Э. Закирова



52 **ШОМЫРТ ЧӘЧӘГЕ АК КЫНА**
Р. Хәмитова

ШУЛАЙ УК: 

12 **ИШЛЕ БАЛА**
Г. Сафиуллина

46 **ҺӘР ГАМӘЛНЕҢ ҮЗ СӘГАТЕ**
Н. Төхбәтуллина

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 



58 **ИЗҮЛӘРЕМ ЧИГҮЛЕ**

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА: 

КЫЙНЫЙ, ДИМӘК, ЯРАТА?!
Чаң сугабыз

МИН ЯЗМЫШНЫ ҖИҢДЕМ!
Булган хәл

РОЗА МУЛЛАНУРОВА «МИЛӘШ КАГЫ»
Хикәя

«АКЧАРЛАКЛАР»
Бер җыр тарихы

ЯШЬ ҖЫРЧЫ РАМИЛ ЗАКИРОВ
Мастер-класс. Ризотто



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



Һәрберебезнең дә күңел түрендә якты истәлек булып кала торган гүзәл мизгелләр була. Минем өчен онытылмас мизгелләр мәктәп еллары́м, яраткан укытучым, җиде ел буена сыйныф җитәкчем булган Венера Вәли кызы Бикмөхәммәтова белән бәйле.

Укытучы дисәң дә, укытучы иде ул. Көләч йөзле, йомшак күңелле, һәр укучысы өчен җан атып тора торган чын укытучы. Без Апас районы Иске Йомралы урта мәктәбендә төрле авыл балалары бергә җыелып укыдык. Дәресләр беткәч, һәрберебезне хәерле юл теләп озатып кала, иртә белән кабат барлап, елмаеп каршы ала иде Венера апа. Карлы-буранлы, яңгырлы-җилле көннәрдә безне – читтән килеп укучыларны үзләренә алып чыгып чәйләр эчертә. Икенче сменада укыганда, бик караңгыга кала торган булсак, йокларга да алып кала. Әти-әниләр борчылмасын дип, аларга хәбәр итү җаен да таба.

Укучыларны байга-ярлыга, яхшысына-начарына бүлмичә, барыбызны да тигез күрде Венера апа. Класс сәгатьләрендә аның безгә биргән сабаклары, кызыклы әңгәмәләре һаман да истә. Бәйрәмнәр җитсә, дәрестән соң калып, чәй эчүләр оештыра иде. Шул рәвешле төрле авыл балаларын үзара дуслаштырган бит ул. Мәктәптә узган кичәләргә чыгышлар әзерләүләребез кызык булып истә калган. Венера апа безгә төрле халык биюләрен өйрәтә иде. Бер бәйрәмдә сигез кыз украин халык биюен биисе иттек. Венера апа белән башта бик яхшылап өйрәндек. Бию матур килеп чыксын өчен аның бит әле киеме дә мөһим. Район үзәгенә барып, барыбызга да җитәрлек тукымалар сатып алдык. Пардан итәкләр, алъяпкычлар тектек. Төсле тасмалардан такыя ясадык. Бик матур килеп чыккан иде ул чыгышыбыз. Ә берсендә Иван Крыловның «Чикерткә белән кырмыска» мәсәлен сәхнәләштердек. Расихыбызны – кырмыска, Әлфияне чикерткә иттек. Аңа бик матур канатлар ясап тактык. Әй күңелле чаклар диген!

Венера апа безне рус теле һәм әдәбиятыннан укытты. Аның дәресләре безгә бер бәйрәм кебек була торган иде. Ул Пушкин, Лермонтов, Грибоедов әсәрләрен шулкадәр җаннарга үткәреп сөйли – үзеннән-үзе хәтергә сеңеп кала. Икенче дәрестә инде син аны кабат укымыйча да сөйләп бирәсең. Бик аңлаешлы, гади итеп бирә белә иде ул дәресләрне. Шулай булмаса, аның егермеләп укучысы рус теле һәм әдәбияты укытучысы һөнәрен сайламас иде. Алар әле дә Венера апа белән аралашып, киңәшләшеп яши. Аллага шөкер, Венера апаның бу фидакарь хезмәте үз бәһасен тапты. Бүгенге көндә аның Хезмәт ветераны, «Россиянең мәгариф отличнигы» дигән мактаулы исемнәре бар. Казанның меңьеллыгы уңаеннан медаль белән дә бүләкләделәр үзен. Узган елның 21 октябрендә яраткан укытучыбызга 70 яшь тулды. Арча районы Мәмсә авылында туып-үскән ул. Дүрт яшьлек чагында әтисе үлеп киткән, 10 яшендә әнисез дә калган. Ятим кызны әнисенең сеңлесе үстергән. Үзбәкстан якларына кияүгә чыккач та, Венера апаны үзеннән калдырмаган ул. Венера апа Үргәнеч шәһәрендә укып белем алган. Аннары әнисенең васыятен тотып, Арча педагогика көллиятенә укырга кайткан.

Сабый чакның бер хатирәсен кызык итеп безгә дә сөйләгәне истә: кечкенә вакытта үз авыллары аша узып баручы рус апаларына ияреп, юл буе аларның сөйләшкәнен тыңлап барган да, өйгә кайткач, әнисенә әйтә икән: «Алар берберләрен ничек аңлый икән соң? Мин бер нәрсә дә аңламадым». Әнисе исә елмаеп тыңлап торган да: «Кызым, алар бит русча сөйләшәләр», – дип аңлаткан. Менә шул кызның киләчәктә үзе үк балаларга рус теле укытачагы берәүнең дә башына килмәгәндер.

Училищеда укыганда Венера апа Альфред абый белән таныша. Соңгы курста укыганда гаилә кора алар. Бер-бер артлы ике уллары туа. Укытучылар гаиләсен 1967 елда Апас районының Иске Йомралы мәктәбенә эшкә билгелиләр. Венера апа, әйткәнемчә, рус теле, Альфред абый физика укытты. Бер туган-тумачасы да булмаган авылда тормышны өр-яңадан башлавы кыен булгандыр инде, билгеле. «Йомралы халкына чиксез рәхмәтлемен», – ди Венера апа үзе. Бүгенге көндә алар Казан шәһәренең Аракчино бистәсендә уллары Руслан гаиләсе белән яши. Бергә яши торган киленнәре дә Йомралы авылы кызы. Күптән түгел генә Венера апаның янына барып, хәлен белешеп кайттым. Минем шәфкать туташы һөнәрен сайлавыма әле дә булса шаккатa укытучым: «Классыгыздагы иң куркак кыз идең бит син, ничек бу һөнәрне сайларга батырлыгың җитте?» – ди.

Узган ел сыйныфташлар белән очрашу уздырган идек. Очрашуга Венера апабызны да чакырдык. Аның янында без әле һаман да бала икән. Барыбыз белән дә кызыксынып, гаиләләребезне, кайларда, кемнәр булып эшләүләребезне сорашты. Кайчандыр бәп-бәләкәй балалар булган укучыларының кайсы мәктәп директоры, кайсы шәфкать туташы, ә иң мөһиме – барыбызның да тормышта үз бәхетебезне таба алуыбызга куанычы йөзенә чыккан иде. Менә шундый ул безнең Венера апабыз! Йөрәгендә һәрбер укучысына урын җитәрлек аның.

Алинә САБИРОВА.
Казан.



Әнинең кадерен сигез сыйныфны тәмамлап, Казанга укырга киткәч кенә белдем. Өйне, әти-әнине сагынуым шундый көчле була иде – атна ахырын көтеп кенә торам да, авылга чабам.

Ул вакытларда авыл клублары гөрләп тора. Яшьләр күп, барыбыз да бертөсле, бер иш. Клубта кино күрсәтәләр, спектакль-концертлар да еш булып тора. Яшьтәшләремнән аерылып, кире Казанга китү бер газапка әверелә. Казанда ике-өч ел яшәгәннән соң, мин кабат авылга кайтырга булдым. Чөнки анда рәхәт. Анда – әти-әни. Анда – бергә уйнап үскән дуслар. Колхозга эшкә урнаштым. Әни ул вакытларда авылда сөт җыя иде. Бергә эшләп, әр-яңа газ плитәсе алып куйдык. Шулай эшләп йөргән җирдән мине кабат Казанга – баянчылар курсына укырга җибәрделәр. Өйдәгеләр матур гына озатып калды. Шулай да тыныч күңел белән китү түгел иде бу – әни сырхаулап тора. Бармыйча да булмый. Казанга килсәм, әле укулар башланмаган. Монда бушка вакыт уздырганчы, дип уйладым да бер-ике көнгә кире авылга кайтып килергә булдым. Юл уңае Сабадагы Кәримә апаларга кереп чыгасы иттем. Аларда бер кич кунып, иртән үзебезгә кузгалдым. Күрше Норма авылында танышыбыз очрап, әнинең хәлен сорады. «Әнигә ни булган?» – дим аптырап. Ул күп сөйләшеп тормады, тиз генә китү җаен карады. Авылга кайтып җиткәч, укытучы Лиза апа очрады. «Әниеңне паралич суккан, Балтачка алып киттеләр», – дип аяктан егарлык хәбәр ирештерде ул. Өйгә кереп кенә чыктым да тизрәк Балтачка чаптым. Мин килгәндә әни беркемне дә танымый иде инде. «Әни, мин кайттым», – дигәч, мине таныгандай, кул изәде. Соңгы ишарәсе иде ул аның. Шулай итеп, кырык өч яшьлек әни безне калдырып китеп тә барды. Без, биш бала, әти, әби белән ятим калдык. Кечкенә энебез Мулланурга ул вакытта сигез яшь кенә иде әле. Әнине соңгы юлга алып чыгып киткәндә уенчыклары белән уйнап калды. Бәлки, ул шулай итеп үзенең сабый күңелен юаткандыр. Фалиянур сеңлемнең: «Әнине алып китмәгез! Әнине калдырыгыз!» – дип, ачыргаланып елаганы исемә төшсә, әле дә йөрәгем телгәләнә. Фәнис энем дә төне буе абзарда елап чыкты ул көнне. Әтиебез Әнәс бу хәсрәтне ничек күтәргәндер инде, бичаракаем? Өстәвенә, шушы хәлләрдән соң әтинең әнисе – Фәризә әбиебез дә авырып китте. Башка туганнары аны үзләренә алып китеп тәрбияләргә теләсә дә, әти әбине бирәүгә дә бирмәде.

Әнидән калганга кырык елдан артык вакыт үткән. Үзе киткәч, никтер өйдән берәм-берәм аның фотолары да юкка чыкты. Төрле туганнардан эзләп карасам да, әнинең бер генә фотосын да таба алмадым. Бердәнбер сурәте – кабер ташына кайчандыр үзем ясаган рәсеме генә. Аптырагач, әнине күз алдыма китерергә тырышып, тагын бер рәсемен ясап карадым. Охшаган да кебек, охшамаган да... Бик сагынганда: «Их, бер генә тапкыр рәсемеңә карасамчы», – ди идем. Бәхет һич уйламаганда елмайды. Үзбәкстаннан күчеп кайткан туганнарыбыз табып бирде әнинең яшь чакта төшкән рәсемен. Аны яңадан күргән кебек булдым. Нәкъ үзе бит! Шатлыгымның иге-чиге булмады. «Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең каберең ташы» дигән юллары өчен Тукайга гомерем буе рәхмәт укыйм. Минем өчен махсус язылгандыр шикелле тоела бу юллар миңа. Моннан да яхшырак итеп әйтеп була микән?

Әни, әни... Еллар узган саен әнинең никадәр миһербанлы, кешелекле, сабыр булуын аңлый барам. Ул бик матур итеп җырлый торган иде. Кечкенә вакытта берәр мәҗлестә әнине җырлатсалар, кычкырып елый идем. Әнине шул вакытта ук беркем белән дә бүлешәсем, берәүгә ди бирәсем килми, ул бик-бик кадерле иде. «Әниеңнең җырлаганы Нормабаштан әллә кайларга ишетелеп тора иде», – дип әйтә иде әти. Нормабаш – әнинең туган авылы. Аның кешеләре дә бертөрле көйләп, моңлы итеп сөйләшәләр. Урман эченә кереп диярлек урнашкан бик матур авыл ул.

Әни вафат булгач, тормышның бөтен кызыгы бетте. Кайбер туганнар да бездән читләште. Әни исән булса, безнең язмышлар бөтенләй башка эздән киткән булыр иде. Соңгы елларын әти дә Казанга килеп яшәде. «Вафат булсам, зинһар, әниегез янына алып кайтып күмегез», – ди торган иде. Аллага шөкер, әтинең бу васыятен үти алдык, әни янына – Чапшар зиратына алып кайтып җирләдек. Урыннары оҗмахта булсын!

Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН.
Балтач районы, Балтач авылы.
Рәсемдә: әнием Рәфисәгә 19 яшь. 1953 ел.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU



Баш яучы! Роза СӘБИТОВАның Беренче каналдагы имиджы шундый! Милли театрлар тамашаларында күреп өйрәнгән яучы-карчыкларга һич тә охшамаган ул. Бәби итәкле озын күлмәген биленә кыстыра төшеп, ыштан балагының сыңарын читек кунычына тыгып, кәләш өенә бик тә «изге эшләр» белән атлап керә торган әбекәй итеп истә калдыргангбыз. Ә бу – замана яучысы. Роза Сәбитова зәвыклы һәм заманча итеп киенгән. Холык-фигыле дә шикәр түгел бугай. Чыннан да, ханым гадәти экран йолдызларыннан нык аерыла. Туры сүзе, җор теле һәм «яучылыгын» онытмавы белән. Роза Рәиф кызы белән нәкъ менә безнең заман яучысының хасияте һәм башка күп нәрсәләр турында сөйләшәбез дә инде.



Ландыш ӘБҮДӘРОВА

ХАТЫН-КЫЗНЫҢ ӨЧ КӨЗГЕСЕ

«Яучы – арадашчы ул»

Роза Рәифовна, Сез – илнең баш яучысы. Без татарларда яучылар, уйнап әйткәндә, элек-электән кызларның «башын ашаганнар», ә чын мәгънәсендә исә язмыш җирәбәсен сайлап биргәннәр. Ә бүгенге көндә яучы кем ул?

– Беренчедән, яучы «әбекәй»нең яшен ачыклыйк. Аңа 40 яшьләр тирәсе булган. Ул ниндирәк кыяфәтле булган? Элек заманда хатын-кызлар иртә картайган, ә безнең заманда 40 яшьлек хатынга әби дип әйтеп кара син! Тагын бер мөһим деталь: яучы кияүдә булмаска тиеш. Кагыйдә буларак, алар – тол. Хәзер дә безнең кәсепнең бу төп шарты булып тора. Ни өчен икәне аңлашыла да: хатын-кызның вазыйфалары бик күп – йорт, ир, балалар, һәм болар бик күп вакыт һәм көч таләп итә.

Хәзерге заманда яучының, әлбәттә, психолог белеме булырга тиеш. Бу – шулай ук мөһим шарт.

Икенчедән, элеккедән килгән алыш-биреш атрибутикасы кала. Димәк, үзара товар-сатып алучы мөнәсәбәтләре урнаша. Димәк, яучы реклама һәм пиар остасы булырга: үзе «саткан» товарны белергә һәм аны дөрес итеп рекламаларга тиеш. Замана безгә мәгълүмат тапшыру өлкәсендә яңа технологияләр тәкъдим итә – димәк, интернет һәм компьютер өлкәсеннән дә белемнәр таләп ителә. Бөтен база электрон версиядә саклана. Кешеләр төрле шәһәрләрдә яшиләр, һәм бу безнең заманда клиент өчен комачау була алмый. Хәтта скайп аша консультацияләр бирергә мөмкин.

Яучыга еш мөрәҗәгать итәләрме? Бүген ул ни дәрәҗәдә кирәкле һөнәр?

– Ул һәрвакыт кирәк булган һәм булачак. Беләсезме, ул кер юучылар кебек. Сез керегезне үзегез юа аласыз һәм аның чисталыгы өчен җаваплылыкны үз өстегезгә аласыз. Шул ук вакытта бу эшне профессионалларга тапшырырга да мөмкин: алар сезгә керегезне юып, төреп бирәләр. Бу – беренче. Икенчедән, шул ук товар-сатып алучы аналогиясе. Яучы – арадашчы ул. Хатын-кызга үзе башлап йөрү килешми, бу «сатып алучы» – ир-ат тарафыннан бәйләнчеклек булып кабул ителергә мөмкин. Кыз кеше үзен-үзе мактый алмый, чөнки бу тыйнаксызлык санала. Хикмәт яучының ни дрәҗәдә оста булуында – ул ир-атлар, хатын-кызлар психологиясен белергә, җенесләр арасындагы мөнәсәбәтләрдән, ялгызлык проблемаларыннан хәбәрдар булырга тиеш. Үзенә күрә маркетинг төре бу.

Эш шунда ки, яучыга хатын-кызлар ешрак мөрәҗәгать итә. Гәрчә, чынлыкта, ир-атлар күбрәк шалтырата. Әмма ир-атның фәлсәфәсе шундый бит ул: аңа хәзер үк булсын. Ә инде эш анкеталар тутыруга, консультацияләргә килеп терәлгәч, теләк сүнә.
Ул иртән тора, аның командировкага барасы бар, башка хатын-кыз белән таныша һәм башкасы. Статистика буенча (ә мин ул статистиканы алып барам) башка агентлыкларда 90 процент хатын-кызлар, 10 процент ир-атлар, миндә исә 65 процент хатын-кызга 35 процент ир-ат туры килә. Танылу өчен барысын да эшлим, шуның аркасында эш даирәм дә бик киң. Беренче белемем буенча мин системалар программисты. Икенчесе – психология буенча.

«Гаиләле тормышка йөз тотып»

«Давай поженимся» тапшыруында Сез берничә тапкыр: «Ә менә татар кызлары...» дип кабатлаганыгыз булды. Ничек уйлыйсыз, татар кызларына гына хас булган сыйфатлар чыннан да бармы?

– Мин үзем – татар кызы. Әзәрбайҗан милләтеннән булсам, әзәрбайҗан кызлары, дияр идем. «Татар» дигәндә, мин шәрык кызларын күздә тотам. Бездә көнчыгыш тәрбиясе геннардан килә. Үземнең кызымның тәрбиясеннән чыгып фикер йөртә алам. Ул әти-әни йортында тәрбияләнгәндә, аның өчен гыйффәтлелек һәм сафлык үзеннән-үзе билгеле төшенчәләр иде. Кияүгә дә ул гыйффәтле булып чыкты. Безнең өчен бу беркайчан да ябык, интим характердагы тема булмады. Ул үзенең хатын-кыз икәнен, хатын булгач, иренә хезмәт итәргә тиешлеген белеп тәрбияләнде. Болар барысы да аның холык сыйфатына салынды. Бу дөрес тәрбия, һәм чагыштыру өчен үземнең тәҗрибәм җитәрлек. Минем Казанда агентлыгым бар иде, ягъни мин бу мәсьәләнең кухнясын эчтән беләм, шулай ук бик күп гыйффәтле кызларны да беләм. Сафлыгын саклаган кызларның кияүгә чыккач яхшы хатын булырына ялгышмый идем. Әлбәттә, Мәскәүдә яшәүче, Европача тәрбия алган кыз бала дөрес тәрбияле шәрык кызыннан аерыла. Ләкин барысы да тәрбиядән тора, җирлектән түгел. Минем кызым да Мәскәүдә туып-үсте. Әмма туганнан бирле алган ата-ана тәрбиясе аның киләчәк тормышын билгеләде. Йомгаклап әйткәндә, дөрес гореф-гадәтләр нигезендә дөрес ата-ананың дөрес тәрбиясен алган татар кызлары бары тик гаиләле тормышка йөз тота.

Яучылык, асылда, үзгәрми: хатын-кыз үзен кәләш, ягъни товар буларак тәкъдим итә. Ир-ат ягы хатын ала, шуңа да ул сатып алучы.

Татар хатын-кызларын тыйнаклык бизи, диләр...

– Татар хатыннары турында шундый бер мәзәк бар. Имеш, син татар хатыны белән яшәгәнсең икән, сиңа хәтта җәннәт тә җәһәннәм булып тоелачак. Мин, шул исәптән 12 китап авторы, язучы буларак та әйтәм моны. Тыйнаклыкның нинди турында сүз бара бит? Ата-бабалардан калган традицияләр нигезендә тәрбияләнгән, тыйнак, гыйффәтле татар кызы кияүгә чыкканчы үзен дөрес, матур итеп тота, чөнки белә (бу аның канына сеңгән): ир-ат, күрәләтә торып ертлач, дорфа хатынга өйләнмәячәк. Кыяфәте белән үк «Мин – хан кызы, ә син – чүп» дип кычкырып торган кызны кем алсын? Менә кияүгә чыккач башлана да инде... Анда тыйнакла-

PRESSA.RU

нып торып булмый. Минем әбием – татар хатыны, 50 ел Мәскәүдә яшәде, махсус рәвештә русча сөйләшми иде. «Әбием, нигә русча сөйләшмисең?» – дигәч, «Тел онытыла», – дип җавап бирә иде. Чыннан да, әбиебез мәрхүм булды, тел дә онытыла башлады. Кирәк вакытта ул тыйнак була белә иде. Ә өйдә, гафу итегез, өйдә ул хуҗабикә, ул барыбызны да тотып тора, ул – баш. Гадәттә, көчле, үз сүзен кистереп әйтә, сүз эзләп кесәгә керми торган бабабыз да өйгә кайтып керүгә ефәк кебек булып кала иде. Чөнки белә: монда әби хуҗа. Татар кызлары ир-атларны тота белергә кирәк икәнен яхшы аңлый. Әбием һәрвакыт кабатлый иде: «Ирсез яшәп булмый, ләкин алар белән дә җиңел түгел, идеал юк. Шуңа да гаилә ныклы булсын дисәң, тыйнакланып утырып кына булмый».

Кәләш үзен тәкъдим итәргә тиеш түгел. Димәк, моны аның өчен кемдер эшләргә тиеш.

«Кияүгә чыгу мәҗбүри»

Ир-атлар һәм хатын-кызлар арасындагы мөнәсәбәтләр өлкәсендә белгеч буларак, кызлар үзләренә гомер юлдашы сайлаганда нindирәк хата җибәрә? Еш очрый торганнарын атап китә аласызмы?

– Төп ике хата. Без ни генә дисәк тә, ир-атлар җәмгыятендә яшибез. Ир-ат – баш, Россия гаиләләрендә бернинди демократия, партнерлык турында сүз була алмый. Татарларда бигрәк тә. Әгәр ир-ат – баш, ә хатын аңа иярә икән, димәк, ул аңа хезмәт итә. Партнерлык, демократия турында хыялланган кызлар белән, гадәттә, тиз «саубуллашалар». Гаилә килеп чыкмаячак аның белән. Ир-атның йөрәгенә иң кыска юл аның эгосы аша ята. Ир-ат – иң-иңе. Гомер буе аның колагына «син – иң-иң әйбәте», дип пышылдап торырга кирәк. Бу – Көнчыгыштан килгән зирәклек: соңгы сүзне һәрвакыт ир-ат әйтергә тиеш, һәм бу сүз «әйе, кадерлем» булырга тиеш. Ир-ат «әйе, кадерлем» дисен өчен, хатын-кыз укымышлы, тәрбияле һәм башлы булырга тиеш.
Бу – нигез ташы.

Һәм тагын бер мөһим нәрсә бар. Кызлар, исегездә тотыгыз: кияүгә чыгу мәҗбүри, әмма кияүдә булу бик катлаулы эш. Шуңа да кайнанагызны яратыгыз, аның белән дус булыгыз, чөнки ул үзенең улын ярата, һәм сез үз әти-әниегезгә караганда да кайнанагызга якынрак булырга тиеш. Акыллы кайнана сезне улын дөрес яратырга өйрәтәчәк, чөнки аңа үзе юкта улының ышанычлы кулларга калачагын белергә кирәк. Бу да нигез ташы. Исегездә тотыгыз: хатын хезмәт итә, кайнана әнидән өстенрәк.

Боларны миңа әбием өйрәтте, гәрчә ул укымаган булса да. Безнең әбиләргә психолог булырга да кирәкмәгән, алар тормыш итүдә үзеннән-үзе зирәк, акыллы булган, артыгын алмаганнар да. Беренче каналда да, үземнең һөнәри эшчәнлегемдә дә мин шушылар белән шөгыльләнәм: туйдан соң яшәргә җиңелрәк булсын дип тырышам.

Безнең заманда еш очрый торган картина: кияүдә булмаган кыз, үзе укымышлы, менә дигән эше, соклангыч карьерасы бар. Һәм менә аңа кияүгә чыгарга тәкъдим ясыйлар. Кызга нишләргә: кияүгә чыгып, алдагы берничә елда карьера турында онытырга, хуҗабикә булып яшәргәме, әллә кияүгә чыгудан баш тартыргамы? Сез нинди киңәш бирер идегез?

– Беренчедән, ир-ат хатынга өйләнә. Һәм хатынының акчасы аңа әллә ни кирәк түгел. Бу җәһәттән миңа Лариса Гузееваның мисалы ошый. Ире аңа болай дигән: «Әгәр иҗат белән шөгыльләнәсең килә икән, барысына да өлгер. Чөнки мин өйгә кайтканда, син дә өйдә булырга тиеш. Өлгермисең икән, өйдә утыр». Ләкин белем алу һәм яхшы эшле булу – иминлек мендәре ул. Әбием гел шулай дип әйтә иде: «Роза, исеңдә тот, беркайчан да яхшы да, начар да булма. Барыбер ике начарлыкның кечерәген сайлаячаксың». Менә шушында башны эшләтергә кирәк инде. Ир-атлар җәмгыятендә һәрвакытта да хатын-кызның өч үлчәме үзәктә тора: хатын-кыз, ир хатыны һәм әни. Ир хатыны булу ул – совет чорында Советлар Союзы Герое исемен алуга тиң – бик мактаулы халәт. Шуңа да сайлау алдында каласың икән, әлбәттә, бер генә юл: кияүгә чык! Әлбәттә, гаилә! Чөнки бары тик ирегез янәшәсендә генә сез хатын-кыз була аласыз, бары тик ирегез генә сезгә ир хатыны дигән статусны, ана булу бәхетен бирәчәк.

Картлык көннәрен сез эштә үткәрәчәксезме, әллә ирегез, балаларыгыз, оныкларыгыз янәшәсендәме? Монда сайлау мөмкинлеге юк та. Мин кызыма һәрвакыт шуны әйтәм: «Өч бала тап», чөнки, кагыйдә буларак, күп балалы әнине ташламыйлар. Бер белән аерылалар, ике бала белән ташлап чыгып китәләр, ә менә өч белән... Анда инде уйлап торырлык вакыт та калмый – балаларны ашатасы, киендерәсе, кеше итәсе бар. Әлбәттә, үзем исән вакытта кызыма ярдәм итәчәкмен. Әни ни өчен кирәк соң?

Балалар үсә төшкәч, ярдәм итәрдәй кешең булса, карьера белән параллель рәвештә шөгыльләнергә мөмкин. Анда да карьераң гаиләңә комачауламаслык булса гына. Тик бик авыр булачак. Карьера белән гаиләне бергә алып бару хатын-кыз өчен бик авыр ул. Ярдәм юк икән, хәтта мөмкин дә түгел.

Хатын-кыз өчен тормыш көзендә ireң, балаларың һәм оныкларың мәхәббәтен тоеп яшәү – нindидер компаниянең генераль директоры булып, ялгыз гомер кичерүгә караганда күпкә мактаулырак. 50 яшьтә сезнең берәүгә дә кирәгегез калмаячак.

Мин бернәрсәне дә исбатламыйм, тормыш үзе исбатлый ул. Хәзер ул карьералы кызларга – 25, 30, 35. Ләкин озакламый 40 та булачак, 50 дә тулачак. Шул вакытта күрәбез дә инде: 25 яшендә кияүгә чыгып, балалар үстергән хатын 50 гә җиткәндә оныклар караша, һәм аның тормышының мәгънәсе бар, ул нәрсә хакына, кем хакына яшәвен белә. Ә карьераны өстен күргәннең

ни баласы, ни мәчесе юк, эт белән яшәп ята һәм миңа килә. Ә мин аңа булышмаячакмын, чөнки мин бала табу яшендәге хатын-кызлар белән генә эшлим. 35 яшькәчә. Мин алтын балык та, тылсымчы да түгел, гафу итегез, ир-атны карт кыз куенына саласым килми. Адәм белән Һава заманнарыннан бирле берни дә үзгәрмәде.

«Мин династия булдырдым»

Үзегезнең хатын-кыз бәхетенең рецепты нинди?

– Хатын-кыз бәхетенең рецепты бер генә: бу дөньяда хатын-кыз, ир хатыны һәм әни буларак яшәп калу. Мөмкин булса, күпмедер карьера кору. Әгәр мин хатын-кыз булып туганмын икән, миңа табигать тарафыннан билгеле бер юл үтү өчен программа бирелгән. Мин балаларым хакына, аларга бу тормышта үзләрен табу җиңелрәк булсын өчен танылу алдым. Асылда, яңа династиягә нигез салдым. Боларны ирем эшләгән булыр иде, кызганычка каршы, ул мәрхүм, һәм монда минем гаебем юк. Бу эшләр минем җилкәгә күчте. Иң мөһиме: бу тормышта үз юлымны лаеклы үттем.

Роза Рәифовна, Сез – һәрчак күз уңындагы кеше. Ни генә булса да, тәнкыйтьсез булмыйдыр. Аңа ничек карыйсыз?

– Бик яхшы. Фаина Раневская әйткәнчә, әгәр сине ямьсез сүзләр белән искә алмый башлаганнар икән, димәк, син инде популяр түгел. Башкаларда ниндидер эмоцияләр кузгата торган кеше популяр була. Уңаймы, тискәреме – нинди хисләр булса да. Әгәр кемнең дә булса сиңа ачуы килгән икән, димәк, аның күңеленә кагылгансың. Һәм ул орыша, тәнкыйтьләп башлый, чөнки битараф кала алмый. Ә нәрсәгә тәнкыйтькә үпкәләргә? Мин бит ул тәнкыйтьне үзем китереп чыгарганмын. Кайчан да булса мине сөйләми, «чәйнәми» яки мактамый (мине балаларым һәм җитәкчелек мактый – миңа шул җиткән) башлыйлар икән, димәк, пенсиягә китәргә вакыт.

Гади телевизор карауты «Давай поженимся» тапшыруына ничек итеп эләгә ала?

– «Давай поженимся» тапшыруында катнашу өчен кызыклы тарих кирәк. Тапшыру ялгызлык проблемасы турында, һәм без катнашучыларның тарихлары аша туйга кадәр, туй вакытында һәм аннан соң нинди проблемалар килеп чыгу ихтималы бар – шулар турында сөйлибез. Тапшыруга яхшы белемле, бер тапкыр да кияүгә чыкмаган, акыллы, тыйнак кыз килә икән – тамашачыларга нәрсә сөйләргә тиеш булабыз? Телевизор карауты кулында пульт бар, ул ике минуттан соң ук башка каналга күчәчәк. Шуңа да «Давай поженимся» тапшыруында катнашасың килә икән, «шкафыңдагы скелет»ларыңны да күрсәтерлек көчең булсын. Әйе, болар экраннар аша бик үк матур күренмәскә дә мөмкин. Шуның өчен тапшыруга кияү яки кәләш табар өчен генә килмиләр. Безнең программага билгеле бер проблеманы күрсәтергә һәм, ихтимал, кияү яки кәләш табарга киләләр. Ә нигә хәлне катлауландырырга әле, кияү яки кәләш табар өчен үземә килегез. Ә телевизорда ул эмоцияләргә корылган шоу гына.

«Мәскәүгә. Хәдичә апага»

Сезнең гаиләдә татарның нинди гореф-гадәтләре сакланган?

– Барысы да түгел, ләкин миңа энемнең хатыны Рәйсә әйтеп-өйрәтеп тора. Бик теләсәм дә, ураза тота алганым юк әле. Телевидениедә эшләгәч, вакытында туклану мөһим – мин командада уйный торган уенчы, шуңа да кагыйдәләргә буйсынырга тиешмен. Эчмим, тәмәке тартмыйм. Булдыра алган кадәр мөселман традицияләренә тугрылыгымны саклыйм. Догалар укыйм – әбием өйрәтте. Балалар аякта нык тора башлагач, барысын да үтәрмен дип уйлыйм.

Өчпочмак, чәкчәк – боларның барысы да өстәлдә бар. Иптәш кызым Коръән бүләк итте, әбиемнән калган борынгы Коръән китабы бар – ул әйбәтләп, кадерләп төрелгән. Машинамда да дога китабы бар – шуннан сүрәләр укыйм. Тәнкыйть турында сорау булган иде – кешеләр көнләшә дә бит әле, болар барысы да җыелып бара, шулардан чистарыну өчен иртәләрен Коръән сүрәләрен аудиодан тыңлыйм. Өйдә шәмаил эленгән. Кыскасы, әбием өйрәткәннәрне үтәргә тырышам.

Әгәр дә татар хатын-кызы гаилә тормышында тыйнаклык саклап тора икән, бу гаиләдә рәт булмаячак.

Роза ханым, Сез берничә тапкыр әбиегезне искә алдыгыз. Буыннар арасындагы бәйләнешләрнең бер буын аша ныграк та, назлырак та булуын беләбез. Сезнең очракта турыдан-туры күренә. Әбиегезнең исеме ничек иде?

– Хәдичә апа. Киң күңелле, кунакчыл кеше иде. Бер бүлмәле фатирда яшәде ул. Балачактан ук хәтерлим әле: әбиемдә һәрвакыт кемдер куна – идәндә гел кемдер йоклый – авылдан килгән берәр туганыбыз (кайчак ул үзе дә танып бетерми иде аларны) атналар буе анда яшәп калырга мөмкин. Камыр ашлары әзерләү – бәлеш, пәрәмәч, аларның исе... Һәм гел кунак, кунак, кунак... Тумышы белән ул Бөгелмәдән иде. Әнием хәрбиләр гаиләсендә – Львов шәһәрендә туган. Әбиемнәр – Нурлат ягыннан. Минем кече Ватаным – Татарстан. Андагы туганнарны санап бетерерлек түгел: әниемнәр 13 бала булган, һәркайсының дүрттән дә ким булмаган баласы бар.

Хәдичә әбием икенчегә кияүгә чыккан (бабам, кызганычка каршы, һәлак булган). Гәрчә әтине тәрбияләп үстергән бабайның үги икәнен белмәдек. Алар Мәскәүгә бик иртә күченгән. Башта баракта яшәгәннәр. Зур шәһәрдә акчаң булмаса, күпләп бала табып ятып булмый, шуңа да әтием үзе генә калган. Шулай да нәсел дәвам итә – без бар!

PRESSA.RU



ИШЛЕ БАЛА



Гөлнур
САФИУЛЛИНА

– Малайлар җыелып: «Әнине кире казып алып кайтабыз», – дип зиратка киткән. Берсеннән-берсе кечкенә иделәр бит әле – иң олы дигәне дә мәктәпкә кермәгән. Ярый, күршеләр күреп калган...

Әмиргали абый тынып кала. Утыз елдан артык вакыт узса да, ул көннәрне искә төшергәндә менә шулай авыр сулаткач, ирнең ул чактагы хәлен чамалавы кыен түгел... Әтиләренең сөйләвен кайсы басып, кайсы утырып читтән генә тыңлаган уллары да дәшми: күзләре генә дымланды шикелле.

...1985 елның 9 марты була ул. Әмиргалиләр, абыйлары һәм җиңгәләре, сеңелләре һәм кияүләре белән бергәләп, күрше авылдагы апаларын узган бәйрәм белән котлап кайтырга булалар. Кичке унберләрдә кайтыр юлга кузгалалар: Римманың иртүк фермага сыер саварга барасы бар. Куе томан төшкән кич була. Ярты юлга җиткәч, алар утырган атлы чана өстенә арттан машина килеп менә... Хатыннарның өчесен дә шифаханәгә озаталар. Әмиргали ГАИ хезмәткәрләре килгәнне көтеп юлда кала. Иртән хәл белергә Азнакайга китәләр. Ул күбрәк: «Апа белән сеңелкәш ничек икән?» – дип борчыла, Риммасы турында уйламый да дисәм... Хатыны бит фаҗигадән соң аякка баскан, башкаларның хәлен белешкән була. «Туганнарыгыз реанимациядә», – диләр табиблар. «Ә Римма?» Ирнең соравы җавапсыз кала... 27 яшьлек хатын инде шифаханәгә килеп җитүгә күзләрен мәңгегә йомган икән. Соңгы минутта телендә иренең исеме булган, әмма ахырга кадәр әйтеп бетерә алмаган: «Әмир...» – дигән дә, соңгы көчен җыеп, биш бармагын күтәреп күрсәткән...

Биш бармак – биш бала! Монысы – әниләренең соңгы үе... Алтынчыга авырлы икәнен иренә әйтергә ул өлгерми кала.







Фирдания

– Биш ятимгә әни булу?! Башта аптырап киттем. Әмиргали баҗасы – минем классташ белән килгән иде, аңа болай гына ияргәндер дисәм... Мәктәптә очрашу оештырып йөргән чагыбыз иде. «Безнең сүз башка бит әле», – диләр... Римма белән бергә укыдык, бер партада утырдык. Якын дуслар булдык. Туена да чакырды. Балалары тугач та кунакка баргаладым. Үлеменә башта ышанмадым да... Җеназасы өстендә дә булдым. Бала белән ирдән аерылып кайтып, Азнакайда эшләп йөргән чагым иде. Әти дәшмәде, ә әни: «Елап кире кайтмаслык булсаң гына бар», – диде. Төрле вакыт булды, әмма еларлык чакта да күз яшемне әниләргә күрсәтмәдем...

Яңа әни алырга киткән әтиләрен малайлар: «Бу бит әнинең дус кызы!» – дип каршы алалар. «Әни» дип аңа иң элек малайларның икенчесе – Илзир эндәшә, аның артыннан – калганнар. Олы малай Илмир гына озак вакыт: «Апа», – дип йөри. Аннан беркөнне каяндыр чабып кайтып керә дә: «Әни!» – дип кычкырып нәрсәдер сорап ала. «Сискәнеп киткән идем», – ди Фирдания апа.

Шулай яшәп китәләр. «Бездә киленнәр эшне сыер савудан башлый», – дип, бригадир аны фермага җибәрә. Кая ул сайлану?! Берьюлы өчәр урында эшләгән чаклары да күп була. Иртән ягулык сала, аннан механизаторларга ашарга пешерә, кичкә мөдир булып клубка чыга... Озак еллар хат ташучы булып эшли. Аннан балалар кул арасына керә башлый. Аңа операция ясаган җәйне таналар группасын Илзире алып кала. 11-12 яшьлек малай! Утыздан артык тананы сава да, сөтен дә урнаштыра.

Әмиргали

– Раилне бер-ике айдан ук үзебезгә алып килдек. Әти, абыйлар белән үсү башка бит ул... Мин аны килүгә мунчага абыйлары белән җибәрә башладым. Мәктәптә укый башлагач, класс журналындагы фамилиясен сызып, «Мөҗипов»ка төзәтеп язып куйган бу. Ачуланганнар инде... Раил тавыш куптарган: «Миңа кадәр туганнар да Мөҗиповлар, миннән соңгылар да... Нигә мин генә Сәгыйтов?» – дип. Шуннан соң тиз генә аны үз фамилиямә күчердем.

Фирдания

– Гөлнур белән Раилнең арасы ике-өч ай гына, бергә укыдылар. Социаль яклау бүлеге хезмәткәре берсендә аптырап: «Апа, бу ике балагызның яшь арасы нигә болай соң?» – ди. «Аның берсе җиде айдан ук туды, икенчесе – вакыты җитеп», – дим. Шаяртуымны әллә аңлады, әллә юк, дәшмәде...

Балалар

– Ишле балалы гаиләнең шул инде: авыр чагы да күп, кызык минутлары да...

Әледән-әле бу сүзне кабатласа да, үскән чакларын сөйләгәндә әниләре гел кызыкларына гына туктала.

– Бер-бер артлы тагын ике улым туды. Сигезәү булдылар! Әле ярый өйдә кайнанам бар иде, авырып киткәнче гел ул булышты... Чөгендер утыйбыз шулай. Өчәр гектар бирәләр иде. Инәйнең каядыр киткән чагы. Ринатка – алты ай, бала арбасына салып, аны да үзебез белән алдык. Олы малай – Илмир кечкенәдән гел әтисе янында булды, анысы трактордан төшмәде. Минем иң беренче ярдәмчем Илзирем иде. Чөгендерне дә икәү утыйбыз (кишәрлекләрне шундый озын итеп ала Илзир: аңа гел алда булырга, эшне бөтен кешедән тизрәк бетерергә кирәк). Җәйге чиллә. Ринатны карарга дип, Раил белән Гөлнурны да иярттек. Без эшлибез, болар бала арбасы тирәсендә уйный. Әледән-әле: «Апаегыз нишли?» – дип сорыйм. «Йоклый», – диләр. Берничә тапкыр шулай дип җавап биргәч, шикләнеп барсам... Алып килгән ризыкны ашап бетергәннәр, чәйне эчкәннәр, бала арбасы өстенә кара халат каплап куйганнар... Сабый эсседән тәмам әлсерәгән. Өйгә алып кайтып аны коендырдым да, үзем тагын басуга киттем: «Апаегызны карагыз, бер генә кишәрлек эшлим», – дим. Кайтсам, өй тып-тын – балалар юк! Бакча артында гына Ык бит – йөгердем. Барысы да шунда! Алты яшьлек Гөлнурым алты айлык энесен тотып су эченә кереп утырган:

– Әни, мин әле аны агызмадым! – ди...

Римма төшкә кергәли, ризадыр...

Фирдания

– Спекулянт! Аласың да арттырып сатасың!

Таныш түгел бер хатын кибеттә шулай дип чат ябышты. Сандалилар бар, дигәч, Актүбәгә барган идем. 1 сум 50 тиен торалар. Һәрберсенә икешәр пар алгач, шактый җыелды шул... Ир балаларга җәй буена бер пар аяк киеме генә җитәмени ул?! Теге хатын милиция чакыртты. Очраклы рәвештә генә кибеткә бер авылдашым килеп кермәсә, бу вакыйганың азагы ничек тәмамланыр иде, кем белгән?! «Әйе, аның үзенең балалары күп: җиде улы, бер кызы», – дип ул әйтте.

Балалар

– Илзирем белән икәү Ютазыдан чебиләр алып кайттык. Йөзне. Шактый гына исәеп киләләр иде инде. Каяндыр кайтып керсәм, өйдә чеби тавышы юк! «Йоклыйлар», – диләр... Ләгәнгә су салып, чебиләремне юганнар болар, сыкканнар (!), аннан печән астына тыгып куйганнар... Ә асрарга калдырам дигән сары төслеләрен магнитофон белән бастырганнар: «Алары музыка тыңлый», – диләр...

Кызып киттем инде, билгеле... «Төшегез бөтенегез дә базга, утырыгыз азрак шунда!» – дим. Үзем эшкә киттем. Эчем поша... Кайттым йөгереп: «Чыгыгыз!» – дим. «Әни, без әле уйнап бетермәдек! Бераздан!» – диләр...

Инәй

– Мин килгәндә алтмыш биштә генә иде әле ул. Аннан авырып китте... Тире рагы, диделәр. Андый чирне дошманыңа да язмасын... Биш ел урын өстендә ятты.

PRESSA.RU

Балалар

– Ринат белән Илдар гына ул кадәр ширлек эшләмәде... Айраты бөтен нәрсәне сүтте менә. Телевизор алып куйдык, ике көннән аны сүтте. Чибәр апаларга чәй эчәргә кергән җирдә дүрт урындыгын сүтеп кайтты. Әти мәрхүм: «Һәммәсен китер, кызым, торсыннар, бәләкәен генә иярмә», – дия торган иде. Өстәл, магнитофон, телевизор, телефон... берсе дә калмады! Дөрес, хәзер сүткәнен җыярга да өйрәнде инде. Яңа гына улы Сәет туды, ул да әтисенә охшаса, нишләрбез?

Балалар

– Әйтәм бит, ишле бала – театр ул... Урамнан кайтып керделәр көтүләре белән – кечкенәсе, Ринаты юк. Ул хәзер өйдә түгел әле, Илнур белән алар Себергә китеп эшлиләр... «Кайда апаегыз?» – дим. «Без аны штабта калдырдык», – диләр. Элек кар күп була иде бит, мунча түбәсеннән үк. Оя казып энеләрен кертеп утыртканнар да кар белән күмгәннәр. Кечкенә иде әле, болар кебек йөгерә алмый, комачаулагандыр. «Бәй, апаегыз катып үлгәндер бит!» – дим. «Юк, без аның астына салам салдык», – ди Илзир. Җыйнаулашып эзләргә чыктык, таба гына алмыйбыз штабны! Үзе дә тавыш бирми. Күрәсең, болар дәшмәскә кушкан булгандыр. Без тапканда рәхәтләнеп уйнап утыра иде...

Бер бала урынына алты яктан алты сабый «әни» дип дәшә башласын әле?!

Фирдания

– Бервакыт балалар мәктәптә сигезе берьюлы укый башлады! Җыелышларга икәү йөрибез. Әтиләре – хәйләкәр: Илзирнекенә генә керә. Ул әйбәт укый, аны гел мактыйлар: Әмиргали аннан күкрәк киереп чыга. Ә миңа бөтенесенекенә өлгерергә кирәк! Ахырга җиткәнче, алдан кергән сыйныфларда нәрсә әйткәннәрен онытам... Берсенең китабы юк, икенчесенең – дәфтәре, өченчесенең...

Әмиргали

– Ата-аналар җыелышында сөйләделәр. Укытучылары: «Балалар, иске ипи ашагыз, ул файдалырак», – дигәч, безнең Илзир кул күтәргән дә: «Апа, ә иске ипи нинди була?» – дип сораган... Кая ул ипине искертеп тору?! Әниләре көн аралаш биш-алты калай ипи сала иде...

Фирдания

– Уенын-чынын кушып, 18 ел армиядә хезмәт иттем, 88 ел мәктәптә укыдым, дим мин... Чынлап торып санап карасаң, мәктәбе күбрәк тә чыга әле – һаман укыйм бит. Быел менә кечкенәсе белән тагын беренчегә керәбез.

Берзаман армия башланды... Җырдагы кебек: «Берсе кайта, берсе китә, берсе комиссиядә...» Олырагы кайтып бер атна торуга, кечерәген алып китәләр – сөенергә дә белмисең, көенергә дә... Илдар белән Ринат кына бармады. Иртәгә китәм дигән көнне Илдарының сукыр эчәгесе шартлады. Ә Ринат күз белән үтмәде. Диңгезчеләребез дә бар, танкист та, коры җирдә хезмәт итүчеләр дә.

Илзирдән дә әйбәт хат язучы булмады – аларны әле дә саклыйм. Илмире: «Мин исән, сез исәнме?» – дип яза иде дә бетерә иде. Өченчесенең – Илнурның – бервакыт хат-хәбәре бөтенләй өзелде. Посылка салам, аңа да җавап юк. Районга, военкоматка киттем. «Исәнме икән безнең ул малай, кайда икән?» – дим. Эләктергәннәрдер инде моңа... Илнурдан хат килеп төште, конвертны ачсам, блокнот битендә ике сүз: «Мин исән».

Оныклар

– 9 малай, 4 кыз бездә. 25 ләргә җитәрбез дип торам – әле малайларның икесе өйләнмәгән бит. Илмирлар берничә өй аркылы гына тора. Аның кечкенәсе җәен һәр көнне муенына зур сөлге урый да: «Әби, су коенырга төшәбезме?» – дип миңа керә. Китәбез инде бергә Ыкка, йөзәбез икәүләп...

Оныклар әтиләре кебек үк зыян салмады дисәм... Помидор кәлшәләрен өйдә утыртмыйм хәзер. «Әби, кара әле, без печәннән кайтабыз!» – дип, бөтен үсентене йолкып, уенчык машина әрҗәсенә төяп куйдылар...

Фирдания

– Малайлар үсеп таралышты да өйдә икәү генә калдык. Бабай зур якта телевизор карый, мин кечкенә якта бәйлим, китап укыйм. Икебезгә генә күңелсез... Башта әйтергә куркып йөрдем, аннары тәвәккәлләдем... Балаларны Чаллыдан алып кайттык. 2007 ел бу. Игезәкләр иде – Руслан белән Радмила. Кызны без Рамилә дип йөрттек. Икешәр яшьлек булсалар да, шундый кечкенә иделәр: берсе – җиде, икенчесе алты гына килограммлы. Кая ул тәпи йөрү – үрмәли дә белмиләр. Имезлек тә суырмыйлар, шешәдән дә иммиләр... Тере гарип булганнар инде, балакайларым.

Башта көчкә икесен дә үрмәләргә өйрәттек. Рамилә 3 яшендә йөри башлады. Аның ашау-чәйнәү рефлексы юк иде – авызына гел массаж ясый торгач, чәйни башлады. Алты яшьтә, ниһаять, калак тотып ашарга өйрәнде.

Әмиргали

– Мәктәп яшенә җиткәч, районнан: «Бу балаларны монда укыту мөмкинлеге юк, алып китәбез», – диделәр... Казанда, Дәрвишләр бистәсендә, акылга зәгыйфьләр интернатында алар. Мин озатырга да бара алмадым. Бик кызганыч, кыен булды... Аларны илткәч, икебез дә чирләдек. Малай азрак аңлый кебек иде, аны алып каласы да килгән иде. «Туганнарны аермыйбыз», – диделәр. Күздән бер дә яздырырга ярамый иде шул үзләрен, чыгалар да китәләр, күрми

дә каласың. Фирдания телефоннан хәлләрен белеп тора. Икесе дә һаман сөйләшми, диләр...

Фирдания

– Аннан менә Чистайдан Настя белән Вадимны алып кайттык... Бабай барганда ук: «Кемне күрсәтәләр, шуны алабыз, башка беркая йөрмибез», – диде. Настяны алып чыктылар. Ул: «А у меня еще братишка есть», – диде... Настяга җиде тулмаган, энесенә өч яшь иде. Быел Вадим да мәктәпкә бара инде. Кайтуга ияләштеләр, күптән үзебезнеке инде алар. Абыйлары әле бер, әле икенче әйбер алып бирә. Татарчага да бик тиз өйрәнделәр. Кайчак сүз тыңламасалар: «Мин сезне кире Чистайга илтәм», – дип орышкан булам. Вадим: «Настя барса барыр, мин әти белән калып торам», – ди. Рәхәт алар белән... Настяның мәктәптән кайтканын көтеп торабыз. Математиканы әтисе белән эшли, калган фәннәр – минем өстә. Әйбәт укый! Гөлнурның кызы белән икәү коймаклар, кыстыбыйлар пешерәләр инде.

Әмиргали

– 2013 елны Әлмәттә йөрәккә операция ясаттым. Анда бит барысы да күз алдында: кемнеңдер янында гел карчыгы утыра, кемгәдер бөтенләй килүче юк... Минем малайлар унбиш көн буена янымнан бер дә китеп тормады – әле берсе, әле икенчесе... Бөтен кеше: «Нинди уллар үстергәнсез!» – диде... Шул арада әбигә инфаркт булды... Операциягә кадәр малайлар мине әниләренең хәлен белергә дә алып кайтып килделәр. Соңыннан бер ел буе чиратлашып өйгә кайтып тордылар. Малларны үзләре карады. Хәзер дә: «Әти, чамалап!» – дип кенә әйтеп торалар. Әле менә каравылга чакыралар да, малайлар: «Әти, юк, булды, җитте», – диләр. Өчәр эштә эшләгән чаклар бар иде. Бригадир да булдым, инженер да, тракторист та, шофер да... Иң авыры туксанынчы еллар булды, хезмәт хакы түләмәгән вакытлар. Илзир Бөгелмә техникумын кызыл дипломга тәмамлады, Казанга барып имтиханнар да биреп кайтты. Аны укытырга биш мең акча булмады ул чак... Армиядән соң инде эшкә урнашты, йорт төзергә кереште. Ә туйларын һәрберсенекен зурлап үткәрдек – йөзәр кешелек табыннар корып!

Фирдания

– Малайлар бөтен эшне эшли безнең. Ел саен утызар каз, үрдәк, күркә, бройлер чебиләр үстерәбез. Кеше чакырмыйбыз, киленнәр, малайлар белән кош-кортны үзебез йолкыйбыз. Олы сугымны да үзләре суя. Терлекне гомергә күп асрадык. Әле дә ике сыер савабыз. Сугымга ике баш эре терлегебез бар, сарыклар... Маллар янына мин чыкмыйм, киленнәр белән без өйдә. Бөтенесе кайткан чакта ашны 20 литрлы кәстрүл белән куям. Пилмән бөксәк – биш йөзне... Бер утырып ашауга шул җитә.

Олы кебек күренгән эш тә, бергәләп тотынгач, тиз бетә бит ул...

Әмиргали

– Шалтыратып хәлебезне белмәгән көннәре юк, кайтып та йөриләр. Әти белән әни начар яшәсә генә балалар өйдән читләшә ул... Үзара да бик дус малайлар. Бөтен эшне күмәкләп эшлиләр. Илзир абыйлары бригадир кебек: кемгә, ничек булышасы – ул хәбәр сала да, җыелышып баралар. Кечкенәдән эшләп үстеләр, мәктәпкә киткәнче малларны карыйлар иде. Хәзер әнә: «Әти, күпмерәк печән кирәк булыр икән?» – дип кенә сорыйлар, кайтаралар. Ринаты КамАЗ машинасы алып куйды, капка төбендә тора – кемгә кирәк, шул утыра. «Баш очларында ныклы түбәләре, яшәргә төпле эшләре булсын», – дип телибез. Шөкер, йортлар да салдылар, эшләре дә бар...

...«Ел хатын кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесенең «Хатын-кыз – ана» номинациясендә Фирдания Мөҗипова быел җиңү яулады. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов аны үзе котлады. Азнакай районының Бүләк авылында яшәүче бу зур, тату гаиләдә бәйрәм булгандыр ул көнне. Гомере вакытсыз өзелгән Римманың дә рухы шаттыр. Римма әнинең... Бу гаиләдә барысы да – Фирданиянең беренче никахыннан туган улы Раил дә, тәрбиягә алган балалары – Настя белән Вадим да аны шулай атый: «Римма әни».

Март башында Казанның Салих Сәйдәшев исемендәге Зур Концертлар залында «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика конкурсына йомгак ясалды. Төрле номинацияләрдә иң-иңнәре дип табылган күркәм ханымнарны тәбрикләү тантанасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты.

Билгеле булганча, конкурс өч этапта уздырыла: муниципаль берәмлекләр һәм зоналар буенча сайлап алу турлары һәм Казандагы финал. 2016 елда конкурста катнашырга 700 дән артык гариза тапшырылган. Зона этапларының 118 номинанты сайлап алынган, аларның 30 ы конкурста җиңгән.

Иң элек Татарстан Президенты барлык хатын-кызларга мөрәҗәгать итеп, 8 Март бәйрәме белән котлады һәм исәнлек-саулык теләде. «Без, мөгаен, хатын-кызның дәүләт, республика, һәр гаилә өчен әһәмиятен кайчак бәяләп тә бетермибездер. Хатын-кыз ул – гаилә нигезе, ә гаилә – дәүләт нигезе. Сез – аналар да – бизнес вәкилләре, җәмәгать эшлеклеләре дә. Сезнең алда баш иябез», – дип билгеләп узды Рөстәм Миңнеханов һәм рәхмәтен җиткерде.



Җиңүчеләрнең тулы исемлеге сайтыбызда урнаштырылган.

PRESSA.RU

Бала туу, дөньяга яңа кеше килү – табигатьнең иң зур могҗизасыдыр... Синең дәвамың, син булып, синсез киләчәккә атлап китәчәк бәгырь кисәгең. Йөрәк парәң...
«Балабыз туды, аңа тәрбия бирүне нидән башларга икән?» – дигән сорау белән аксакал янына килгән яшь әти белән әнигә, инде гомер кичкән, тормышның ачысын-төчесен татыган, башкалар белән бүлешерлек тәҗрибә туплаган өлкән кешенең: «Сез аны тәрбияләргә инде тугыз айга соңга калдыгыз...» – дип җавап бирүен риваять итеп сөйлиләр.
Баланы көтү, аны дөньяга тудыру, иң беренче тапкыр кулыңа алу, күкрәк сөтен имезү, исем кушу... Халкыбыз боларның һәркайсына зур игътибар биргән, алар белән бәйле әллә никадәр йола, гореф-гадәтләр сакланган. Һәм аларның һәрберсендә нинди дә булса хикмәт бар! Шуларның барысын бүген яшьләребезгә аңлатасы, өйрәтәсе, күңелләренә салып куясы килә. («Тәрбия баскычлары» дигән фильмны да шул максаттан төшердек.)



КӨТЕЛГӘН БҮЛӘК

Бер-ике ел элек Төркиягә, Истанбул шәһәрендә яшәүче милләттәшләребез уздырган «Татар кызы» бәйгесенә барырга туры килде. Соңыннан, сөйләшеп утырганда, «Идел–Урал татарлары» оешмасы җитәкчесе Гөлтан ханым Ураллыдан: «Мөмкин булса, мине бала тудыру йортларының берәрсенә алып барыгыз әле», – дип үтендем. «Нәрсәгә?» – диде ул аптырап. «Сездә балаларны ярып алалармы икән, шуны беләсем килә», – дим. Гөлтан ханымның җавабы мине шаккаттырды: «Бездә ул 95-96 процент тирәсе булыр. Табиблар аны акча эшләү юлына әйләндерде», – диде ул. Ышанырга да, ышанмаска да белмәдем... Бардык бала тудыру йортына. Бирдем андагы табибларга үземне кызыксындырган әлеге сорауны. «Ә ни булган? Моның нәрсәсе бар?» – дип сораугa сорау белән генә җавап бирде алар.

Казанга кайткач, бу хакта бер танышыма сөйләдем. Аның улы белән килене Төркиядә яши. «Нәрсәсенә аптырыйсың?! Әйе, шулай. Безнекеләр өченчесен көткәндә табигый юл белән бала табу мөмкин булган тудыру йорты эзли-эзли аяктан калды. Истанбул читендә генә таптылар андый бала тудыру йортын», – диде ул.

Уйлана калдым... Үзебезнекеләргә шалтырата башладым. Казандагы бала тудыру йортларының берсендә: «Яңа туган балаларның 36 процентын ярып алабыз», – дип җавап бирделәр. Икенчесендә – 42, өченчесендә – 48 процент, диделәр. Алай икән...

Табиблар яшерми: баланы хәзер анага яки балага куркыныч янаган очракларда гына ярып алмыйлар. Анысы – башка аның. Бүген хатын-кызларның күбесе баласын операция юлы белән дөньяга китерүне тулгак ачысыннан, авыртудан курку белән аңлата. Моңа бернинди сәбәп булмаса да, патологияләр күзәтелмәсә дә, баласын ярып алуны алар табиблардан хәзер үзләре сорый, хәтта таләп

итә. Табигый юл белән бала табарга куркуның медицинада инде үз термины да бар – «токофобия» дип атала.

Бөтендөнья сәламәтлекне саклау оешмасы: «Бу проблема соңгы вакытта глобаль масштаб алды», – ди. Интернет китергән мәгълүматлар буенча, Латин Америкасы илләре әлеге исемлекнең башында тора. Әйтик, Бразилиядә яңа туган балаларның яртысыннан күбрәген (шәхси клиникаларда биш баланың – дүртесен) ярып алалар икән. Аларда әлеге «эпидемия» белән көрәшү өчен инде махсус законнарга кадәр кабул итә башлаганнар. Хәер, башка илләр дә калышмый. Чиратның икенче баскычында – Мисыр (анда 51,8 процент бала дөньяга шушы юл белән туа). Европада бу күрсәткеч буенча Төркия (47,5 процент) белән Италия (38,1 процент) рекорд куйган. Мексика, Иран, Америка Кушма Штатларында да бу саннар шактый югары. Кеше саны буенча җир шарында алдынгылыкны бирмәгән Кытайда менә хәлләр алай ук борчылырлык түгел кебек (25 процент). Әмма бу беренче карашка гына шулай, чөнки барлык операцияләрнең 32 проценты нәкъ менә ананың теләге, үтенече буенча ясала. Анда әниләр бала туган көнне ниндидер бер аерым датага, берәр бәйрәмгә туры китерер өчен тырыша.

Хәер, һәр төбәкнең үз сәбәбе. Әйтик, мондый операцияләр гадәти күренешкә әйләнгән Бразилиядә, кабат бала табарга теләмәгән әниләр тагын бер проблеманы хәл итә: баланы ярып алганда, аналык көпшәләрен бәйләтеп, беррәттән стерилизация дә ясата. Чили, Аргентина кебек илләрдә исә хатын-кыз өчен һәрвакыт сексуаль булып калу бөтен нәрсәдән өстен: баланы ярдырып алып, алар җенес әгъзаларын ярылулардан, киңәюдән саклый. Ә Италиядә үткәргән сораштырулар андагы хатын-кызларның бу адымга бары тик үзләрен тулгак газапларыннан аралау һәм баланы төрле хәвеф-хәтәрдән саклау өчен баруларын күрсәтә.

Беренче баласын тапканда ниндидер катлаулылыклар, авырлыклар кичергән хатыннар арасында да икенче тапкыр әни булырга җыенганда: «Бары тик ярып кына алдыртам», – дип әйтү бар.

Яшерен-батырын түгел, баланы ярып алуның бүгенге көндә «мода»га әйләнүендә табиблар үзләре керткән өлеш тә аз түгел. «Суым китте», – дип хәбәр иткән хатын янына төн уртасында барып, сәгатьләр буе аның, ниһаять, бәбиләвен көткәнче, гинекологлар план буенча мондый операцияләрне көнгә берничәне дә ясый ала. Бу ысул белән аларның акча эшләве дә күп нәрсәне аңлата...

Чынлыкта, хатын-кыз баладан үзе котылу белән чагыштырганда, баланы ярдырып алганнан соң ана да, бала да уникe тапкырга күбрәк өзлегүен табиблар үзләре дә яшерми. Җиңел, дөньяда иң киң таралган операцияләрнең берсе дип саналса да, барыбер пычак астына

ФИКЕР



Наилә ГАЙНАНОВА,
ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының баш белгече, акушер-гинеколог

Хатын-кызга иң зур вазыйфа йөкләнгән. Ул таза, сау-сәламәт балалар тудырырга тиеш. Яшь әни, йөклелеге 12 атна булганчы хатын-кызлар консультациясенә барырга, табиб кушканнарны үтәргә, кирәкле анализларны тапшырырга тиеш. Хатын-кыз бәбиләгәндә көтмәгән төрле хәлләр, катлаулыклар килеп чыгарга мөмкин. Ананың да, баланың да гомерен саклап калу өчен бу очракта баланы ярып алалар. План буенча баланы алдан ук ярып алырга тиеш булган очраклар да бар. Моны табиб кына хәл итә. Тулгактан куркам, авыртуга түзмим дип кенә хатын-кыз хирург пычагы астына ятарга тиеш түгел. Медицина бер урында тормый: авыртуны баса торган ысуллар, чаралар бар хәзер. Мәскәүдә, академик В. И. Кулаков исемендәге фәнни үзәктә бер профессорның чыгышын тыңларга туры килде. Табигый рәвештә туган һәм ярып алган балаларны күзәткәннәр: алар ничек үсә, нәрсәгә сәләтлеләр... Нәтиҗәләр шуны күрсәткән – әниләре үзләре тудырганнар сирәгрәк авырыйлар, алар күпкә талантлырак.

ФИКЕР



Фәнзилә ҖӘҮҺӘРОВА,
Татарстан Республикасы традицион мәдәниятне үстерү үзәге директоры

Йөкле хатын аркылы яткан бауны атлап чыгарга, җеп эрләргә тиеш түгел – баланың кендегә уралып туа, диләр. (Беләбез инде – кендегә уралып туганда асфиксия башланырга мөмкин: балага тиешле дәрәҗәдә кислород килми, нәтиҗәдә аның акылына зәгыйфьлек килүе бар). Ул мәеткә дә карарга тиеш түгел – туачак баласының йөзе мәетнеке кебек ак булыр, куркып калыр, диләр. Мөмкин булган кадәр матур, чибәр кешеләргә карарга кушалар – баланың йөзе матур булыр, диләр. Безнең гаҗәеп үзенчәлекле йолабыз булган – «авызландыру» дип аталган. Аны кендек әби белән баланың әбисе бергәләп башкарганнар. Балага беренче ризык авыз иттерү – күкрәк каптыру бу. Монда теләк теләү бик мөһим: авызың баллы, телең тәмле, гомерең ризыклы, дөньяң мәнле булсын... Әнисе, кендек әбисе һәм дәү әниләре баланың киләчәгенә шулай итеп берникадәр программа салып куя.
Бала бишеген теләсә кая эләргә ярамый. Иң куркыныч урын – матча, диләр. Матча – бу дөнья белән теге дөньяны тоташтыра торган урын дип санала. Бишек бары тик астан-өскә генә хәрәкәтләнергә тиеш: баланың үсүе дә шулай бит.

PRESSA.RU

ФИКЕР



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН,
«Туган авылым» мәчете
имам-хатыйбы

Баланы тәрбияләү хатын-кыз үзенә – ир, ә ир үзенә хатын сайлаганда башлана. Халык мәкале «әтисенә карап, улын коч, әнисенә карап, кызын коч», ди. Гомумән, без үзебезнең булачак хатыныбызга (иребезгә): «Ә ул нинди әни (әти) булыр?» – дигән күзлектән карарга тиешбез.

Балага җан кергәнче без әле Аллаһы Тәгаләдән: «Миңа шундый-шундый бала бирсәң иде», – дип сорый алабыз. Җан кергәч, аның инде киләчәк гомере языла: күпме яшәячәге, нинди гамәлләр кылачагы, бәхетле яки бәхетсез булачагы... Аллаһы Тәгалә хәерле язмыш язып бирсә иде, дип сорарга кирәк. Чөнки туганнан соң аны инде син үзгәртә алмыйсың – бала шул язмыш белән туган санала.

Балага узган хатын-кызга авыр сүз әйтмиләр, авыр эш эшләтмиләр, борчымыйлар... Ана ашаган ризык белән дә балага тәрбия керә, тәүфыйк керә. Шуңа күрә өстәлдә хәләл ризык кына булуы бик мөһим.

Исемнең мәгънәсе кеше язмышына турыдан-туры тәэсир итә. Шуңа күрә, балага мәгънәле исем бирергә кирәк. Алар берничәгә бүленә. Тыелган исемнәр, ягъни бөтенләй бирергә ярамый торганнар. Мәгънәсе ямьсез булганнар: аларны кушмау яки алыштыру хәерлерәк. Мәгънәсе нейтраль булган исемнәр бар, мәсәлән, чәчәк, күк җисемнәре исемнәре. Авыр исемнәр: бу исемнәрне кушарга мөмкин, ләкин кешенең тормышында авырлык барлыкка килүе бар.

хәзер әниләрнең үзләренә бирәләр. Ана кешегә аны кайда, ничек сакларга икәнен генә аңлатырга кирәк безгә. Ике газиз кешене бербөтен итеп ялгап тотачак җеп бит ул!

Дини, фәнни, дөньяви, гореф-гадәтләр хәзер менә шулай әкренләп бер ноктада җыела, кисешә.

Бала тапканда бөтен тамыр өзелеп бетә, берсе генә кала, диләр. Бәбигә кырык көн булганчы, ана белән баланы элек бөтен авыл белән тәрбияләгәннәр: чиратлашып бу йортка бәби ашы китергәннәр. Бүген хатын-кызның күбесе: «Үзем!» – ди. Ялгышалар... Яшь әнигә иң элек ире булышсын. Гаилә ныклыгы өчен иң кирәк шартларның берсе бу.

Кадрия ИДРИСОВА,
«Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы рәисе,
филология фәннәре кандидаты.

яту инде бу... Бала өчен моның нинди зур стресс, шок булуын аңлар өчен гади генә бер мисал китерәм. Төнге күлмәкләр белән үзебезнең йокы бүлмәсендә йоклап ятабыз, ди. Ишек-тәрәзәләр бикле. Үзебез иялләшкән тирәлек. Һәм шул вакыт ишегебезне каерып ачалар да, урыныбыздан йолкып алып, урамга чыгарып бастыралар... Нинди халәт кичерер идек? Шок! Курку! Бала да шулай. Гомумән, табигый юл белән туганда бала үзе үтәргә тиеш юлны үтә. Фән дә моны хуплый. Ярып алган балалар киләчәктә стрессларны күпкә авыррак кичерәчәк. Мишель Оден дигән француз табибы, акушер-гинеколог: «Гомумән, җәмгыятьтә агрессивлыкның ни дәрәҗәдә булуы бик еш кына ул илдә акушерлык эшенә дә бәйләнгән, – ди. – Киләчәктә кешенең нинди шәхес булуы бала туганда аның организмында нинди гормоннар күбрәк барлыкка килүеннән дә тора», – ди ул. Окситоцин икән, димәк, ул бөтен нәрсәгә дә яратып караячак. Ә ярып алганда, ана белән баланың беренче «очрашуы» шунда ук булмаганда, организмда адреналин артып китә һәм бу дөньяны кабул итүгә дә тәэсир итәчәк, агрессивлыкны арттырачак.

Статистика мәгълүматлары буенча, сабыена күкрәк сөтен имезмәүчеләр арасында баласын ярып алган хатыннар күбрәк. Андый аналарны кемдер җинаятьче дип атый. Бу сүздә хаклык та бардыр. Күз алдына китерегез: без каяндыр кайтып кердек, тамагыбыз ач, ә өйдә табын тулы ризык. Тик әниебез безне шул табынга утыртмый... Күңелебездә нинди уйлар туар иде икән? Аннары ана белән бала арасында якынлык, җылылык, бердәмлек юк дибез... Баланы имезү – зур бәхет ул, әни кешенең иң рәхәт чоры. Хәзер бит баланы кендеген кисүгә алып китмиләр – ананың күкрәгенә салалар. Элек угыз сөтен дә савып түккән булсалар, хәзер имезергә кушалар. Угызны бернәрсә дә алыштыра алмый, тышкы тирәлектәге микроблардан саклый, баланың иммунитетын ныгыта торган иң күп элементлар анда икән. Баланың кендек бавын да моңарчы тудыру йортларында чүплеккә чыгарып ыргыталар иде,

Кичә, бүген, иртәгә...

«Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасының киләсе елга ниятләгән эшләре:

- «Татар исемнәре» китабын чыгару.
- «Тәрбия баскычлары» CD дискның II өлешен чыгару (балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләргә балалар халык уеннарын өйрәтү, уеннарның видеоязмалары).
- «Күркәм гаилә» бәйгесен үткәрү.
- Бөтендөнья матурлык бәйгесе «Татар кызы–2016» үткәрү.
- Уфада татар милли китапханәсен ачу.
- «Калфак бәйрәме» үткәрү.
- «Шәҗәрә – безнең тамырлар» бәйрәмен үткәрү.
- «Татар халык ашлары» мастер-классын уздыру.
- Татар милли киемнәре дизайнерлары бәйгесен уздыру.
- Бишек җырлары бәйгесен уздыру.

«МӘРХӘМӘТ»ЕҢ БЕЛӘН...

Авыр хәлдә калган гаиләләргә ничек ярдәм итәргә? Вакытлыча приютларга урнаштырылган балаларны ничек итеп тизрәк өйләренә кайтарырга? Эчкечелеккә каршы тагын нинди чаралар кулланырга? Ведомствоара мөнәсәбәтләрне ни рәвешле көйләргә? «Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлар берләшмәсенең Балык Бистәсендә булып узган күчмә утырышында берсеннән-берсе җитди проблемалар күтәрелде.

Мәдинә АВЗАЛОВА

Сүзне нидән башларга да белмим. Чөнки Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасында Бала хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау, Сәламәтлек саклау министрларының урынбасарлары, УФСИН вәкилләре, дистәләгән районнардан килгән опека һәм иганәчелек бүлекләре җитәкчеләре, мәктәп директорлары катнашында үткәрелгән бу утырышта телгә алынган һәр сүз, һәр җөмлә сискәндереп яңгырады. Көн үзәгенә куелган мәсьәләләр турында фикер алышучылар артык нечкәләнеп, нәзакәтлелек күрсәтеп тормадылар: бүгенге хәлне ничек бар, шулай аңлатып бирделәр.

Бөтен бәланең башы эчкечелектән: гаиләнең таркалуы да, бала язмышының җимерелүе дә, җинаятьләрнең артуы да, яшүсмерләр арасында суицидларның кабатланып торуы да... барысы, барысы да. Яшәү рәвешебезгә әйләнә барган бу ләгънәттән ничек котылырга соң? Дөресен әйткәндә, без күбрәк инде эш узгач, фаҗига булгач кына, ягъни яшен яшьнәгәч кенә бу ямьсез күренешләрнең нәтиҗәләрен анализларга алынабыз. Билгеле бер фильмдагыча, туңдырма – балага, чәчәк – әнигә, дигәндәй, эчкече гаиләдәге әти белән әнине, (теләге булса, әлбәттә) – Наркология диспансерына, ә бала-чаганы, әлбәттә инде, приютка, вакытлыча сыенып торыр куышына куып кертәбез. Ошыймы балага ул, ошамыймы?! Бу хакта әллә ни уйланып тормыйбыз. Чөнки беләбез: ошамый.

Бүген республикада аракы тозагыннан ычкына алмаган 1214 гаилә (бу сан гел үзгәреп тора) исәптә тора. 1439 кеше дәвалануга мохтаҗ. Шуларның 703 е – дәваланган. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Юлия Абдрееваның әйтүенә караганда, максат – аларны айныту гына түгел, тизрәк эшкә урнаштыру да. Бүген исә «ышанычсыз» төркемгә кергән шундый 529 кеше эшкә урнаштырганны көтеп йөри. Көтеп йөргән арада алар тагын ычкынып куя. Нәтиҗәдә, айлар буена барган көрәш бер селтәнүдә юкка чыга. Ә приютта бала, өзгәләнеп, әнисенең тәэзләгәнен көтә.

Вәкаләтле вәкил Гүзәл Удачина бу уңайдан җанга сулыш өрердәй мисаллар китерде: моннан бернича ел элек балалар приютта бишәрҗидешәр елга тоткарланган булса, хәзер алты айдан бер елгача гына. Моның сере – эчеп, «дилбегәсеннән ычкынган» тәрбиясез ата-ананы айныту, башкача әйтсәк, тернәкләндерү программасының уңышлы эшләве.

Хөкүмәт каршындагы Балигъ булмаган яшүсмерләр һәм аларның хокукларын яклау республика комиссиясе җаваплы секретаре Илсөяр Гарифуллина, бу җәһәттән, балигъ булмаган балалы алкоголик әниләр өчен «Аеклык ноктасы» проекты эшли башлавы, әлеге чараларда 45 ана катнашуы, март ахырларына аның тәмамланачагы хакында әйтте. «43 әни бу сынауларны уңышлы үтте. Берсе бу чорда авырга узды һәм дәвалануны өзәргә мәҗбүр булды, икенчесе түзә алмады, биреште», – диде ул. Яман чиргә гадәткә каршы төрле алымнарны сынап карарга, сөйләшүдә катнашучылар тәкъдим иткәнчә, элеккеге чорларда кулланылган ирексезләп дәвалауны да яңадан кайтарырга кирәктер безгә. Ә шулай да иң мөһиме: республикада яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләре булдыру. «Без мондый үзәкнең кирәклеген аңладык инде», – диде комиссиянең җаваплы секретаре.

«Ятим балаларга, авыр хәлдә калган гаиләләргә ниндидер мөнәсәбәте булган һәркем, «мин нәрсә эшли алам», дип уйлансын». Утырышны алып баручы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, «Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе җитәкчесе Татьяна Ларионова бу сүзләрне югары мөнбәрдән юкка гына кат-кат әйтмәгәндер. Бу мәсьәләгә салкын, җавапсыз караш еш кына фаҗига белән тәмамланырга да мөмкин бит. Игътибарны кызыксындырган, ә дөресрәге, сәер саннарга гына юнәлтик әле: Татарстанда бала хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил аппараты авыр хәлгә юлыккан гаиләләр турында мәгълүмат җыя башлагач, шундыйлар рәтенә 2014 елны – 8, ә узган ел нибары 2 генә гаилә кертелүе ачыклана. «Гаилә хәлләрен җирлек башлыкларыннан да яхшырак тагын кем белә? Ә бирелә менә шундый саннар. Үз эшеңә гаять дәрәҗәдә җавапсыз карау дип бәялим мин моны», – диде Вәкаләтле вәкил борчылып.

Инде опека һәм попечительлек бүлекләре хезмәткәрләренең эшләренә килгәндә, бу өлкәдә дә җибәрелгән хаталарның исәбе-саны юк. Чыгышлардан күренгәнчә, аларның кайберләре «отписка», «формализм» белән шөгыльләнә. Әйтик, тернәкләндерү программасына кертелгән бер гаиләдә барган «тәрбия» чаралары турында берсе болай дип яза: «Тернәкләндерү чаралары үткәрелде: хәл уңай якка үзгәрде. Гаиләне «Минем гаилә» газетасына яздырдык, әти кешегә «Сак бул! Спайс» темасына лекция укылды». Ә «әти кеше» дигәннәре урын өстендә ята торган инвалид.

Балаларны гаиләдән алу, ятимнәр йортларына урнаштыру барышы да бик күп ризасызлык-аңлашылмаучылык китереп чыгара. Былтыр гаиләләрдән 122 бала (?!) алынган. Ә бит һәр очракны гадәттән тыш хәл буларак бәяләргә тиешбез.



Тулысынча сайтыбызда укый аласыз.



PRESSA.RU



БУЛДЫРАСЫҢ, МАРИЯ!



Мәдинә
АВЗАЛОВА

МОНДЫЙ УҢГАН, СИЗГЕР КУЛЛАРГА ЭЛӘККӘН СЫЕРЛАРГА ДӨНЬЯ РӘХӘТЕДЕР УЛ.

Маллары арасында чиксез бәхетле булып йөргән, йөзеннән елмаю китмәгән бу ханымнан: «Эшеңне яратасыңмы?» дип сорау урынсыз булыр иде.

Кайбыч районының Хуҗа Хәсән авылы үзәктән еракта булып чыкты. Юл уңаена бераз баргач, Чуашстан Республикасы башлана. Авылның уң күршесе дә, сул күршесе дә – шулар... Шуңа күрә Хуҗахәсәннәр: «Канашка чыгып кердек», – дип кенә сөйләшә. Дөресен әйткәндә, туганлашып беткән инде алар. Чуашы, татары бергәләшеп, үзләре әйтмешли, «матур гомер кичереп» ята шулай. Авыл үзе бик зур сыман тоелса да, җирлек башлыгы Светлана Матвеева әйтүенә караганда, 247 хуҗалыктан гыйбарәт. Хуҗасыз калган йортлар күп биредә. Кайсы шәһәргә, кайсы фани дөньяга күченгән. Ләкин 800 ләп кешесе булган Хуҗа Хәсән читтән караганда гына пыскып торган учакны хәтерләтә. Авыл тормышы белән якыннанрак таныша башладың исә, исең-акылың китә: ә бәләкәй казан шәбрәк тә кайный икән әле ул! Хәер, бу кадәресе инде дүрт авылны бер йодрыкта тоткан җирлек башлыгыннан тора. Моннан берничә ел элек республика «Ел хатын-кызы» бәйгесенең «Хатын-кыз – лидер» номинациясендә җиңү яулаган Светлана Петровна бүгенге героинябызның апасы булып чыкты.

– Менә бит кемгә карап шундый безнең кыз!

Шулай дигәч, җирлек башлыгы көлеп җибәрә:

– Ул кызның житкән улы, ике кызы бар инде... Аннары, – дип өсти ул, – миңа түгел, әнигә охшаган ул. Безнең әни алдынгы сыер савучы иде.

Бер ишегалдында ике йорт: сулдагысында – Мариянең кайнанасы Елизавета түти яши. Ә уңдагысында – Мария белән Владимир Таймасовлар гаиләсе. Безне каршы алган йорт хуҗалары: «Аерым яшәмибез, әни гел бездә», – дип, шундук ачыклык кертеп куя.

Янибызда бөтерчектәй йөргән тиктормас Марияне, кулыннан көч-хәл белән әләктереп алып, янибызга утыртабыз. Сөйлә, янәсе... Җиңү арты җиңү яулауның да бер сере бардыр ич инде?

Бер-бер артлы биргән сорауларыбызга: «Шулайдыр инде...» – дип тыйнак кына җавап биреп утырган яшь ханымның тора-бара теле ачылды тагын үзе.

Алты яшьтән – фермага

– Мин урта мәктәпне уртача тәмамладым, – дип сөйли башлый ул. – Институтка керә алмавымны белдем. Бик бәләкәйдән әнигә ияреп фермага йөргәнем истә. Кайчак әнинең алып барасы килми, «комачаулап, сыерлар куркытып йөрмә», дип ачулана. Ә мин елыйелый аның артыннан чабам. Шул вакыттан бирле яраткканмын, күрәсең, малларны. Шулай да никтер унберенчене тәмамлагач, Канашка училищега китәргә – штукатур-буяучы һөнәрен үзләштерергә булдым. Үзем дә белмим, нигә вакыт әрәм итеп йөргәнмендер инде. Һаман да шул башкаларга иярү, шәһәргә китү теләге булгандыр, мөгаен. Башкача аңлата алмыйм. Бер ел шунда укып, һөнәр алгач, Яшел Үзәнгә барып, төзелешкә эшкә урнаштым. Ә үземнең йөрәк сыкрый, авылны сагынам, әнинең сыерларын үлеп сагынам.

– Егетең булгандыр әле, ул чакыргандыр, – дим, сер йомгагын сак кына сүтә-сүтә.

Ул елмаеп җибәрә. Гомумән, ул кояшның үзе шикелле. Миңа калса, аның йөзеннән бервакытта да елмаю китмидер, бу аның табигый халәтедер сыман тоела.

Клубтан өенә кадәр... кулында күтәреп

– Анысы дөрес, – дип җөпли сүзебезне әңгәмәдәш. – Тугызынчы сыйныфтан бирле йөри торган егетем бар иде. Ул миннән бераз олырак. Мәктәпне тәмамлап, армиягә киткәндә мин аңа: «Көтәрмен, исән-сау кайт кына», – дидем. Сүземдә тордым: көттем, бер генә минутка да исемнән чыгармадым. Ләкин, беләсез инде, ул дөнья гизеп, Владивосток якларыннан туган иленә, ягъни авылыбызга кайтып төшкәндә, мин пыр тузып Яшел Үзәндә эшләп ята идем. Ял вакытында авылга кайттым да клубка чыктым. Ул мине күрү белән үк күтәреп алды да, өенә кайтып җиткәнче кулыннан ычкындырмады. Ә яшәгән өе клубтан ерак. «Төшер, – дим, – җәллим үзен. – Мин беркая китмим. Әни белән апаны гына чакыр». «Юк, – ди бу, – төшерсәм, качасың». Әнә шулай кара төндә килен булып төштем.

> *Колхоз рәисе аңа: «Әйдә, безгә фермага кил! Күрсәтәчәксең әле син үзеңне...» – ди.*

– Ничек карадыгыз инде бу хәлләргә? – дибез, сүзгә кушылырга җай гына эзләп торган Елизавета түтигә.

– Ничек карыйсың? Әйбәт, – ди карчык. – Алар минем дүрт малай. Алдылар да керделәр, алдылар да керделәр, кем әйтмешли. Менә шул, – ди ул кеткелдәп. – Киленем шәп, үземә охшаган, – дип мактап та куя.

– Туйлар узды, авылга кайттым, – дип дәвам итә Мария. – Хәзер бит инде миңа эш кирәк. Колхоз рәисе шул чагында мине эшкә чакырды. «Син – малларны, маллар сине ярата», – диде. Дөрес әйтте. Тәкъдименә бик рәхәтләнеп риза булдым. Беренче көнне ферма ишеген ачып кергәч тә, өнемме-төшемме дип тордым. Шулкадәр сагынылган, шулкадәр тансык. Нинди төркемне бирсәләр, шуның белән эшләргә әзер идем. Әнигә рәхмәт, җиңемнән әләктереп алды да: «Минем сыерларны ал, син аларны яхшы беләсең», – дип, күктән җиргә төшерде. 25 сыер белән эшләп киткән кеше мин.

«Бәхетле гаиләдә генә балалар елмая»

Мәктәптән кайтып кына кергән кызлары – Альбина белән Варвара – безне күрүгә әниләре сыман балкып китә. Шулкадәр дә охшарлар икән әниләренә. Йөзләренә кунган нур-яктылык азга гына да сүрелеп тормый. «Мин үскәч табиб булам», – ди икенче сыйныфта укучы төпчекләре Варвара. «Ә мин – җырчы», – ди Альбина. Ул гел «5»легә генә укый. Канашка музыка мәктәбенә йөри. «Әтисе машина белән йөртә», – ди әниләре горурланып. «Альбина, уйнап күрсәт әле». Кыз ялындырып

Фото: Ксения Богданова

PRESSA.RU

тормый. Синтезаторын күтәреп чыга да, бүлмә уртасына куеп, уйнап җибәрә. Стенага эленгән дистәләгән медальләренә караганда, кыз да әнисеннән калышмый. Волейбол, теннис буенча ярышларда катнаша, йөгерешче дә икән әле үзе. Олы уллары Николайга – тиздән армиягә. Ул инде техникум тәмамларга, машинист һөнәрен үзләштерергә өлгергән. Җыеп әйткәндә, бу гаиләдә барысы да балалар өчен, аларның мәнфәгатен кайгыртып, алар турында уйлап эшләнә.

– Шат күңелле балалар, әйеме?!

Светлана Петровна әйткәнебезне шундук эләктереп ала: «Бәхетле гаиләдә үскән бала гына шулай елмая».

Әйе, һәр почмагына сөю-ярату, наз-мәхәббәт кунган бу йорттан чыгып китәсе килми. Мария хәзер: «Ярый әле киреләнеп тормаганмын, кулыннан ычкынып чапмаганмын», – дия торгандыр. Ире Владимир әйбәт кеше булып чыкты. Ул аңа булыша. Таңнан торып сыер саву, терлек асларын чистарту – аның эше. Фермага эшкә бергә йөриләр. Елизавета түти әйткәнчә, бергә чыгып китәләр, җитәкләшеп бергә кайталар. «Ирең шундый булмаса, дүртәр көн ярышларда йөрү тәтемәс иде». Бу сүзләрне гомер юлдашына мең рәхмәтле Мария әйтә.

Кайнанасы аны: «Киленем үземә охшаган», – дип мактап бетерә алмый.

Җиңү арты җиңүләр...

– Эшкә чыккачмы? – ди ул соравыбызга сорау белән җаваплап. – Сыерларны беләм, алар да мине таный. Эшләп китү читен булмады. Әйтерсең, мин азга гына каядыр китеп югалып торганмын да, хәзер менә кайтып, үз дөньямда йөрим. Баштан ук үземне шулай хис иттем. Бүген генә ул аппаратлар белән сауган сөт үзеннән-үзе торбалар аша китеп, суыткычларга барып урнаша. Сөтне сауганнан соң бидон белән ташыган чаклар да бар иде бит. Ул чагында менә авыр иде. Хәзер нәрсә ул?! Аппаратны биш секундта җыйдың, сыерның җиленәнә көйләдең дә йөрисең араларында «Җимешем», «Матурым» дип. Һәр сыерымның исеме бар. Исемнәре белән дәшсәм, шундук җавап бирәләр. Һәркайсы...

– Ничә сыер инде ул хәзер?

– Илле...

– Барысының да исеме бармы? Ничек исеңдә калдырасың? – дибез, ышанмыйчарак торып.

– Менә инде, – ди Мария, әйткәнебезгә гаҗәпләнеп. – Гомер буе шулар янында бул да, исемнәрен исеңдә калдырма... Алай булмый ул. Алар бит миңа балаларым кебек. Декрет ялыннан да балаларның яше тулыр-тулмас фермага йөгердем. Ә кечкенәсе белән – ике айдан. Варвараны гел кайнанам карады. Ул – аның кызы. Чит кулларга бирергә җәлләдем малларымны. Үземә үзем урын тапмадым. Чистартмыйлардыр, карамыйлардыр, дим, ашарларына вакытында салмыйлардыр, авырып киткән сыерлар нишли икән? Башымда гел шундый сорау булды. Җаныма урын таба алмадым.

Мария Таймасова карамагында илле сыер, дидек. Иң алдынгы сыер савучыларга иң яхшы сыерларны сайлап биргәннәр. Моның хикмәте бар, әлбәттә. Башка сыерларны көненә ике мәртәбә саусалар, боларны көненә өчәр мәртәбә савалар. Сыерларны да, гадәттәгечә, иртән түгел, ә стресс алмасыннар дип, кичен юалар. «Болай иткәндә, сөт арта», – ди алдынгы сыер савучы. Февраль аенда гына да ул 24570 центнер сөт савып алган. Аның нинди һөнәр иясе булуын шушы күрсәткечләргә карап кына да чамалап була.

Хәзер ул, чыннан да, иң алдынгы сыер савучылар рәтендә. Районда, республикада гына түгел, ил күләмендә! Иң беренче зур җиңүе былтыр сентябрь аенда Татарстан буенча сыер савучылар арасындагы ярышта булды – «Абсолют батыр» булып калды. Хәзер аны Россия күләмендә үткәреләчәк ярышларга чакыралар.

– Каушап калмадыңмы соң?

– Юк, – ди ул, – ышандым үземә.

Түбән Новгородта узган бу ярышка илнең 56 регионыннан осталарның осталары җыела.

– Сөт аппаратын җыеп, эшләтеп җибәрергә кирәк иде. Кемдер 12 минутта, кемдер 15 минутта җыйды. Ә мин 4 минут та 20 секундта җыйдым. Аппарат эшләп киткәч, куануларым... Икенче урынга да куандым, иремә шалтыраттым. Ул да: «Молодец, булдыргансың!» – диде.

Мария күптән түгел генә булып узган «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесенең «Язмышым – һөнәрем» номинациясендә янә җиңү яулады.

– Бу бәйгедә җиңгәч, ирең, балаларың ни дип әйтте?

– «Молодец! Булдыргансың, диделәр», – дип елмая Мария.

Без дә бу сүзләргә бик теләп кушылабыз: «Булдырасың, Мария!»







ҖӘМГЫЯТЬ



■ Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов ТР Хөкүмәте йортында Дәүләт Третьяков галереясы директоры Зөлфирә Трегулова белән очрашты. ТР Мәдәният министры Айрат Сибагатуллин һәм «Казан Кремле» музей-тыюлыгы директоры Зилә Вәлиева катнашында узган очрашу барышында мәдәният өлкәсендә, музей эшендә хезмәттәшлек мәсьәләләре һәм Казанда Дәүләт Третьяков галереясы фондларыннан күргәзмә проектын оештыру турында сүз барды. Зөлфирә Трегулова Татарстан рәссамнары эшләре өчен экспозиция мәйданчыгы бирергә әзер булуын белдерде.

■ Казанда V Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыены узды. Анда Россиянең 36 төбәгеннән һәм Татарстаннан килгән эшмәкәрләр казанышлары белән таныштырдылар, тәҗрибә уртаклаштылар, татар авылларында эшләүче фермерлар, авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртүчеләр үз тармакларындагы проблемалар турында сөйләделәр. Җыелышның пленар утырышына килгән Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов милләттәшләребез башкарган эшләр белән горурлануын белдерде. Президент фикеренчә, эшмәкәрләр бик мөһим бурыч үти, алар татар авылын, туган телебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калырга булыша.

КОТЛЫЙБЫЗ



■ Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында алтынчы тапкыр «Тантана» республика театр премиясен тапшыру чарасы узды. Театр сәнгате өлкәсендә иҗади һәм иҗтимагый казанышлар өчен гамәлгә куелган бу премиягә быел 40 номинант дәгъва кылды. «Иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә Т. Миңнуллин исемендәге Түбән Кама татар дәүләт драма театры артисты Гүзәл Шәмәрдәнова җиңүче дип табылды.

МӘДӘНИЯТ

■ «Созвездие-Йолдызлык» Республикакүләм ачык телевизион яшьләр фестивале моңа кадәр Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов патронажында уздырылса, хәзер исә ЮНЕСКО оешмасы да кушылды. Бу хакта ЮНЕСКО эшләре буенча РФ комиссиясе секретаре Григорий Орджоникидзе фестиваль дирекциясе һәм лауреатлары белән очрашу барышында җиткерде.

■ Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының Санкт-Петербургта гастрольләре зур уңыш белән үтте. Ул камаллыларның «йөзек кашы» булган «Зәңгәр шәл» спектакле белән ачылды. Үзенең 110 нчы юбилей сезонында театр Петербургка 6 спектакль алып барган иде. Г. Товстоногов исемендәге Зур драма театры сәхнәсендә «Хуҗа Насретдин», «Гөргөри кияүләре», «Дон Жуан», «Банкрот», «Бабайлар чуагы» спектакльләре күрсәтелде.

■ Габдулла Тукайның 130 еллыгына багышлап, Казанда «И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!» фестиваль-бәйгесе уза. Анда төрле яшьтәге катнашучылар үзләрен «Нәфис сүз», «Театр сәнгате», «Бию», «Җыр», «Уен кораллары», «Гамәли сәнгать» номинацияләре буенча сыный ала. Алар 26 апрельдә Иске Татар бистәсендә узучы Гала-концертта исеме билгеле җырчылар белән бергә чыгыш ясаячак.

■ Татарстан халыклары Яшьләр ассамблеясе вәкилләре «Габдулла Тукай турында 130 факт» дип исемләнгән марафонга старт бирде. Анда һәркем катнаша ала. Марафонның төп геройлары – төрле милләттән булган Татарстан халыклары Яшьләр ассамблеясе вәкилләре. Алар Тукай тормышыннан булган вакыйгалар турында сөйләп, видеоязмалар әзерләячәк. Марафон барышында Инстаграм челтәренә шундый 130 видео эленәчәк.

МИЛЛӘТ

■ Бөтендөнья татар яшьләре форумы «Калеб» яңа буын җыены белән берлектә «JADIDFEST» – милли дизайн ярминкәсен уздырды. Мәскәүдән, Санкт-Петербургтан, Уфадан, Чаллыдан килгән яшь дизайнерлар, рәссамнар, музыкантлар, аш-су осталары анда үз эшләре белән таныштырды, «Кутуй һәм феминизм», «Такташ һәм аның хатыннары, 115 факт» лекторийлары узды. Рус телендә, ләкин татар мәдәнияте белән бәйле темаларга иҗат итүче Мәскәү язучылары Шамил Идиатуллин һәм Илдар Әбүзәров белән очрашу үткәрелде.

МӘГАРИФ

■ Татарстанның укытучылар әзерли торган вузларына 200 абитуриентны максатчан кабул итү күздә тотыла. Укытучы булырга теләүче чыгарылыш сыйныф укучыларын районнарда барлап, 800 кешедән гыйбарәт исемлек төзелгән, хәзергә укучыларның 400 е сайлап алынган. БДИ нәтиҗәләренә карап, арадан 200 е максатчан рәвештә кабул ителәчәк. Һәркайсына дүрт ел дәвамында 15 мең күләмендә айлык стипендия түләнәчәк.

СПОРТ

■ Казанда Су спорты төрләре сараена суга сикерү осталары җыела. FINAның суга сикерү буенча 2016 елгы дөньякүләм сериясенең IV этабында катнашучылар, Казанда Спортның су төрләре буенча XVI Дөнья чемпионаты җиңүчеләре — барлыгы 12 илдән 72 спортчы осталыкта көч сынаша. Ярышларны уздыруда төрле юнәлешләр буенча 74 волонтер ярдәм итәчәк. 18 судья хөкемдар булып катнашачак.



PRESSA.RU



АЛТЫ АВЫЛНЫҢ АЛТЫНЫ

ПЕНЗА КЫЗЫ ЭЛЬМИРА КАЗАНГА БАРЫРГА ЯРАТА. КИТӘ, КАЙТА, ТАГЫН ҖЫЕНА...

Күпме илләр, күпме шәһәрләр күргәне бар югыйсә. Ә Казан – башка! Аның ниндидер үзгә бер тарту көче бар. Хәзер инде бигрәк тә!



Эльмира
ЗАКИРОВА

Пенза өлкәсе хатын-кызларының «Ак калфак» иҗтимагый оешмасын җитәкли башлауга, Казан белән аралар тагын да якынайды: очрашулар, форум, киңәшмәләр... Аннан... Эльмираның үз эше, мөселман товарлары сата торган үз кибете дә бар бит әле! Менә ул тагын юлда. Машинасында Пензага кадәр килде дә поездга утырды. Аз да түгел, күп тә түгел – унике сәгатьлек юл. Казанга Пензадан 600 чакрым. Самолетта сәгать ярымда да килеп җиткәне бар анысы. Ә болай бераз ял итәр, кылган эшләрен барлап, планнар корып барыр. Әнисенең озатканда әйткән сүзләрен искә төшереп, елмаеп куйды: «И күптән инде барган юк Казанга. Барыр ием, багып чыгыр ием. Бик иректем инде Казанны...» Әнисе генә түгел, Эльмира да сагынды шул Казанны. Шушы сәфәрне, җай гына текелдәп баручы тәгәрмәчләр җырын сагынды. Купега кереп урнашуга, мәшәкатьләрен бер кырыйга куеп, хатирәләргә чумды.

Кикинныкылар

...Ни гаҗәп, вагон тәрәзәсе артыннан йөгереп калучы туган як урманнары, калкулыклар, авыллар, эреле-ваклы станцияләр Эльмираны ашыктырып-йөгертеп кенә балачагыннан ераклаштыра сыман. Җәйләрен абыйсы Илдар белән әби-бабай янына сагынып кайта торган бик кадерле Кикин авылы да артта кала. Эльмира атлы кыз бала да. Кикин ул – янәшә тезелеп утырган алты авылның иң зурысы. Кайчак «Алтавыл» яки «Алтын авыл» дип тә җибәрәләр аны. Качкару, Кобылкин, Решетин, Тиләтен, Мәчәли авыллары да шул алтылыкка керә. Шабай очында, Нижури урамнарында уйнап йөрүләр, коянтә белән су ташулар, сыер савып караулар, клубка чабулар... Машинасында җырчы Гүзәлиянең гел әйләнә торган «Авыл көйләре» монда инде күңелендә чыңлады. Район үзәгендә рус мәктәбендә укыган кызның татарча матур сөйләшүенә сокланалар. Каян өйрәндең дә каян өйрәндең, янәсе. Өйләренә бит «Азат хатын» килә! Журнал килү белән Эльмира, сүзләрне кызык кына әйтеп, татарча укырга тотына: аһ, шул «җ, ң, һ, ө, ү»ләр. Әнисе кызы артыннан дөресләп бара.

Эльмира, көзгегә күз салып, чәчләрен рәтләгәндәй итте. Көнбагыш чәчәгебез, Сары гәрәбәбез, Кояшыбыз дип йөртәләр аны яратып. Каре итеп кискән аксыл-сары чәчле ханым зәйтүн җимеше төсле яшькелт күзләре белән елмаеп карады: «Төс-кыяфәтем – әниемнән, холкым – әтинеке».

«Алла, әниеңнең яшь чагы инде гел!» – дип, әтисе бер генә кабатламагандыр. Нык холыклы, максат итеп куйса, башкарып чыкмый туктамый торган Эльмира белән горурлана Хәмзә абзый. Җае чыккан саен: «Кызым үземә охшаган!» – дип куя. Әнисе менә киң күңелле, йомшак, сабыр аның. Башында гел яулык булыр, гел намаз укыр, көн саен камыр ашлары пешерер... Кайчак кызы шелтәләп тә ташлый: «Хәлең дә юктыр, нигә инде бүген ул бәлеш?!» Ә ул шуларны пешерүдән рәхәтлек ала, ул шуның белән яши икән! «Мунча яктык, бәлеш салдым, килегез!» Шул сүзләре генә дә ни тора бит!

Әвеш-тәвеш...

Эльмира Каменка мәктәбендә укыганда немец теленнән гел «бишле»ләр ала иде, чит телләр факультетына укырга керәм дип хыялланды. Үзебезнең телдәге кайбер сүзләр белән немец телендәгеләр яңгыраш ягыннан гына түгел, мәгънә ягыннан да охшаш икән бит дип ачышлар ясады. Кара, Austausch сүзе товар алмашу дигәнне аңлата икән. Безнең әвеш-тәвеш була түгелме соң? Алыш-биреш, сәүдә, сату-алу, ягъни мәсәлән.

Әнисенең сеңлесе Фәридә бөтенләй көтелмәгән якка борды да куйды: Әстерханга технология техникумына бар, җәмәгать туклануы системасына бик кирәкле белгеч булып чыгарсың ди. Аннары Пенза педуниверситетының икътисад, идарә һәм хокук факультеты, бухучет һәм аудит белгечлегенә уку... Каменкадагы яшелчәләр консервлау цехына начальник итеп куйганда технолог Эльмира Карамышевага нибары 20 яшь иде. Озак эшләмәде ул. Үпкәсенә салкын тиеп, табиблар пневмония дигән диагноз куйдылар да, эштән китте. Һәм... Еракта калган вакыйгалар, матур сурәт кебек, Эльмира күз алдында балкыды. Фарсы култыгы яры буйлап сиксән чакрымнарга сузылган әкият-шәһәр, әфлисун төсендәге комлыклар, зәңгәр океан киңлекләре, елның 365 көнендә дә гел җәй, гел кояш булган җәннәт почмагы... Гарәп Әмирлекләренә китеп, Дубайда Фәридә апасы янына эшкә урнашты бит ул. Кибеткә сатучы булып. Бу эшкә хирыслык та нәселдән килә, әлбәттә.

Атаклы Муса һәм Заһир Бигиевләр, Муса Акъегет, Кәрим Тинчурин, Гадел Кутуйлар Пенза туфрагында туган дип өйләрендә гел әйтеп торалар.

Җомга саен Мәскәүгә йөреп, Кикин авылын товар белән тәэмин иткән Зөһрә әбисен, авыл халкына ит ташыган Сабирҗан бабасын сагынып күз алдына китерде. Бер уйласаң, Эльмира да шул ук эшне башкара бит инде! Менә кайчан кирәге чыга чит телләрнең! Инглизен дә, гарәбен дә өйрәнә. Үзлегеннән дә, китаплар аша да. Россиядән килеп эшләүче дус кызыннан да... Кайткач та, өч ел буена инглиз теле курсларына йөри. Өйрәнми кая барасың! Замана таләбе шундый булгач. Клиентларга нәрсә кирәк? Ни хакка, ничәү? Шунысы да бар бит әле: өйдә генә утыручы гарәп хатыннарының инглизчәсе бөтенләй юк икән! Эльмира гарәп сүзләрен җизнәсе Мөхәммәттән сорап, язып-язып куя. Итәкме, күлмәкме? Нинди төс ошый? Үлчәмнәре нинди? Баштарак әнә шулкадәресе җитеп тора. Дубайда эш җиңел булды дип әйтмәс иде. Ялларсыз, гел аяк өсте. Кибетләр төнгә тикле эшли. Иртән торасың да чабасың. Ике ел эшләгәннән соң, Каменкасына кайтып, тын алып килә. Тагын китеп бара. Кайталы-китәле апасы кибетендә эшли шулай. Һәм бер нәрсәне бик яхшы төшенә:



Әтисе Хәмзә дә, әнисе Румия дә шушы Кикиннныкылар. Алар «Каз өмәсе»ндә танышканнар. Быел «Ак калфак» белән «Каз өмәсе» оештырганда телевидение журналистына шул турыда сөйләде Эльмира. Казларны тиз-тиз йолкучы уңган, җитез Румиягә Хәмзәнең күзе төшә....

PRESSA.RU

тырышкан кеше булдыра икән бит! Апасының уңышлары аңа канатлар куеп җибәрә. Ул да үз эшен булдыра ала, димәк! Мөселман товарларын сата торган үз кибетен ачасы килә аның! Һәм ача да! Аның бит әле тагын бер уңган апасы бар! Мәскәүдә яшәп, сеңлесенә ярдәм итеп торучы Фәйрүзә тутасы! Алма агачыннан ерак төшми: Фәйрүзә дә – әнисенең бертуган сеңлесе! «Мөселман атрибутикасы» кибетен белмәгән кеше юк хәзер. Халык өзелеп тә тормый. Шуны алып кайт, моны алып кайт, дип заказлар бирергә килләләр. Доллар, евро бәяләре әле сикермәгән чакта Төркиясеннән дә, Гарәп Әмирлекләреннән дә товар ташый Эльмира. Хәзер кризис: кирәк әйберләрне Казаннан алып кайта. Халык рәхмәтләр укый, ярый әле шундый кибет бар, диләр. Кемгәдер никахка күлмәк, кемгәдер түбәтәй кирәк.

«Эшмәкәрлек мишәрнең канында ул. Эшсез тора алмый торган нәсел без...»

Мәҗлесләрдә сәдака итеп өләшер өчен яхшы яулыклар, дисбеләр сорыйлар. Бәясе арзан, сыйфаты яхшы булсын, диләр. Һәр мөселман белергә тиешле дога китапларын, татар календарьларын кайтарталар. Алары да кемгә – 50, кемгә 100 данә кирәк икән. Ул, елмаеп, Рамил белән Лилия никахын искә төшерде. Инде онытыла башлаган борынгы димләү йоласы белән кавыштырдылар ла яшьләрне! Эльмираны никах мәҗлесенә чакырдылар. Күз тимәсен, бик бәхетле яшиләр! Ул блокнотын ачып заказчылар исемлегенә күз йөгертеп алды. Тәк, тәк... Татарча җыр дисклары, татар концертларына билетлар... Боларын яшьләр сорый. Хәер, эшен шул концертлар оештырудан да башлап җибәрмәде микән әле? Артистлар чакыру, билетлар сату, заллар тутыру, реклама ясаулардан... Барысы да җырлап китте инде Каменкада. Килмәгән Казан артисты калмады. Эльмира экскурсияләр оештырып, туризмны да җайга салмакчы. Их, якташларын төяп Казанга алып барасы иде! Тинчурин, Камал театрларын, Бауман урамнарын, Кремльне, Колшәриф мәчетләрен күрсәтәсе иде шуларга! Май аенда Кикин мәктәбе укучылары белән Болгарга барырлар. Автобус белешеп куйды инде. Тукта, тукта... элеккеге Пенза губернасының атаклы Тархан авылы да әллә ни ерак түгел бит! Лермонтовның музей-тыюлыгы анда! Балачак, яшьлек елларын шагыйрь шунда – Арсеньевлар утарында уздырган. Әллә шуннан башласыннармы сәфәрне?..

Елама да, пошынма да!..

Телефоны шалтырап, уйларын бүлде: Дамир! Әнисенә хәерле сәфәр теле. Улы ясаган шәмаилләр талисман кебек: кайда да үзе белән йөртә аларны. Дамирга да тиздән 16 яшь тула! Казанда, архитектура-төзелеш академиясендә укырга хыяллана. Әтисе генә менә...

Дамирның әтисе белән Эльмира параллель сыйныфларда укыды. Начар егет түгел иде. Көннәрдән бер көнне күңелсез хәлгә тарыган бу. Әллә нинди гаепләр якканнар. Шунда бик кызганды аны Эльмира. Бәладән йолып каласы, ничек тә ярдәм итәсе килде. Шуңа күрә Карамышевларга Васильевлардан кыз сорарга башкодалар килеп төшкәч, кыз егетне җәлләп... кияүгә чыгарга ризалык бирде дә куйды! Никах укыту, туй ясаулар... Аннан Дамир туа... Аерылышу... Эльмира берүзе үстерә баланы. Менә шундый язмыш.

Эльмира Дамир шәмаилен сыйпап куйды: «Бар да яхшы булыр, Алла боерса». Әбисе аны кечкенәдән үк догалар укырга өйрәтте. «Аятелкөрси»не, «Әлхәм»не... «Син ятканда укы. Ни теләгәнеңне сора Ходай Тәгалә-







дән», – дия торган иде. Гел укый, гел сорый Эльмира. Булышалар. Тынычлап кала ул. «Елама да, пошынма да, уйлама да! Иң мөһиме – Ходай Тәгалә ташламасын сине ярдәменнән...» Боларын әнисе кабатлый. Капка төбендә утыручы күрше Рауза апасы әнә нәрсә ди: «Бөтен дөньяң җитеш, инде бер яхшы кияү дә тапсаң иде...» Чын күңелдән бәхет теләгән апаның үз сүзе сүз һаман: «Бәхет ул без ума, нәркәмәскә бара да куна», – ди мишәрчәләп. Нәркәмәс әрем була инде аларча. Ә Эльмира өчен бәхет башкачарак төсмерләрдә. «Оланым Дамир – терәгем, таянычым. Аны аякка бастырасым килә!» – ди ул.

Асыл затлар

Эльмирага карап, кыенмы аңа, түгелме икәнен белеп тә булмый. Кызмый, түгелми-чәчелми. «Кыенлыклар мине чыныктыра!» – дип кенә елмая. Хәер, булышчылары да җитәрлек анысы. «Ак калфак» оешмасында – укытучылар, эшмәкәрләр, китапханәчеләр. Бизнес-леди да, гинеколог та, социаль хезмәт күрсәтүче дә, мәдәният өчен җаваплы кеше дә – үзләрендә. Шалтыратуга ук җыелып бетәләр. Халкыбызның гореф-гадәтләрен, телен, мәдәни мирасын саклап калу өчен җан атып йөргән булдыклы мишәр хатыннары. Йөз меңгә якын татар яши торган Пенза өлкәсендә башкарган эшләре турында узган ел Казанда Бөтендөнья татар конгрессына җыелган хатын-кызлар алдында дулкынланып сөйләгән иде ул. Кульяулыклар чигү, энҗе калфаклар тегү буенча мастер-класслар да, мөселман товарлары һәм милли ризыклары белән 37 район һәм өлкә сабантуйлары витриналарын бизәүләр дә, «Әбикәй-матуркай», «Авыл кызы» бәйгеләре дә телгә алынды... Бу изге эшләрнең артында олы йөрәкле, тынгысыз кешеләр тора. Дус кызы, «Алтын куллар» кооперативы рәисе Фирдәвес Тумеркина, әнә, милли ашлар әзерләп, «Игелекле Пенза» акциясен үткәрде. Нурия Акҗегетованың тәрбиягә алган ун баласы бар. Яртысы урыс балалары, татарча сөйләшәләр, татарча җырлыйлар. Иганәчелек белән шөгыльләнүче Батрак авылы крестьян-фермер хуҗалыгы җитәкчесе Кадрия Акбулатованы ал тагын. Утызлап приют баласы өчен баллы кичәләр, пәрәмәч бәйрәмнәре уздырды, ветераннарга бүләкләр әзерләде. «Ак калфак» оешмасының мәгълүмат бүлеге мөхәррире Ләйлә Тренгулова да шундый ук: киң күңелле, ару-талуны белмәс...

Эльмира башкарылган эшләргә күңелдән генә исәп-хисап тотты. Инде ничә ел рәттән Кикин авылында талантлы татар балаларының «Одаренные дети» форумы уза. Пенза өлкәсеннән генә түгел, Мордовия, Татарстаннан килгән кызлар-малайлар да фәнни, иҗади бәйгеләрдә теләп катнаша анда. Быел Кикин авылы мең ярымга якын баланы кабул итте! Шигырь-әкиятләре, төрле проектлары, җыр-биюләре Грантлар, дипломнар, кыйммәтле бүләкләр белән бәяләнде. Бәкер Усман улы, гадәттәгечә, бүләкләрне мулдан әзерләгән иде. Бөтенесен бергә җыеп, берләштереп, яңа эшләргә илһамландырып тора ул. Кызык идеяңне әйт кенә, Бәкер Усманович күтәреп ала!

> *Никах икән, яшь киленне киендерәләр; кайгы килсә, әнәсеннән җебенә кадәр әзерләп куялар.*

Эльмира да чараларны Бәкер абыйсы булышлыгы белән уздыра. Җырчылар чакырырга кирәксә дә, чәй табыны әзерләсәләр дә, Бәкер Усманович бөтенесен шундук уңай хәл итә! Үзе дә татар концертларын, җырларыбызны ярата. Пензаның үзендә Җәмигъ мәчете төзү эшләрен кайгыртып йөри. Әле күптән түгел «Игелек балкышы» дигән зур хәйрия концерты булды. Аны да «Пенза өлкәсе татар милли-мәдәни автономиясе» оештырды! Пенза эшмәкәрләре билетларны үз акчаларына сатып алып, якташларына таратты, концерттан соң кергән акча мәчет төзелешенә күчерелде. Бәкер Усман улы бармаган авыл, ул булмаган мәктәп юк та өлкәдә. Иллегә якын татар авылларында булып, халык белән очрашып, аларның проблемаларын өйрәнеп йөр әле! Туган авылы Качкару исә Пензаның йөзек кашы сыман хәзер. «Татар авылларында бабаларыбыз традицияләрен дәвам итәргә, балаларыбызны туган телебезгә өйрәтергә кирәк», – дигән сүзләрен игелекле эшләре белән раслый. Ул салдырган ике катлы зур мәчет балкып тора: төннәрен Качкару урамнарына манараларыннан яшькелт нурлар тарала. Менә кемнән үрнәк алырга кирәк! Милләт дип, халкым дип яши торган асыл ир солтаны. Эльмира Бәкер абыйсының умарталар тотуын да, нәселле атлар үрчетүен дә (алар 200 ләп!) белә. Зур тамаша ясап, ат чабышлары үткәрергә хыялланууларын да... Шундый тынгысыз җан ул!

...Поезд Мордовия, Ульяновскиларны калдырып, Татарстан җирләре буйлап чаба. Казанга да ерак калмады. Эльмира якташлары, үзләреннән чыккан асыл затлар турында һичшиксез сөйләячәк әле. Пензаның Акҗегетовлары, Дәвликамовлары, Акчуриннары, Иртугановлары турында. Ул да шул татарның бер газиз баласы ла!



■ Милләтпәрвәр эшләрнең барысы да бер кешегә – «Пенза өлкәсе татар милли-мәдәни автономиясе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе, «КАГАУ» компанияләр төркеме директорлар советы рәисе Әбүбәкер Усман улы Акҗегетовка барып тоташа. Татар теле дәресләре укыту, балаларга татар китапларын өләшү, дини гыйлемнәр бирү, балаларны иҗатка, спортка, сәнгатькә тарту... Һәр чәршәмбе саен «Татар мәдәни үзәге»ндә уза торган милли-мәдәни автономия утырышларында боларның һәркайсы турында тәфсилләп сөйләшәләр.

PRESSA.RU

Әйе, без барыбыз да балачак иленнән. Башкортстанның атказанган икътисадчысы, зур абруй казанган хәйрияче, милләтпәрвәр эшкуар, «Ак калфак» Башкортстан татар хатын-кызлар ассоциациясе җитәкчесе Люция Җабир кызы ВАФИНАның балачак мизгелләре аның күңелендә онытылмас хатирәләр булып саклана. Әби-бабайлардан калган күңел ядкарьләре, гореф-гадәтләр, ата-ана тәрбиясе – безнең тамырларда. Шушы тотрыксыз заманда, күп акыллыбашлар, иманнарын җуеп, чит ил банкларында үзләренә «гигант мая» җыярга тырышканда, Люция ханымның, милләтем хакына дип, зур хәйрия чыгымнарына баруы, бу юлда ихлас тырышлыгы гаҗәп тә, гыйбрәтле дә.

Ләйсән КӘШФИЕВА



ЕГЕТЛӘРЧӘ!

шсөяр гаиләдә, иманлы нигездә әби-бабай, әти-әни тәрбиясендә туып-үсә ул. Вафиннар гаиләсе хезмәт белән яши.

Яшьлекләрендә Бакалы механизаторлар курсында танышып, гаилә корган Илеш кызы Тәхия белән Туймазы егете Җабир комбайнда гизгән кырлар Җир шарын урап чыгарга җитәр, алар суктырган иген Урал тавы кадәр булыр иде. «Әниемнең тракторчы, комбайнчы һөнәрен сайлавы аның бертуган апасы Саниянең – Баллый апаның Бөек Ватан сугышы елларында тракторчы булып эшләве, үсмер кызның аңа кызыгып каравы белән бәйледер», – ди Люция ханым. Гаиләдә авыл хезмәтенә генә түгел, китапка, шигъриятькә, җыр-моңга да хөрмәт зур. Су буенда каз бәбкәләрен саклаганда да, кичләрен сыер көткәндә дә Люция йотлыгып китап укый. Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури әсәрләре кызык та, кызганыч та булып, кызның рухи офыкларын киңәйтә.

Математиканы су урынына эчкән, химия-биологияне яратып укыган Люция медицина университетын сайлый. Абитуриентлар күп, конкурс зур. Документлар тапшырырга көн буе чиратта торган кызны кире боралар, янәсе паспорттагы фамилия белән аттестаттагысы туры килми: Хазиева – Хазеева, имеш. Кыз, документларын алып, авиация институтына юнәлә, монда да кабул итү комиссиясе, фотолар сорап, аны кире бора. Фотога төшеп йөргәндә очраткан авылдашы Люцияне авыл хуҗалыгы институтының яңа гына ачылган икътисад факультетына димли. Ризык кайда – бәндә шунда, диләр. Монда исә авыл баласына артык бәйләнеп тормыйлар...

«Танцыларга йөрмәдем, театр-концертлар карарга яраттым, күп вакытым китапханәдә үтә иде», – дип искә ала Люция ханым студент елларын. Курстагы 150 студентның тугызы гына егет. Аның да өчесе гарип, берсе өйләнгән, икенчесе өйләнергә йөри. Яхшы укучы, тырыш, җитди холыклы кыз өлешенә дә берәү калган икән әле. Һәм алар өченче курста укыганда ук, күпләрне көнләштереп, гаилә корып җибәрәләр.

Ике яшь белгеч «Бүздәк» совхозында хезмәт юлын башлый. Баш икътисадчы итеп тәгаенләнгән Люция бу урынга ирен димли, үзе, булачак әни, гади икътисадчы урынын сайлый. Краснокама районының «Беренче май» колхозында баш бухгалтер һәм баш икътисадчы булып кулга-кул тотынып эшләүләре дә нәтиҗәсез үтми. Алар әле дә Люция ханым төзегән технологик карталардан, хисаплау алымнарыннан файдаланалар.

Эшне җиренә җиткереп башкаручы, зиһенле, фидакарь икътисадчының тора-бара республика дәрәҗәсендә эшләве гаҗәп түгел. Башкортстан Авыл хуҗалыгы министрлыгында, Дәүләт банкында. «Восток» коммерция банкында, Республика салым инспекциясендә, «Башнефть» компаниясендә генераль директорның финанс мәсьәләләре буенча урынбасары, баш бухгалтер булып эшләгәндә дә ул үзен югары әзерлекле, заманча фикерле белүче, зирәк белгеч һәм җитәкче итеп таныта. «Россиянең иң яхшы бухгалтеры», «Россия бухгалтерлык хисаплау системасы отличнигы» дигән һөнәри дәрәҗәләргә ия була ул.

Икмәк – изге башлангыч

Икътисадны яхшы белгән җитәкче 2002 елда үз бизнесын башларга ният кыла. Башкалар төшемле юнәлешләрне сайлаганда, ул икмәккә мохтаҗлык кичерүче бер авылның күптән гамәлдән чыккан ипи пешерү цехын җиһазлый. Икмәк пешерү – изге һөнәр. Моңа бабасы сөйләгән хәдисләр аша инанган Люция ханым авырлыклар алдында каушап калмый. Аңа бер үк вакытта ипи салучы да, технолог та, директор да булырга туры килә. Эчүдән тилергән урыс авылы халкын эшкә күнектерү җиңел булмый. Тырыша торгач, Ходайдан бәрәкәт килә: ипи пешерү цехы авылны гына түгел, Уфадагы кайбер хастаханәләрне дә колмаклы ипи белән тәэмин итә башлый. Соңрак изге икмәк эшкуарлыкның киңрәк юлларын ача. Икмәк пешерү эшен улына тапшырып, Люция ханым объектлар төзүгә тотына, бизнесны үстерү консультатив үзәген ача.

Җанга дәва эзләп

Адәм баласы матди житешлек белән генә канәгать булып, үзен бәхетле хис итсә, рухият дигән илаһи дөнья бетәшеп калыр иде. «Дөньяда беркем дә юата алмас чаклар була. Шул вакытта мин кулыма үз ана телемдә язылган китапларны алам яки туган телдә җырлар тыңлыйм, театрга барам. Дөнья ыгы-зыгысы онытыла, күңелем ял итә, җанга көч иңә», – ди язмабыз каһарманы. Аның тирәсендә һәрвакыт сәнгать әһелләре, каләм ияләре, сәхнә осталары бөтерелә. Кайсына музыка коралы сатып алырга, кайсына концертларын оештырырга ярдәм итә ул.

Менә инде ничә еллар Люция Вафина республика сәнгате, мәдәнияте үсешенә матди яктан ярдәмләшә. Сәбәбы кимүдән куркыпмы, болар хакында тәфсилле сөйләмәүне хуп күрә ул. Ләкин аның «Рамазан» милли агарту үзәгенә, төрле өлкәләрдә Сабантуйлар үткәрүгә, «Туган тел» татар җыры бәйгесен оештыруга ясаган хәйрия ярдәме хакында судагы балык та, халык та белә. Юкка гына ул Бөтендөнья Татар Конгрессының мактау язулары, «Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты» белән бүләкләнмәгән. Ә 2014 елда эшлекле, булдыклы ханымны «Ак калфак» Башкортстан хатын-кызлар ассоциациясе рәисе итеп сайлап куйганнар иде.

– Безнең максат – милли гаиләләрне саклап калу, гаиләдә хатын-кызның статусын күтәрү, илебезгә тәрбияле, иманлы балалар үстерү, телебезне, динебезне, гореф-гадәтләребезне, йолаларыбызны саклау, – ди Люция Җабир кызы. – Бүгенге глобализация шартларында безгә күркәм милли йола-гадәтләрне югалту куркынычы яный. Интернет, телевидениедәге йөзләгән каналлар ипле гаилә идеалын тудыра, дип әйтеп булмый. Әнә шул юнәлештә «Ак калфак» оешмасы эзлекле эш алып бара да инде. Нибары ике ел эчендә Башкортстанның дистәләп район һәм шәһәрендә «Ак калфак»ның бүлекчәләре барлыкка килде. Аларда «Минем гаиләм татарча сөйләшә», «Татар гаиләсе – матур гаилә», «Исемең матур, олан» кебек эчтәлекле чаралар узып тора.

Люция ханым ярдәмгә мохтаҗ кешегә игелек кылудан бетмәс рәхәтлек кичерә, зур ләззәт ала.

«Ак калфак» оешмасы республикада узган бер генә милли чарадан да читтә калмый, Люция Вафинаның шәхси матди ярдәме милли рухиятебезне үстерүдә бәяләп бетергесез.

Күптән түгел Уфа мәркәзебездә яңа гына сафка басучы «Вафа» бизнес үзәгендә милли китапханә ачылды. Анда Татарстаннан һәм Башкортстаннан күренекле милләтпәрвәр затлар катнашты. Бу хакта «Сәхибҗамал» татар хатын-кызлары җәмгыятенең шәрәфле рәисе Динә Морзакаева болай диде:

– Заманыбыз шундый: көн тудымы, яңа базарлар, сәүдә нокталары ачыла. Күпләр, халык җисми мәнфәгатьләрен генә кайгырта, дип зарлана. Һәм менә могҗиза! Люция Җабир кызы Уфаның нәкъ үзәгендә милли китапханә ачты! Милләт коты – китап икәнлеген, тик әдәбият, мәдәният белән генә халкыбызның телен, димәк, халыкның үзен саклап калырга мөмкин булуын аңлаган зирәк акыллы, зыялы, ифрат та булдыклы ханымның бу гаярь гамәленә афәрин!

Быелгы Мәүлид бәйрәмендә без Люция ханымның әнкәсе Тәхия апа белән бергә булдык. Балалар турында сүз чыккач, ул: «Бер генә кыз үстердем, берәгәйле кыз үстердем», – диде. Шундый дәвамыңа куана алудан да зуррак шатлык бармы әниләр өчен?!

Башкортстанда Люция Вафина яккан рухи учакта җылынучыларның исәбе-хисабы юк. Кемнән сорасаң да, аның турында сокланып, хозурланып, тирән рәхмәт хисләре белән сөйлиләр.

PRESSA.RU



...Эльмирасы бик еракта хәзер, океан аръягында ук. Нью-Йоркта яши. Казанның инглиз мәктәбен һәм КАИның җәмәгатьчелек белән багланышлар факультетын «бишле»гә генә тәмамлаган кызның күңеленә офык артына бару хыялы керә. Ул Америкага, Филадельфиягә үк китеп бара. Анда югары уку йортын уңышлы тәмамлап, рестораннар һәм кунакханәләр бизнесы буенча белгечлек алып чыга.

– Башыңны эшләтсәң, якты йолдыз кебек юл күрсәтүче максатың булса, чит илдә дә югалмыйсың икән ул! – Роза ханым шулай ди. Һәм кызы турында сөйләп китә. – 21 яшьлек кыз бала, язмыш дилбегәсен тотып, кесәсенә 500 доллар салып чыгып киткән иде Америкага. Бер айдан соң ул акчаны безгә кире җибәрде инде. Эшләде дә, укыды да. Укуына үзе түләде. Хәзер Нью-Йоркның Манхеттенында, Мәскәүнең Кызыл мәйданы кебек үзәк урында, зур гына бер компаниядә директор урынбасары булып эшли... Кешегә сөйләсәң, кеше ышанмас: Казансу елгасы буенда үскән татар кызы Гудзон ярларында яшәүче америкалыларга инглиз телендә җыелышлар үткәрә. Филадельфиядә укыганда студентлар фестивалендә катнашып, укытучыларын да, ректорны да Рөстәм Яхин романсларын фортепианода уйнавы белән шаккаттырган. «Талантлы татар кызы» дигән дәрәҗәле исем биргәннәр аңа шунда. Тырыш, максатчан ул безнең. Кечкенәдән ике мәктәптә дә «бишле»гә генә укуы да ярдәм иткәндер, мөгаен: беркайчан артта калырга яратмады! Тырышлыгын Америкада да бик тиз күреп алдылар!

ТАТАР КЫЗЫ СЫНАТМАС!

Йолдыз ШӘРАПОВА

«Безнең әни «Сөембикә» журналын дога китаплары янына куеп саклый... Гөнаһ түгел ич инде бу?!» – дигән иде яңа танышым Роза ханым Идиятуллина. Ә мин басма матбугатны изгегә санап яшәүче, гомеремне дә шуңа хезмәт итүгә багышлаган журналист: «Ю-у-ук, билгеле, – дип суздым. Ниндидер кызыклы хәл турында ишетергә өметләнеп: – Кайсы санын? Ни өчен?» – дип кызыксына башладым.

Роза апа әнисенең догалыклары арасыннан «Сөембикә» журналының 1999 елгы ноябрь санын алып бер битен ачты да миңа сузды – «Әбиемнең ак яулыгы» дигән язма. Кат-кат укып чыксам да, яңа танышларым турында бер җөмлә дә тапмадым. Авторы да алар түгел. Тукта, тукта... Язманың бөтен битен нурландырып торучы ак яулыклы әби белән оник фоторәсемендә Роза апаның әнисе Лена һәм кызы Эльмира икән бит! Дәү әнисе күп кенә догаларны яттан белгән оныгын – 15 яшьлек кызны – Коръән укучы балалар конкурсына алып килгән булган. «Кайсы мәчеттән килдең, балам?» – дигән сорауга: «Мине дәү әнием өйрәтте», – дигән кыз, икенче урынны яулап, дәү әни мәктәбенең сыйфатын да исбатлаган. Фотожурналист Газинур Хафизов дәү әни белән оникны нәкъ менә шул бәхетле мизгелдә төшереп алган. Журналда бу хакта, гомумән, алар турында язылмаса да, туксанга якынлашып килүче Лена әби үзләренең сурәтләре төшкән «Сөембикә»не бик еш кулына ала икән.

...Дәү әнисе оныгының уңышларына сөенә. Ләкин бик сагына ул аны. Үлеп китәрмен дә күрми калырмын дип борчыла әбекәй. Тынычланыр өчен тагын догаларын кабатлый. Хәтереннән генә гомер йомгагын кирегә сүтә башлый.

1929 елның чәчәкле җәендә Азнакай районының Әлкәй авылын-

да укытучы гаиләсендә дөньяга килгән Лена бик яшьли әнисез кала, ятимлек ачысын татый. Бөгелмә педучилищесын тәмамлаган кызны Әлки районы Чиябаш мәктәбенә укытырга җибәрәләр. Әлкәй авылы кызы Әлки районында яши башлый. Севастополь хәрабәләрен төзекләндерүдә катнашып, хәрби бурычын үтәп кайткан комбайнчы егеткә кияүгә чыга. Тату гаиләдә ике малай, өч кыз үстерәләр. Балаларны иманлы итеп тәрбияләүдә кайнанасы Зәйнәпнең дә өлеше зур була. Бүгенге көндә Лена апа бик бай дәү әни: ун оныгы, алты туруны бар. Эльмира шул алты оныкның иң сагындырганы иде моңарчы. Сагындырган оныклар рәтенә Эльвина да өстәлде менә. Банк мәктәбен тәмамлап, анысы да Мисырга эшкә китте. «Тиздән кайтам, дәү әни!» – дип скайптан шалтырата. Оныклары белән аралашкан саен намазлыгы өстенә утыра да: «Дөньялар гына тыныч булсын! Сугышларга юл куйма, Ходаем!» – дип ихластан күз яшьләре белән дога кыла әбекәй. Сугышның нинди газаплар китергәнен яхшы белә ул. Намазлы, динле ак әби адәм балаларын тәкъдире, эчәр суы йөрткәнен яхшы аңлый, әлбәттә. Әнә бит, кызы Роза эчәсе суның да шактый тамчысы океан артында булган. Ул да инде Эльмирасы янына әллә ничә мәртәбә барып кайткан. Эшсез торуны күз алдына да китерә алмаган ханым Америкада да шөгыль тапкан. Көннәре яңа танышлары белән аралашып үтсә (араларында татарлар да шактый – *Й. Ш.*), күңелендә йөрткән туган як чәчәкләрен сәйләннәрдән тезеп, кичләрен картиналар ясаган.

Роза Идиятуллина менә тагын Америкага җыена. Әле күз көне генә Польшадагы кодагыйларына Краков шәһәренә кунакка алып барганнар үзен. «Бик әдәпле, тәрбияле бала, – ди Роза апа кияве турында, сөенечен яшермичә. – Кызымның һәвәслеген белгәч, кияү синтезатор бүләк итте. Икәүләшеп «Су буйлап»ны җырлыйлар хәзер. Кияүгә Татарстан гимнын башкару да ошый».

– Америка якын ич ул – океан артында гына! Бер үк Җир шары лабаса! – Роза ханым шулай дияргә ярата. – Безнең балалар анда төрле милләт кешеләре белән бик дус яши. Уңъяк күршеләре – украин хатыны, сул яктагысы – поляк. Гает бәйрәмнәрендә аеруча күңелле була. Таба ашлары пешереп, үзебезгә кунакка чакырам. Дөньяда Татарстан дигән ил барын һәм анда кунакчыл һәм уңган халык яшәвен белсеннәр дип тырышам, – ди ул. Ирен, алтын бәясенә тиң Маратын, шәфкатьле кайнанасын сагынып куя – алар инде бакыйлыкка күчкән. Улы, спорт мастеры Ленар турында горурланып сөйли, аннары тагын Эльмирага күчә:

– «Сөембикә»нең ниндидер тылсымы бар бугай. Кызым 15 яшендә аның битләрен бизәгән иде – журналның аягы җиңел булды. Хәзер инде Эльмира хакында Америка журналларында да язалар. Хәер, безне әнкәйнең догалары саклыйдыр инде, – ди Роза ханым.

Мин аны тыңлап, кухнясының буеннан-буена ябыштырылган Нью-Йорк небоскреблары (күктерәүләре) рәсеменә карап, Польша конфетлары белән чәй эчкәндә, биргән бит Ходай тәвәккәллекне бу нәселгә дип сокланып утырам. Аны тыңлаган саен, Кояш



Кызымның уңышлары өчен татар теленә, милли моңнарыбызга рәхмәтлемен.

тирәсендә әйләнүче Җир шарының барыбыз өчен дә уртак йорт булуына ныграк инанам. Океан артында булса да, дуслар, танышлар яшәгәнгә инде миңа да көннән-көн якыная барган Америкадагы Нью-Йорк шәһәренең Манхеттенындагы бер йортта Татарстаныбызның бер почмагы булуга, анда туган телебез, моңлы көйләребез, изге догаларыбыз яңгыраганга җаныма горурлык хисләре тулуын тоям.

КИТСӘЛӘР ДӘ – КАЙТСЫННАР!

«Гыйлемне, Кытайга барып булса да, ал!» – дип васыять әйтеп калдырган бабайларыбызның теләкләре тормышка аша бүген. Дөнья илләренең чикләре ачылгач, сәләте яшьләргә чит илләрдәге атаклы университетларның да ишекләре ачылды. Ул яктан республикабыз яшьләре аеруча бәхетле. 2006 елдан башлап Татарстанда «Алгарыш» грантлар программасы эшләп килә. Россиядә дә беренче булган бу программа Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов тәкъдиме белән оештырылган иде. Ул берьюлы ике бурычны хәл итә. Беренчесе – дөнья университетлары биргән белемгә ия югары квалификацияле яшь белгечләр белән тәэмин итеп, республикабызның абруен арттыра, икенчесе – сәләтле яшьләрне күреп алып үстерә, аларга фән белән шөгыльләнер өчен уңай шартлар тудыру юнәлешендә һәртөрле ярдәм күрсәтә. Әлеге грант конкурсында катнашып җиңү яулау 35 яшькә кадәрге талантлы белгечләргә, галимнәргә, укытучыларга АКШ, Бөекбритания, Ирландия, Германия, Франция, Австралиянең дәрәҗәле уку йортларында белем алу мөмкинлеге бирә. Уку, яшәү, юл чыгымнары бушлай. Диплом алып, магистратурада укый башлаган яшь белгечләргә игътибар аеруча зур. Гыйлем һәм тәҗрибә туплап кайтып, өч ел дәвамында (монысы мәҗбүри) республиканың икътисадын, халыкның тормыш дәрәҗәсен тагын да югарырак күтәрү юнәлешендә эшләргә юл ача. «Алгарыш» – республикабыз җитәкчеләренең Татарстаныбызның киләчәге турында кайгыртып, алга карап эш итүләрен күрсәтүче программа.

PRESSA.RU



БИЕКЛЕККӘ ОМТЫЛЫШ



Фәнзилә МОСТАФИНА

«ПИРАМИДА» КОНЦЕРТЛАР ЗАЛЫНДА ҖЫР БӘЙРӘМЕ. ӘЛЕ КӨЙ УЙНАМЫЙ ДА, Ә КҮҢЕЛ ТҮРЕНДӘГЕ НӘФИС ЧӘЧКӘ, КОЯШНЫҢ БЕРЕНЧЕ НУРЫН КҮРГӘНДӘЙ, ТАҖЛАРЫ БЕЛӘН ЮГАРЫГА ҮРЕЛӘ ДӘ ИНДЕ...

Җыр башлансын гына: күңел бакчасының коргаксый башлаган туфрагы туеныр, саргайган яфракларга яшеллек иңәр, гөлнең таҗларына нур кунар. Сулыш алуларга кадәр җиңеләеп китәр.

Күңелләрне баета торган җырлы тамашалар еш булып тора анысы. Һәрберсенең үз тамашачысы, үз атмосферасы. Менә апрель башында үткән «TMTV» премиясен тапшыру тантанасы да үзенең тамашачысын тапты. Беренче коймак иде әле бу. Телевизордан «MTV», «МУЗ-ТВ» премияләрен тапшырганны караган бар, тик яңа гына тәпи киткән татар музыкаль каналлары алар белән ярышырга алыныр дип уйлаган да юк иде. Ә «TMTV» өлгер булып чыкты. «Музыкаль биеклек» дип аталган премиясен булдырып та куйды.

45 номинация, җиңүгә дәгъва кылучы 150 җырчы... 50 сенә менә бәхет елмайды: татарның тәүге музыкаль премиясен беренче булып кулларына алдылар. Араларында җыр сәнгатенә зур өлеш керткән Хәмдүнә Тимергалиева, Халидә Бигичева, Зөфәр Хәйретдинов, Хәния Фәрхи, Айдар Галимов, Нәфкать Нигъмәтуллин, Рәсим Низамов һәм башкалар бар. Шулай да лауреатларның күбесе – яшьләр. Татар дөньясының төрле почмакларыннан Казанны яуларга



килеп, кичә-бүген генә сәхнәгә чыккан яшь башкаручылар. Бу премиянең башлыча аларныкы булуы дөрес тә! Татарстанның атказанган артисты Рәсим Низамов белән килешми мөмкин түгел: «Бирелсен яшьләргә! 25-30 елдан соң да сәхнәдә булсалар, димәк, әлеге премия аларга юкка гына бирелмәгән була».

Бәйге рәвешендәге мондый чараларның күп булуы әйбәт – җырчылар бер урында гына таптанып тормый, эзләнә, тамашачыны шаккаттырырга тырыша. «Музыкаль биеклек» сынын тапшыру тантанасында да сюрпризлар байтак булды. Татар сәхнәсенә Элвис Пресли чыкты (тамашачылар Гүзәл Уразова белән парлап җырлаучының Илдар Хәкимов булуын танып алды, әлбәттә), Илсөя Бәдретдинова һавага «акчалар» очырды. Яшь башкаручылар Лилия Хәйруллина белән Лилия Гыйматдинова башкалардан күпкә биектә – шакмак рәвешендәге тимер каркасларга басып җырлады. Премиянең исеме җисеменә туры килсен, дигәннәрдер, күрәсең.

Ә кемдер сәхнәгә бернинди махсус эффектларсыз, хәтта биючеләрдән башка гына да чыкты. Аларга ярдәмче чаралар кирәкми дә иде. Залга җыр агылды, моң агылды... Филүс Каһировка «Кабатланмас тавыш иясе» дигән бәһа бирделәр. «Бу номинациядә җиңүем икеләтә куанычлы. Бер җырымны гына түгел, гомумән, иҗатымны бәяләделәр дип аңлыйм мин моны», – дип хисләре белән уртаклашты ул соңыннан, сәхнә артына кергәч.

Уен-көлке белән үрелеп барган җыр-биюле чарада барлык тамашачыларны берьюлы елатып була, дисәләр, ышанырсызмы? Ә «TMTV» премиясе тапшыру тантанасында бөтен зал елады. Арабыздан вакытсыз киткән Татарстанның һәм Башкортстанның атказанган артисты Вәсилә Фәттахованы искә алып, экраннан аның соңгы клибын караганда, күз яшьләрен тыеп булмады шул. Оештыручылар аны онытмаган. «Музыкаль биеклек» сыны, җырчының иҗатын бәяләү билгесе булып, Башкортстанга – Вәсиләнең ире һәм балалары янына китәчәк.

...Сәхнәдә чәлпәрәмә килеп тәлинкә ватыла. Тамашачы бер мәлгә сагаеп куя: чү, нәрсә булды бу? Ә-ә, Булат Бәйрәмов белән Ләйсән Гыймаева җырлый, рәвешен китергән булып, тәлинкәләрне идәнгә очыралар икән. Бәхеткә юрыйлармы әле? Ә без премиянең гомерле булуына, сыйфат билгесенә әйләнүенә юрыйк!

PRESSA.RU



И. Айдаров. «Тукайның мәхәббәте – Зәйтүнә Мәүледова».

Шагыйрь мәхәббәте дигәндә без Зәйтүнә Мәүледованы күз алдына китерәбез. «Кайдан алсын шигъре шагыйрь, булмаса илһамчысы?!» «Наз итәр кемнәргә гөл — каршында былбыл булмаса?» «Бирмәде Ләйлә кеби мәхбүбәгә дөнья бәһа; Ул болай бер кыз гына — каршында Мәҗнүн булмаса...» Кем соң ул Зәйтүнә?



Роза КАМАЛЕТДИНОВА

ҖАННАН САРКЫЛГАН МОҢ

Пәйгамбәргә тиң шәхес – бәләкәй Апуштан зуп-зур Тукай булган, егерме җиде яшендә җир куенына кереп яткан әдип бай әдәби мирас калдырган. Аның рухани дөньясын һәр буын үзенчә ача. Ул яшәгән чор, яшәү кануннары һәм, әлбәттә, шагыйрьнең серле, яшерен мәхәббәте әле дә булса күпме күңелләрне дулкынландыра. Шагыйрь гыйшкы – ачылмаган сер, никадәр шигырь-поэма, музыкаль әсәрләр тууга сәбәпче булган. Замандашларының истәлекләреннән күренгәнчә, шагыйрь хатын-кыз затыннан, ни сәбәпледер, ерак йөрергә тырышкан. Ләкин ул яр сөймәгән, гыйшык утында янмаган дигән сүз түгел әле бу. Күңелендәге саф-садә хисләре энҗе бөртекләредәй гүзәл әсәрләргә әверелә: «Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер

йөрәк, парә-парә кисмәсә гыйшык-мәхәббәт кайчысы...» Яки: «Мәхәббәт төрлечә: йолдыз ул күктән атылган җиргә, Генрих Гейнечә...» Ләкин ни аяныч, туры килгән урыны чүплеккә!

Тукайның мәхәббәт лирикасы хакында сүз алып барганчы шагыйрьнең гаиләгә, парлы тормышка мөнәсәбәтен күздән кичерик: «Өч кешедән дөньяда качып котылып булмый: берсе – кендек әбиседер ки, ул сине теләсәң дә, теләмәсәң дә дөньяга тартып чыгарыр. Икенчесе – яучы карчыктыр. Ул сине, аласы кызыңны күрсәң дә, күрмәсәң дә, алырга теләсәң дә, теләмәсәң дә – өйләндерер. Өченчесе – мәзиндер. Ул сине теләсәң дә, теләмәсәң дә – җуар да күмәр», – дип яза да шәрехләп куя: «...теләмәсәң дә өйләндерер... Юк, ул алай булмый шул...» «Әгәр булса «сөю...» кочаклау куллар арганчы, үбү булса әгәр чут-чут, ирен һәм бит кабарганчы – гомер дә сөйгәнем юк һәм «сөям» дип әйтмәмен һич тә; сөюнең мәгънәсе минчә, бигүк гали, бигүк нечкә».

«Өйләнү – түгел сөйләнү... Гаилә хакында минем фикерем коры гына: әгәр... син – аны, ул сине якыннан белеп яратышсаң, шуның өстенә гаилә оятлы булмасын өчен, иң азында ел тәүлегенә биш йөз тәңкә килерең булса, һәркемгә өйләнү тиеш. Югыйсә эчеңә сәнәк белән төрткәндә бер тамчы кан чыкмаслык булса, ике күңелдә чын мәгънәсе белән мәхәббәт уты янмаса, гаилә өчен әллә нинди түбән кешеләргә тәлинкә тотарга булса – Алла сакласын!»

Зәйтүнә

Чистай кызы Зәйтүнә Мәүледова 1907 елның җәендә әниләре белән Казанга күченеп килә. Бер ел элек – туганнарына кунакка килүендә Фатих Әмирханның энесе Ибраһим аны, иптәш кызлары белән, «Әльислах» басмаханәсенә алып кергән була. Тукай белән беренче очрашу тәэсирләнүчән туташ күңеленә мәңге онытылмаслык булып уелып кала. Көндәлегенә: «Тукай кара пинжәк, буйлы ак күлмәктән, галстуктан, үзе яланбаш иде, – дип язып куя. – Ул күрешкәндә безгә бер генә караш ташлады, аннан кулларыбызга текәлеп кенә: «Исән-сау йөрисезме?» – дип куйды. Мин күзләремне аннан һич аера алмыйм...»

Алар әдәби кичәләрдә очрашалар. Тукайга бу чакта егерме ике яшь, Зәйтүнәгә унбиш тулмаган әле. Ләкин Казанда кыйммәтчелек, тормыш итү авыр булганга гаилә кире Чистайга кайтып китәргә ниятли. 1908 елның җәй башында Зәйтүнә дус кызы белән Тукай янына саубуллашырга килә. «Тукай чыкты, – дип яза ул көндәлегенә, – күрештек. Бергәләп урамга чыктык. Чистайга бөтенләйгә китәчәгебезне әйттем. «Бик җәл», – диде ул, башын иеп».

Тукайның бик нык күңелсезләнүе авыру аркасында дип белеп, кыз кат-кат аның сәламәтлеге хакында сораштыра. Кызлар шагыйрьгә хат язарга теләүләрен әйтәләр. «Мин сезне озатырга төшәрмен, шунда адресны бирермен», – ди Габдулла. Ләкин ул төшми. Бераздан «Кызык гыйшык» исемле шигырь басыла. Эссе көндә берәүнең салкын суны җилкә аркылы читкә сибүен, «әл дә тимәде» дип шатлануын тасвирлый шагыйрь. «Мин моны яздым, бу – гыйшкым миследер; / Чөнки гыйшкым нәкъ минем шул төследер, / Мин сөям, хәтта ки гакълымнан шашам – / Сөйгәнемнән шүрәле төсле качам...»

«Керпе үзенең кабыгына кереп яшеренгән сыман сөю турында бер шигырь язсам, ялган имзалар астына сыгынамын». Тукайның «Шүрәле», йә «Мәҗнүн» тәхәллүсе куеп бастыруы да: «Әмма ләззәтле дә соң яшерен газап, яшерен яну! / Бар микән, белмим, моның миннән бүтән аңлаучысы?.. / Кул-аяк бәйле, котылу кайда! – сихерләнгәнмен», – дип йөрәк серен ошбу шигырьдә ачуы да күпне сөйли. «Мин сөям, хәтта ки акылымнан шашам. / Сөйгәнемнән шүрәле төсле качам... / Белми китте, күп шөкер, – дип шатланам. / Бер хәбәр бар: ул хәзер киткән бугай, / шәһренә күптән барып җиткән бугай...»

1910 елның җәендә Габдулла Кариевлар труппасы Чистайга килә. Кариев Зәйтүнә туташны эзләп таба, аңа Тукайның контрамаркалар бирергә кушуын әйтә. «Тукайның сезнең хакта язган әсәрләрен күргәнегез бармы?» – дип сорый. «Юк. Кайсы шигыре минем хакта?» Кариев Тукай җыентыгын ача да «...гә» дигән шигырьне күрсәтә. «Язгач та миңа укыды, бу кем турында дип сорады. Мин бит коръәнхафиз, сезне белмәсәм дә Зәйтүнә исемле берәр туташ турындадыр дигәч бик шатланды». Шул очрашу вакытында Кариев Тукайның үзенә биргән фоторәсемен: «Һәдияне – һәдия», – дип язып, Зәйтүнәгә бүләк итә.

> *«Гөл кадерен былбыл белер, асылташ кадерен – белгече».*

Зәкия апа

Нәкъ егерме ел элгәре без Тукайның тамырларын, нәсел-нәсәбен ачыклап, шәҗәрәсен төзүгә, шагыйрь тормышына, иҗатына бәйле тарихи мәгълүматлар җыеп, киң җәмәгатьчелеккә җиткерүгә күп хезмәт, көч куйган галимә Зәкия апа Рәсүлева – Зәйтүнә ханымның килене белән әңгәмә корып утырган идек.

Зәкия апаның әнисе ягыннан бабасы Мөхәммәтгали Сабитов Казандагы Әҗем мәчете мәхәлләсендә мәзин була. Татарча чыккан матбаганы укып, әдәби мохит белән таныш, Тукай иҗатыннан да хәбәрдар булгангадырмы, шагыйрь вафатыннан соң бер төркем язучылар килеп, Габдулланы юып кәфенләүне аңардан үтенәләр. «Мескен шулкадәр беткән, шулкадәр ябыккан, катырак тотармын да тәнен авырттырырмын, дип, кызгана-кызгана юып кәфенләдем. Җеназа укыганда да, гүргә иңдергәндә дә аның белән бергә булдым», – дип сөйли ул Зәкия туташның әнкәсенә. Зәкия үскән гаиләдә Тукай әсәрләрен һәммәсе яттан белә. «Тукай җеназасын сурәтләгән рәсемнәрдә дә дәү эти бар», – дип сөйләгән иде безгә дә Зәкия апа. «Үсмер чактан ук без Кырлайга гел кайтып йөрдек. Җизнәбез Хәлилрахман Гобәйдуллин Тукайның Кырлайдагы остазы Фәтхерахман мелла Гобәев улы иде. Тукай яратып йөргән Зәйтүнәнең киле-

PRESSA.RU

не булуны насыйп итте миңа язмыш. Кайнанамның истәлекләре, көндәлекләре, альбомындагы сирәк рәсемнәр соңра безгә мирас булып күчте».

Зәйтүнә зирәклеге, тырышлыгы аркасында Бубый мәдрәсәсендә өч еллык программаны бер кышта үтеп, мөгаллимә таныклыгы алып Чистайга кайта. Апрельдә «Тукай вафат» дигән дәһшәтле хәбәр килеп ирешә. Көндәлегеннән өзек: «Тукай үлгәнен ишеткәч, бик еладым, бик борчылдым. Әкрен генә йөткерә башладым, ябыктым. Әни мине, Гөлсем апага ияртеп, профессорга күренергә дип Казанга җибәрде. Иң элек, килгәч тә, зиратка чаптым. Тукайның кабере кергәч тә капканың уң ягында икән. Зур гына бер калайга «Шагыйрь Габдулла Тукаев» дип язылган. Мин кабер янында Коръән укып бик озак елап утырдым».

«Мин, ахрысы, сөюдә дә милләтче... Мин татар кызының телен, сөйләшү рәвешен яратам».

Чибәр, укымышлы, заманына күрә алдынгы карашлы Зәйтүнәгә соңрак данлыклы Зәйнулла ишанның улы Кадыйр гашыйк була. Туй сәяхәтенә ишан яшьләрне хаҗга – Гарәбстанга җибәрә. Алар кайтыр чакта беренче бөтендөнья сугышы башлана. Төркия аша кайтырга тиешле яшьләр шунда бүленеп кала, әсир булып исәпләнәләр. Солых төзелүен көткән чорда да Зәйтүнә тик ятмый, атаклы Айя-Суфия мәчетенә йөреп укый, көндәлекләр алып бара. «1915 сәнәдә улым туды. Кендек әбисе Расиха абыстай», – дип язып куя. Татар әдәбиятында билгеле эз калдырачак галим, язучы, романнары өчен Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булачак Атилла Расих – Рәсүлев Атилла Кадыйр улы була бу.

Зәкия туташ Яңа Бистәдә үсә, татар мәктәбендә укый. Мехкомбинатта эшли торган абыйсы янына Атилла исемле егетнең килгәләп йөрүен хуплый гаилә. Акыллы малай, дус булсыннар, диләр. «Абый белән эшләүче шул егет берсендә чибәр кыз ияртеп килеп керде. Җырлый-җырлый әле генә идәннәр юып чыгарган идем. «Сөйгән кызыдыр» дигәнем... егетнең әнисе икән: «Улым әйбәт дусларым бар, дип, сезне бик мактый, күрешергә, танышырга килдем», – дип гаҗәпкә калдырды безне». Беренче очрашу Зәкия хәтереннән озак җуелмый.

Бу Зәйтүнә ханым була. Зәкиянең әнкәсе Зәйнәп Сабитова да Ләбибә-Хөсәения, Фатиха Аитова кызлар мәктәпләрендә мөгаллимлек иткән. Зәйтүнә – Атилланың әнисе – Шәледә укыта икән. Ике мөгаллимә уртак тел тиз таба.

«Ә мин күзләремне аера алмыйча яшь ханымны күзәтәм. Сихерләнгәндәй, чибәрлегенә шаккатып карап торам. Булса да булыр икән бу кадәр илаһи матурлык! Шул чакта хатын-кыз чибәрлегенә таң калуым озак еллар исемнән чыкмады. Аның рәсемнәре күп, әмма бер генә рәсем дә аңардагы сихри матурлыкны, соклангыч гүзәллекне – аның үз төсен чагылдырмый. Күрәсең, аның чибәрлеге җаннан саркылган моң кебек эчтә иде. Без шулай дуслашып, якынаеп киттек. Атилла скрипкада, абыем өздереп гармунда уйный, мин җырларга яратам. Бәхет өчен кешегә күп кирәкмени!»

Зәкия башта педагогия техникумын, аннан институт тәмамлый. Укыта. Сугыштан соң яшьлек дусты Атилла Расих (Рәсүлев) белән өйләнешәләр. Кайнанасы Зәйтүнә ханым: «Зәкия, ул теләдек, улыбыз булды. Кыз теләдек – күкләр ялваруыбызны ишетмәде, инде син безнең кызыбыз булса идең», – дип изге теләкләр теләп каршы ала. Яшь килен үзе дә кайната-кайнанасын үз, якын итеп, әткәй-әнкәй дип олылап яши. Зәйтүнә-бианай килененә хәерхаһ, гомер буе шәфкатьле, мәрхәмәтле була. «Зәкиянең ап-актан киенеп аш-су янына килүен, «әнкәй, пешеренергә осталыгым юк, үзең өйрәт инде мине», диюен күңелем бигрәкләр дә үз итте», – дип киленен яратып сөйли торган була.

Еллар үткәч, аш-сулы мәҗлесләрнең берсендә кунакларны: «Менә бу Тукай Зәйтүнәсенең килене була инде», – дип таныштыралар. «Тукай Зәйтүнәсен без беләбез, ә килене нинди икән?» – дип сораштырырга тотына кунаклар. Шулчак Зәйтүнә ханымның туганнан туган сеңлесе Сафия ханым: «Зәйтүнә белән без ахирәтләр идек, бер-беребезне «дустым» дип йөртә идек. Зәйтүнә дустымның сөйләгәннәрен сезгә дә җиткерәсем килә, – дип сөйләп китә, – Атилла, китабы чыккач, гонорарын әти-әнисенә йорт сатып алу өчен биргән булган. Әмма алдан вәгъдәләшкән йорт сатучылар бәяне тагын ике меңгә күтәреп куя. Каян акча табарга? Атилла командировкада. «Зәкиянең кышкы киемнәре юк иде, хезмәт хакыннан әз-әзләп пальтолык акча җыйган икән. Берсүзсез ике меңне чыгарды да бирде. Шулай итеп балалар безне өйле итте», – дип сөйләгән иде дустым».

Әти-әнигә генәме, Тукайның: «Шәфкатьле Сәҗидә апамның сабый вакытта иткән изгелекләрен кабердә ятсам да онытмам», – дип хәтерләгән апасының балаларына да тия аларның игелеге. Тукайның алтмыш еллыгын билгеләгән көннәрдә нәкъ менә шул Сәҗидә апасы белән очрашкач, аларның шәҗәрәсен төзүгә ныклап алынырга кирәк дигән уйга килә бит Зәкия Рәсүлева. Балтыйк буеннан Тын океангача илләр-җирләр гизеп, замандашларының, якыннарының истәлекләрен бөртекләп җыя ул. 230 дан артык туганын барлап, Тукайлар нәселенең шәҗәрәсен төзи. «Без эзләп тапканда Бибисәҗидә апаның кызлары Нурдидә белән Әклимә бик начар шартларда яши иде. Атилла Расих белән икәүләп йөри торгач, Язучылар берлеге аркылы аларга бер бүлмәле фатир алырга булышуыбызга куанып туялмыйбыз. Мин Атилла белән бик бәхетле булдым. Бер-беребезне аңлап, яратышып яшәдек. Ике ул, бер кыз үстердек. Фәридәбез – шагыйрә», – дип сөйләгән иде Зәкия ханым Рәсүлева.

Игелекле, олы йөрәкле Зәкия апа белән аралашу инде якты хатирә булып калды. Гүзәллеге күпләрне таң калдырган, Тукайга илһам биргән Зәйтүнә дә, Зәкия апа, Атилла абый да күптән мәңгелек йортта. Урыннары җәннәттә булсын.

Асия
СӘГЫЙТОВА

ШӘҖӘРӘ, НӘСЕЛ-НӘСӘПНЕ БАРЛАУ ХАКЫНДА КҮП СӨЙЛИБЕЗ ХӘЗЕР. АЙ-ҺАЙ, КОЛАЧЛЫ, МӘШӘКАТЬЛЕ ЭШ БУЛЫРГА ОХШАП ТОРА УЛ!

ТӘГӘРИ КИТТЕ БАЛДАГЫМ...

Әни үзе белгәннәрен теркәп калдырган икән. Без авылда туган-тумачасыз үстек. Ә менә әни дәфтәрендә алар... Әнинең бабасы Әхмәтхәбиб мулланың сигез баласы булган. Шул сигездән тагын кырык ике бала туган. XIX гасыр азагында туган балаларны XX гасыр чүпләп бетерә барган. Әхмәтхәбиб мулла – репрессия корбаны. Балаларын да язмыш аямаган. Аның өченче улы – минем Хәниф бабам кырык яшендә Бөгелмә төрмәсендә вафат. Икенче улы Халитша 1929 елда репрессияләнә, төрмәсөрген юлларында югала. Олы кызы Мәхүбҗамал унике бала табып, милләт санын ишәйтүгә өлеш кертә. Башкортстанның Кандра төбәгендәге Мансуровлар шуның оныклары булыр. Халитшаның Мирхатип исемле гаярь улы атасы юлыннан үтәргә теләмәгән. Сөргенгә җибәрер алдыннан ятим калган бала-чаганы авыл советы бинасына алып килеп бикләгәч, төнлә тәрәзәне урындык белән бәреп ватып, апа-сеңелләрен Ютазы станциясенә, аннан Ташкент якларына алып китә ул. Нәселнең байтак өлеше шул якта.

Багланышлар юк, ерагайганбыз.

Мин әнинең кайда барса – шунда кардәшебезне тапканына гаҗәпләнә торган идем. Ә бит нәсел таралмыйча яшәгән булса, нинди матур, күркәм оя буласы булган. Ә без ялгызлыктан каңгырып яшәдек.

Йә хуш. Әнинең әбисе ягыннан шәҗәрәбездә кемнәр бар икән?

Моннан ун еллап элек Финляндиягә барасымны белгәч, әни, анда безнең кардәшләр бар, дип, елмайтып куйган иде. Финляндиядәме? Суоми илендәгеләр башлыча Нижгар, Сергач тамырлы.



– Бар! – диде әни. – Минем Хәмидә әбиемнең иң кече сеңлесе Рәйханә балалары яши анда. Бубый мәдрәсәсен тәмамлаган Рәйханә Нижгар ягы авылында мөгаллимәлек итә, шунда кияүгә чыгып, ире белән Фин ягында бүленеп кала. Ул аннары абыйсы Габдулланың кызы Гәүһәрне дә, бала карашырга дип, үзе белән алып киткән.

Бардым, күрештем мин кардәшләрем белән. Рәйханә апа балалары Нармин апам белән Айтән апамны да күрдем, Гәүһәр Туганай балалары Зирәк, Хәтфә, Гүзәл белән дә танычтым. Хәзер кайберләре исән дә түгел инде. Гәүһәр апам белән Рәйханә апам каберләрен зиярәт кылдык. Зөһрә Сәхабиева алар рухына Коръән сүрәләрен укыды.

Финляндиягә 13 яшендә киткән Гәүһәр Туганай 2000 елда, 92 яшендә вафат булган икән. Гомер буе туган авылын, тауларын, шөлек, җирек куакларын, Ык елгасын сагынып яшәгән. Сагыну аны шагыйрә иткән. «Ташка басып карасам да, туган ягым күренмәс» диган җыру язып куйган ул көндәлек дәфтәренә. Калын дәфтәре тулы сагыш иде Туганайның. Шул чагында мин Сагыну хисенең Мәхәббәт хисеннән дә олырак, тирәнрәк, газаплырак хис икәнен тагын бер кабат аңлаган идем.

Сәфәремнән кайткач, күргәннәремне сөйләдем, сәламнәр тапшырдым. Әни белән бергә мине укытучым Нәкыя апа да тыңлап утырган иде. Шунда укытучым торып, шкафыннан нидер алып килде.

– Ә бит Гәүһәр апа алтмышынчы еллар башында – ил капкалары ачылгач кайтып китте. Шул чагында миңа бармагыннан салып шушы балдакны бүләк иткән иде. – Нәкыя апа учын ачты. Анда металлы билгесез бер балдак ялтырап ята иде. – Сеңлем, мине илемнән шушы балдак белән алдалап алып киткәннәр иде. Кырык ел кайта алмадым. Калсын бу балдак монда. Сиңа төсем булсын, диган иде.

Бу кыйсса мине бик тетрәндерде. Нәкыя апаның да, Фәһимә апа Хисамованың да әнигә өч туган сеңел тия икәнен шул чагында гына белдем. Укытучым бу серле балдакны минем оныгыма – ул чагында 13 яшьтәге Камиләгә бүләк итте.

Беркөн оныгым минем яныма бармагына шул балдакны киеп килгән. Чит илгә китеп, укуын дәвам итү уе белән йөри. Күңелемә хәзер үк инде сагыш кереп оялады. Туган иленнән бөтенләйгә алып китә күрмәсен иде аны бу балдак.

PRESSA.RU

Яз. Апрель. Тукай... Бу сүзләр күңелләребезгә балачактан уелып калган. Ул шигырь булып яңгырый. «Туган тел» җыры белән гел янәшә йөри. Ул безнең шигарь сыман... Бөек Тукаебыз туган көн Шигырь бәйрәме бездә. Тукайга чәчәкләр китерә, мәйданнарга чыгып, Туган тел, Тукай турында шигырьләр укый торган көн.

ЯЗДАН АЕРЫП БУЛМЫЙ ТУКАЙНЫ!..

Лена ШАГЫЙРЬҖАН

Тагын язлар килде

Тукайга

Нәни Апуш, сине
Кулларыма алып,
Йолдызларга тикле
Чөясем килә.
Үз әниең кебек,
Битләреңнән үбеп,
Сабыйкаем, диеп,
Сөясем килә.

Башкалардан элек
Хәлләреңне белеп,
Шөбһә-шикләреңне
Таратыр идем.
Туганым күк күреп,
Йөрәгеңә кереп,
Абыйкаем, диеп,
Яратыр идем.

Ялгыз чакларымда,
Ялгышканнарымда
Киңәш сорап, сиңа
Киләсем килә.
«Замандашым, Тукай,
Мин адаштым бугай,
Чыгар туры юлга», –
Диясем килә.

Тагын язлар җитте,
Җыелып сиңа килдек,
Һәйкәлеңнең ташын
Үбәсем килә.
Җырларыңның көче
Җиргә кучкән өчен,
Тукаем, дип башым
Иясем килә...

Саҗидә СӨЛӘЙМАНОВА

Шигърият язы белән

Без китәбез,
сез каласыз дип җырлармын,
Җәсадемне туфрак белән
күмгәндә дә.

Г. Тукай

Күпме килде, күпме китте
шагыйрьләр дә җырлары.
Тукай аһәңнәрен отып
калды Кырлай кырлары.

И мөкатдәс моңлы сазы
Һәркемнең күңелендә.
И туган тел, и матур тел –
халкымның гомерендә.

Җыр булса да, сын булса да –
һәрвакыт шагыйрь тере.
Тукай күзләре –
халыкның
ташка уйган хәтере.

Бу заманда шатлыклар да,
кайгылар да кискенрәк.
Көч күбрәкме, хис кимрәкме,
санмы, җанмы өстенрәк –

хәстәрле, сыный күк шагыйрь
кичен дә, иртәсен дә.
Дөньяның кайгы-шатлыгы
калганнар җилкәсендә.

Шул йөкне күтәрештә ул
шигърият язы белән.
«И туган тел»е белән дә,
и моңлы сазы белән.

Равил ФӘЙЗУЛЛИН

* * *

Яздан аерып булмый Тукайны!
Язда килгән, язда ул янган.
Язы, киләчәге барлар ничек китсен,
Ничек югалалсын дөньядан?!

Язны җуймый
Кара елларда да,
Халыкның ул гүзәл гамьнәрен,
Хыялларын, чорлар аша безгә –
Бүгенгегә китереп бәйләде.

Тел яшергән Тарих кына белә
Бар кылганын аның, күргәнен.
Ә шулай да булалган бит илгә
Игелеклелек кылу үрнәге.

Бу Тарихта мәшһүрләрне куйсаң
Ул яшәгән хәлгә, урынга, –
Байтагының шаулы даны түгел,
Чыкмас иде, бәлки, тыны да!

Яшәрен һәм үлемсезлеген
Дәлилләүгә мохтаҗмы халык?
Шикләнүче булса, кара, тикшер,
Бер бәгырен – Тукаен алып!

Апрель.
Кемнәр көтми ышанулар, гөлләр,
Яшерүләр биргән бу айны?
Яздан, гаделлектән, киләчәктән
Мөмкин түгел аеру Тукайны!

Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ

Тукай көне

Илдә кояш,
Җирдә кояш,
Йөздә кояш, күздә кояш,
Әмма бүген үзгә кояш.

Бүген аның каршысына
Канатланып чыккан бөре...
Аваз сала томшыклары:
Тукай көне!
Тукай көне!

Килә язлар, китә язлар,
Һәр ел саен үзгәрелә...
Үзгәрелә...
Һәр ел саен Тукай гына
Япь-яшь хәлдә килә безгә.

Киңлекләрдә язгы аваз –
Чыр-чу килә кошлар иле,
Чеңләп тора аһәңнәре:
Тукай көне!
Тукай көне!

Илдә кояш,
Җирдә кояш,
Тукай көне канат җәйгән.
Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген,
Тукай көне –
Безнең бәйрәм!

ЗӨЛФӘТ

Ялгызлык

Ил өстендә айкала җил
Тыннарны буып.
Боз да боз тәрәзәләрдә –
Тукайга суык.

Нинди язмыш булды соң бу?
Юл кая бара?
Каралып ява карлары,
Бураннар кара...

Кечерәя шәмнең уты...
Кем тора артта?
Шәм өстендә кара шәүлә
Зурая, арта.

Әкрен генә төшә түшәм...
Дөнья нинди тар!
Кайда ул канат җилпенеп
Очкан минутлар!

Кайда ул ялтыр яшендәй
Чатнаган чаклар?
Кайда шөлдерләр чыңлатып
Чапкан пар атлар?..

...Куш йодрык өстәл өстендә.
Шул куш йодрыкка
Ияген куйган да Тукай,
Текәлгән утка.

Ил өстендә айкала җил.
Суык. Төн кара.
Зурая шәүлә. Карала.
Шәм сүнеп бара...

Әкрен генә ишек ача
Мәңгелек салкын.
Мин сине күпме җылыттым! –
Кайда син, халкым?

Нияз АКМАЛ

Тукай

Кешеләрне шул бер сорау борчый:
Тереклеккә тере су кайда?
Йөз яшәгән картка килгән кебек,
Килә кеше япь-яшь Тукайга.

Мең тарафка таралганы Җирнең
Бер тарафка куйган төйнәлеп.
Тукай кебек карый белү кирәк,
Һәр төенгә шулай төбәлеп.

Төбәлгән ул... Халык язмышларын
Йөрәгенә аннан төйнәгән.
Чынбарлыгын әкият итеп әйткән,
Әкиятендә чынын сөйләгән.

Пәйгамбәр дә түгел, бары – шагыйрь!
Юраганы әмма юш чыга.
Шүрәлене бер очрату кирәк
Өнсез, телсез калган юлчыга.

Ә юлчыны шул бер сорау борчый:
Тереклеккә тере су кайда?
Мең яшәгән картка килгән кебек
Киләчәкләр әле Тукайга...

Асия ЮНЫСОВА

«Туган тел» җыры

Татар тарала ул төрле якка,
Тик тарая бара юрганы.
Ешкынына чумып хәл җыярга
Урманы да хәзер юк аның.

Түгәрәктән атлап чыгу белән
Ана телен йота ят лөгать.
Чит гадәткә капка ачкан саен
Өй түренә уза һәлакәт.

Адаштык та инде, саташтык та,
Каерылдык илдән читкә гел.
Шул чагында,
Бишек бавын тоткан ана кебек,
Урталыкка чыкты «Туган тел»:

«Иң матур тел, – диде, – туган телең,
Әткәң-әнкәң теле, – диде ул. –
Кайт өеңә кире, татар улы,
Идел–Урал – илең», – диде ул.

Ишетелде сөрән бар дөньяга,
Барып җитте һәрбер өйгә дә.
«Таралгансыз, телсез балаларым!
Җыелыгыз минем тирәгә.

Ярлыкагыл сине – телсез кавем!
Ана телен җуйган – сулган гөл».
Уятучы бишек җыры булып
Ил сагына басты «Туган тел».

Нәҗибә САФИНА

Барлау

Ялгыз мизгелләрем мине
Тукайга алып килә.
Каршы ала мине шагыйрь,
Ерактан көлә-көлә.

Таш сынын бөгеп сәламли,
Сузалмый кулын гына.
«Рәхмәт, – ди, – тагы килгәнсең,
Үзгәртмә юлың гына.

Мин дә ялгыз ел буена
Көтеп торам гавамны.
Килсәләр, барлар идем, дип,
Туган телле дәвамны...»

Ләис ЗӨЛКАРНӘЙ

* * *

Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов,
Тукай – өч йолдыз ул.
Г. Тукай

Бар дөньяның ямен, гамен җыеп
Яна шагыйрь, ут бөрки тәннән.
Шагыйрь өчен шушы дөнья – оҗмах,
Шушы дөнья – утлы җәһәннәм.
Шаулаган да җиргә иңгән, дибез.
Ә кабердә ята тән генә.
Утлы җан ул, дөрләп, күккә аша,
Йолдыз була, яна мәңгегә.
Ә күкләрдә инде күпме йолдыз!
Кайсы бөек, кайсы тәң(е)ре?
Дәшми әйләнәләр, ә үзәктә
Казык йолдыз – Тукай бәгыре.
Бик биеккә менеп янсалар да,
Төшенәләр җирнең гаменә.
Йолдыз атылганда килдек җиргә,
Җаннар шул ук, бүтән тән генә.
Баштан ашсын ләззәт, утлы газап,
Янсын бәгырь, көл калсын тәннән.
Безнең өчен шушы дөнья – оҗмах,
Шушы дөнья – утлы җәһәннәм!

PRESSA.RU



Асия ЮНЫСОВА

БАДАХШАН КЫЗЫ

(Хикәя)

Галим Шәмсуаров бу кайтуында «Казан» милли мәдәният үзәгендә ачылган күргәзмәне карап чыгарга ниятләде. «Бөек Ефәк Юлы рәссамнары» дигән аншлаг дәшеп китерде аны. Гомеренең бер матур өлешен Бөек Ефәк Юлын өйрәнүгә багышлаган, берара мәшһүр Ефәк Юлы узган төбәктә яшәп алган кеше өчен. Рәсем сәнгате һәм ефәк инде алайса. Кызык бу. Бөек Ефәк Юлы дигән галибанә яңгырашлы бу атама аның үзе өчен дә ниндидер географик термин булудан битәр, бер олы сергә мөнәсәбәте булган төшенчә кебек тоела. Тик менә ул сернең ни нәрсә икәнен генә эзләп таба алмый тора әле ул. Йөрәгенең ниндидер бер яшерен күзәнәгендә яши ул сер. Йә, ярый. Бәлки, шушы күргәзмә аңа ул сернең ачкычын табарга ярдәм итәр. Әйе, Шәрык белән Гареп багланышларының борынгыдан килгән бу тарихи сукмагы югалган цивилизациягә үтеп керү коды, ачкычы, хәтта ки капкасы, яшьләрчә әйткәндә, порталы кебек тә кабул ителә бугай. Шуңамы, соңгы араларда Бөек Ефәк Юлының тарихы, язмышы белән кызыксыну кабат җанланып китте.

Нәкъ менә ПОРТАЛ! Рәвешеңне, хәтта ки җисемеңне алыштыру урыны! Кешелек тарихында беренчеләрдән булып бик күп хикмәтләрнең серен белгән кытайлар үз могҗизаларын мыскаллап кына илләреннән чыгара башлагач, ягъни Борынгы Кытайдан Борынгы Рим юнәлешенә таба товар төялгән кәрваннар кузгалгач, Бөек Кытай диварыннан башланып, Турфан, Памир, Кавказ тауларын кичеп, Лоб-Нор, Искәндәр, Ван, Иссык күлләрен урап, Текла-Макан чүлен ерып, Кашгар, Өремче, Фиргానә, Герат, Кабул, Пәшәвар шәһәрләрен бер чылбырга ялгап, Римга таба барган, Урта диңгезгә таба үткән бу юл уңаенда күпме патшалыклар калган. Калыккан, җимерелгән. Ефәк Юлыннан Александр Македонский гаскәрләре дә, Аксак Тимер яулары да узган. Булып кичкән дәүләтләрнең, югалган халыкларның исемнәрен тарихчылар гына белсә белер. Бөек Болгар дәүләте дә шулар хисабында.

Югыйсә бит өч меңьеллык тарихлы бу юл беркайчан да тоташ такыр тасма булмаган. Төрле тау сыртларын үзләре белгән сукмаклардан, кичүләрдән кичкән ишәк, дөя кәрваннары зур базарлы шәһәрләрдә генә очрашканнар. Әй кайнагандыр инде ул борынгы базарлар! Хикмәт, тамаша күп булгандыр инде аларда. Бер кәрван белән генә дә өч йөзләп дөя керсен әле

базарыңа. Кем санагандыр инде ул кадәресен! Хәер, санаганнардыр. Йолдызбагарлары, математиклары белән дә шанлы бит әле ул Шәрык.

Базарны узгач, кайсы кәрван Урта Азия ягына, кайсы Багдад, Димәшкъ, кайсы Һиндстан, кайсы Болгар юнәлешендә кузгалган. Товарына, дөяләргә төялгән йөкләрнең кайда үтемлерәк булуына карап, ягъни мәсәлән.

Сәүдәгәрнең малы кытай ефәге генә түгел әле ул. Бу кәрваннар дөнья буйлап тылсымга ия дип саналган кытай көзгеләрен, тиңдәшсез затлы алтын-көмеш савыт-сабаларны, чинаякны (фарфор) тараткан. Хәер, чиннар гыйлләләрен үзләре генә белгән малларын чамалап кына сата башлыйлар башлавын, алай да ефәк яки кәгазь ясау серләрен нык саклаганнар алар. Урта Азия һөнәрчеләре ефәктән тукыма туку осталыгына өйрәнгәнче әле тагын күп гасырлар үтәр. Сәүдә кара-каршы, алмаш-тилмәш булганда гына отышлы була ул. Шуңа күрә каршы як кәрваннарында Кытай тарафына чыдам гарәп атлары, җиләк-җимеш, корал, буяу, хәтта ки арыслан, леопард кебек киек җәнлекләр дә барган. Кәрван юлларындагы шәһәр-авылларда сабыйлар туып калуы да бик ихтимал. Кара чәчләр – Төн илендә, сары чәчләр, зәңгәр күзләр гарәп чүлләрендә әфсен белән генә пәйда булмагандыр кана. Һәмишә кеше эзләре, ашыгыч мәхәббәт җимешләре калган булыр. Кем белә, кем белә... Борынгылык пәрдәсен кем күтәреп караган да, кем серләрен нинди төннәр йоткан! Кем орлыгы кайда калганын белсә дә, шул ефәк пәрдә – Бөек Ефәк Юлы гына белә булыр.

Уйлары бу урынга җиткәч, Галим әфәнде үз алдына канәгать елмаеп куйды... Ефәк сере, имеш. Монда да шул контрабанда... Ефәк корты кузакларын Будда динендәге монахлар, бамбуктан ясалган куыш эчле таякларына яшереп, үзләре инанган диннәре белән бергә, Урта Азиягә алып килгәннәр, ди. И-һи-һи, яшерерсең серне Бөек Кытай диварын төзеп кенә. Әле күп вакыт икәү генә белгән серне дә саклап калып булмый! Ә Кытайда ефәк серен белүчеләр меңнәр белән исәпләнгән. Шул меңнәр сер сандыгын, ил капкасын ачкач ясалган инде ул Бөек Ефәк Юлы тузанына төшкән беренче адым. Хәзер булса, Олы Юл дияр идек. Тукта, бу атамада да сер яшерелгән түгелме соң? Төрекләр, әнә, әле дә «олы» дигәнне «бөек» дип сөйләшәләр. Телебезнең бер бөртек берәмлеге шушы атамада сакланып калган. Шушы бер сүз генә дә безне уртак олы, юк – БӨЕК! – тарихка бәйләп куя түгелме соң?

Бөек Ефәк Юлы сәүдә юлы гына булмаган ул. Юк! Халыкларның күченеп йөрер юлы – Бөек Аралашу Юлы булган ул! Галим Шәмсуаров үзенең борынгы бабаларының да бу Бөек Юлда мосафир гына түгел, нәкъ менә юлчы, ә бәлки әле сәүдәгәр дә булу ихтималын уйлап, сөенеп куйды. Һәрхәлдә, яңа заман тарихында татарларның юлчылыгы, илчелеге, илгизәрлеге бәхәссез! Чит-ят җирләргә татар улын сәүдә генә алып китмәгән анысы. Нәселе туздырылганнар да бәхетен читтә эзләгән. Хәзер шул яхшы нәсел балалары әле бер тарафта, әле икенче тарафта, ташны тишеп чыккан кыяк кебек, баш калкыта. Татар баласының чит-ят мохиттә танылуга ирешә алуын кыякның баш калкытуы белән генә тиңләү көчсез чагыштыру инде анысы. Җөрьәт итеп, кояшка үрелгән сабый үләнне аяк табаны да, тәгәрмәч кыршавы да изәргә генә торган ул. Ә бит издермиләр, күтәреләләр! Менә бу күргәзмәдә дә шул – тураеп басканнарның картиналары булырга тиеш. Бик мөмкин. «Бөек Ефәк Юлы» дигән атама шуны вәгъдә итә.

Рәсем сәнгатенә Галим Шәмсуаров болай да битараф түгел. Картиналар туплау кебек байлар шөгыле белән мавыкмаса да, карарга, сокланырга, хисләнергә әвәс. Дөньяның байтак илләрен күргән кешегә Шәрык рәсем сәнгатенең дөнья мәдәниятендәге урынын чамалап карау да кызык. Болай гына. Үзе өчен генә. Фикерләрен ул берәү белән дә уртаклашып йөрми. Рәсем сәнгате нечкәлекләрен бәя бирерлек дәрәҗәдә беләм дип тә уйламый.

Татар рәссамнары арасында ул үзе Фәйзерахман Әминев иҗатын якын итә. Андагы нечкә лиризм, рәсемнәрдән саркып торган моң аның иң нечкә хис тамырларын кытыклый. Төш кебек кенә тоелып, еракта калган балачак хатирәләрен уята, сагышландыра, нечкәртә белә Әминев. Илдар Зарипов та шундый сизгер тоемлы татар. Якты сагышлы татар. Хәер, кайсы татар баласы сагышсыз инде ул! Ә менә рәссам Чыңгыз Әхмәрев иҗаты өлкән журналистның горурлык җилкәнен киереп җибәрә. Рәхмәт бу рәссамга. Алматы рәссамы, олы оста Камил Муллашевның серле фәлсәфәсе аны гаҗәпләндерә. Ярыммистик, ярымфантастик образларны кайдан табып бетерә торгандыр ул?

Тукта, нигә соң әле ул сәнгатьне милләтләргә аера? Сәнгать ул бөтен Кешелек байлыгы. Аның милләте юк! Дөнья күргән журналист милли кичерешләр белән мавыгуның азагы хәерсез икәнен исбатлау өчен аз тырыштымыни? Шул-шул менә – тырышты! Әмма тырышкан саен, ник минем булдыклы милләттәшем әдәбият, рәсем сәнгате, музыка, хәтта кино төшерү кебек гаммәви сәнгать тарихына милләтен яшереп керә? Милли хөрлек турында күбрәк сөйләнәбез генә бугай. Ә бит гамәлләр кирәк.

Менә әле дә Галим Шәмсуаров, «Казан» милли мәдәният үзәгенең ишекләрен киереп ачып кереп, күргәзмә хозурына иңәсе урында, каршы бакчадагы утыргычта үз алдына фәлсәфә корып, гомер буе туплаган белемнәрен барлап утыра. Журналист гадәте инде бу – һаман барлау, анализлау, шәрехләү. Югыйсә гади нәрсәләрдән рәхәтлек таба, кинәнә белергә дә ярый торгандыр бит. Кая китте аның романтикага бирелүчән табигате? Демагог!

Үзен шулай чыбыркылап алгач, Галим Шәмсуаров тәвәккәл адымнар белән атлап килеп, имән ишекнең җиз тоткасына тотынды. Күргәзмәгә кереп китте. Ягъни ПОРТАЛга иңде! Үзгәреп, яңарып чыгар өчен!

Һо-һо! Саллы икән бу күргәзмә. Бөек Ефәк Юлының үзе кебек колачлы!

Картинадан картинага йөри торгач, Галим әфәнде тәмам язылды. Югалткан ватанын тапкан кеше рәвешле,

PRESSA.RU

йөзенә иңгән куанычны яшермичә, һәр картинаны озаклап манзара кылды. Авторы кем, кай тарафтан килгән, кайсы халыкның баласы? Исемнәр күп иде биредә – танышлары да, таныш түгелләре дә. Күргәзмәне төзүчеләрнең яшерен максаты да булган кебек күренә. Авторларның барысы да Бөек Ефәк Юлы үткән төбәктән түгел. Әйтик, Киевтан Рафаэль Масаутов, Санкт-Петербургтан Рәшит Гыйлаҗев, Париждан Ринат Анимаев... Ләкин барысы да татар тамырлы рәссамнар. Бактың исә, болар татар авылларыннан кубарылганнарның балаларыдыр әле. Зыялы нәселләрнең варислары. Кайсы рәхмәт төшкересе, «Ефәк юлы» дигән брендны оста файдаланып, дөнья буйлап сибелгән татар рәссамнарын барлау хәйләсен тапты икән?

Ак җеп белән тегелгән хәйлә тиз сүтелүчән. Экспозициядә Үзбәкстанның, Төрекмәнстанның, Таҗикстанның яшь рәссамнары да лаеклы урын алганга күрә бу «ак җеп» күзгә ташланмый. Кардәш халыкларның сәнгатен белү, алар сулышын тоеп тору шулай ук кирәкле шәйдер. Шуңа күрә Галим әфәнде икенче залга да бик теләп үтте. Үтте дә беренче картина янында ук әсәрләнеп туктап калды.

Риза Рәхимов. «Канибадам базары». Үзбәк белән таҗик катнаш яшәгән Канибадам шәһәрендә Галим Шәмсуаров гаиләсе белән бер ел чамасы торып алган иде. Картинадан шул шәһәрнең җылы, шифалы, бәрәкәтле сулышы, базардагы бихисап мәйва-җимешләрнең хуш исе бөркелгәндәй булды. Авыздан су китерерлек шәфталулар, май йомарлагы төсле кавыннар, анарлар, кандай кызыл эчле карбыз телемнәре. Үрел дә ал гына, сыйлан гына. Әнә, бер читтә һөнәрчеләр балчыктан чүлмәк әвәлиләр, аның янында ук бер оста җиз ләңгәзгә (подноска) яңа гына зәңгәр бизәк төшергән касәләрен матурлап тезә. Шунда ук ашбаз кайнар тандырдан чүрәкме, нанмы алып тора.

...Төсләр бәйрәме бу картинада. Шәрык ачык төсләр, бәйрәм буяуларын ярата. Шәрык халкының бәйрәм сөю, кунак ярату холкын рәссам бик оста сурәтли алган.

«Канибадам базары»ннан Галим әфәнде бер дә аерылмас иде, картинаның эченә үк кереп китәр иде дә, озаклап шул базарда йөрер дә, йөрер иде дә бит. Күз кырые белән генә янәшәдәге картинаның тагын да зуррак бәйрәм вәгъдә итүен абайлады.

«Нәүрүз бәйрәме». Бәхетҗан Мулдагазизов картинасы. Бу рәссамның милләте кем? Исеменә караганда Бәхетҗан үзбәк булырга охшап тора. Бу борынгы милләттә, татарның каерылган канатында, сәнгати сизгерлек, тоем бик көчле. Сәмәрканд, Бохарадагы Регистан, Гүр-Әмир биналарын күреп үскән яшь рәссамнар кай заманга тигезләнергә икәнен беләләр. Нәүрүз. Гомумтөрки бәйрәм. Яңа ел башлануны бәйрәм итү, димәк. Татар дөньясына гына рәхәтләнеп кереп китә алмады бу бәйрәм. Югалган рухи байлык!

Канибадамдагы тәүге һәм бердәнбер дә булды инде ул Нәүрүз. Илдә урысча Яңа елны каршы алуга кузгалганнар иде алар Таҗикстан ягына. Суыклар Зәмирәсенең буыннар чирен кузгатып җибәргән иде ул кышны. Әллә ниткән «Рейно чире» дигән диагноз куйдылар. Имеш, климатны алыштырырга, җылы җирдә яшәргә кирәк хатынына. Галимнең инәе генә үз алдына сукранып йөрде: «Бозганнар киленне. Рәнҗеш төшкән аңа – хатын аертып килгәненә күрә. Бала рәнҗеше бар килен өстендә».

Инәй сукрана калды. Галим белән Зәмирә ике кызларын кочакка алдылар да, өч чемодан сөйрәп, Дүшәмбе ягына бара торган поездга утырдылар да киттеләр. Галимнең армиядә бергә хезмәт иткән дустына кышкы кар кебек барып төштеләр. Атна буе кунак булгач, шул Канибадам каласына барып урнаштылар. Адәм баласын тәкъдир генә түгел, бәлки, ризык та йөртә. Ризыгың булсын өчен эш дигәне кирәк. Урта Азиядә белемле кешенең кадере бик бар иде ул вакытта. Бигрәк тә рус телен яхшы белсәң. Галим урта мәктәпкә тарих укытырга урнашты. Мәктәпнең торагы да бар икән. Зәмирәне эш әзерләп көтеп торганнар диярсең. Бер атнадан хастаханәгә чакырып килделәр. Балалар табибы ул. Бик тиз кирәкле кешегә әйләнде. Төнге дежурлыклары белән тәмам үзәгенә үткән иде Галимнең. Зәмирә килгәнче ничек эшләп яткандыр ул хастаханә? Җылыга тиенүгә сызланулары басылган хатыны муеннан сырхау балалар мәшәкатенә чумды.

Галимнең вакыты иркенрәк булып чыкты. Шуңа күрә игезәкләре – өчәр яшьлек Гүзәл белән Гөлназ күбрәк аның тирәсендә, күбрәк әтиләрен тинтерәтә. Их, әнә теге тәрәзәдән күренеп торган җимеш бакчасына кертеп җибәрәсе иде үзләрен. Анда чинар агачына эленгән даган да күренә. Әй кинәнерләр иде кызыкайлар! Тик менә кеше бакчасына ничек бәреп керәсең? Шулай гына, тәрәзәдән карап хозурланырга гына кала. Бакчада, чыннан да, хозур. Галимнең туган авылында әле язгы бозлар кузгалмаган да булыр. Ә монда инде җимеш бакчалары чәчәктә. Өрек чәчәгенә бер чәчәк тә җитми икән дип карап торган иде бер көнне. Иртәгәсен анар чәчәк атты. Һушың китмәле! Дөрес, тәрәзә аша чәчәкләрнең хуш исе сизелми. Ә менә аларның Ык буе әрәмәләрендә шомырт чәчәк атканда аның исе кар базына кадәр төшә торган иде. Күрсәнә, монда килеп төпләнүләренә өч ай гына тулып килә, ә ул инде җирси дә башлады түгелме соң? Эшсезлек галәмәте бу! Мәктәптәге атнасына унсигез сәгать дәрес кенә җан ярсуын баса алмый, күрәсең.

Хатынының рухланып йөргәненә Галимнең кытыгы килә. Үзенең дә нindидер зур эшләр майтарасы килеп йөди. Йөри торгач уйлап тапты. Бөек Ефәк Юлының төркиләр тәрәккыятенә йогынтысын өйрәнү максатыннан күзәтүләр алып бара, шуңа бәйле материаллар туплый башлады. Казанга кайтуга диссертация яклау хәстәре белән йөрермен дип уйлады. Тик менә кызлар... Гел бимазалап торалар шаянкайлар.

Әйе, Нәүрүз бәйрәме иде ул көнне дөньяда! Галим ул көнне дә икенче кат тәрәзәсеннән күршеләр бакчасын күзәтеп озак басып торды. Чөнки ул гүзәл дөньядан күзне ала торган түгел иде. Күз явын ала торган матурлык шундый буладыр инде ул. Әнә, анар агачыннан зур бер тәлгәш аерылды да Галимнәр болдырына таба килә башлады. Бу бакчада һәр көнне күренеп ала торган


Рәсем: Наталья Васильева

туташ түгелме соң? Аллы-гөлле хан-атлас күлмәгә анар гөле сурәтенә керткән чибәркәйне. Ул кыз гел матур күлмәктән була. Бу юлысы ул чыннан да чәчәк иде. «Анаргөл!» – дип әйтеп куйды Галим, бу табигать бүләген үзенчә бәяләп.

Анаргөл бераздан ишектән үк атлап керде.

– Галим әкә! – кара син аны, ирнең исемен дә белә икән. – Бүген бәйрәм ләбаса. Бөтен кеше бәйрәм итә. Сез генә күренмисез?

– Сөбханалла, сеңлем, минем атымны да беләсең икән. Тик миңа «әкә» дип дәшмә, ярыймы? «Агам» яки «абыем» дип әйтсәң, яратарак төшәрмен үзеңне. «Җаным» дисәң, бөтенләй дә эреп китәрмен.

Аның соңгы сүзен ишектән кереп килгән Зәмирә ишетеп калган икән.

– Ай-ай, картым. Ул матур сүзне сиңа үзем генә әйтермен. Оялтма күршекәйне. Белеп тор, аның ире минем коллегам. Саграк сөйләш. Бәхтияр Фазылович бик кырыс җитәкче. Миңа да эләгер.

– Зәмирә аем, рәхмәт сезгә. Алайса, Галим агаем оялта куйган иде. Мин сезне бәйрәм чәенә чакыра кердем. Аннары матур кызларыгызны безнең бакчада уйнатыйк. Айванда гына, саф һавада табын корган идек. Бәхтиярым кәбаб куыра калды. Көтәбез.

Ул көнне бик ямьле бәйрәм иттеләр алар. Бу күршелек мөнәсәбәтләре аннан соң да матур дәвам итеп, ике гаиләнең дә тормышын кызыклырак итеп җибәрде. Галим күп белә, белгәнен матур итеп бәян итәргә дә оста. Зәмирә – хатын-кызлар өчен бәяләп бетергесез киңәшче. Тик менә күршеләр өендә бала-чага күренмәве генә сәеррәк тоела. Хәер, өйләнешеп оя корганнарына артык озак вакыт үтмәгән икән әле. Өлгерерләр. Әмма Зөмрәтнең, яшь ханымның үз исеме шулай булып чыкты, бу җәһәттән хафалануы сизелә. Соңыннан Зәмирә дә серне ачты. Имештер, Зөмрәт Бәхтиярның икенче хатыны икән. Ирнең бикәсеннән өлкәнрәк икәнен чамалаганнар иде шул. Беренче хатыны да бала китермәгән булган. Аерылышуның сәбәбе шул икән. Зөмрәт ирен бик ярата икән. Бала булмаса, үзен дә аерыр дип курка икән.

Зәмирә Зөмрәтне тәмам шефка алды. Табиблар гына белгән хатын-кыз серләрен яшь хатынга ачты, төрле физио-дәвалау чараларына йөртте, күнегүләр өйрәтте.

Ике гаилә дуслашып алгач, чит туфракта яшәү дә мәгънәлерәк булып китте.

«Нәүрүз бәйрәме» картинасын утыз җиде ел элек булган ямьле тормышны хәтерендә яңартып, күршедусларын сагынып, уйланып торды. Ник аларның дуслыгы Галимнәр Казанга кайтып китүгә тукталып калды икән? Югыйсә арада бернинди кинә сүзләр, низаглар, тәмсезләшүләр булмады. Әллә булган иде микән соң? Галим генә белми калган иде микән? Бервакытны таудагы урманлыкка чикләвек җыярга менгәч булган хәл бозылышу өчен сәбәп була ала идеме икән әллә? Әйе, алар ул җәйне тау арасындагы соклангыч Искәндәр күленә су коенырга да бардылар әле. Шунда Зөмрәтнең үзенә төбәлгән сокланулы карашын абайлап алган иде Галим. Бәхтияр йөзә белми икән. Ә Галим суда балык кебек. Ыкта үскән егет лә ул. Йөзеп аргач, ярга чыккан мәлдә үзенең яшь Геракл кебек мәһабәт була алганын ул үзе дә белә. Авыл хезмәте белән дә, спорт белән дә ныгыган ирнең мускуллары ул заманда уйнап кына тора иде. Үзенә сокланып караган Зөмрәткә Галимнең күз кысканын Бәхтияр күреп калды, ахрысы. Шул көннән соң айванда чәй эчүләр бетте. Әмма бергәләп кыргый

PRESSA.RU

алыча җыярга да, чикләвеккә дә бардылар. Чикләвек җыйганда бит әле. Әйе. Зөмрәт елан өстенә килеп чыгып, чырыйлап кычкырып җибәргән иде. Аның янына Бәхтиярдан алда Галим килеп җитте. Әмма Зөмрәткә бер адым калды дигәндә, Бәхтиярның кылычка тиң карашын күреп, сөрлегеп калды. Ярамый икән, кеше хатынын еланнан да араларга ярамый икән! Галим моны мыегына урап куйды. Кирәксә-кирәкмәсә күршесенең хатынына күз кысмас, сүз катмас булды. Йөрәксезлек түгел иде бу. Үзеннән байтак өлкән ирнең ирлек хисләрен аяу иде.

Әмма Зөмрәт үзе, нигәдер, бер дә кирәкмәгән кыю булып чыкты. Сәбәп табып та, сәбәпсез дә килә дә керә. Һәм еш кына Зәмирә кечке сменада чагында. Әллә үзенең ире дә өйдә югындамы? Җимешләр, алмалар, кавыннар алып керә, кызлар белән уйный. Игезәкләргә үзбәк җырларын өйрәтә. Ялгыз, ягъни хатынсыз кич утырган иргә күңелле булып китә.

Зөмрәт Галим өчен Анаргөл булуына ияләште инде. Бер кергәнендә чәйгә салып эчә торган үләннәр алып кергән бу. «Безнең чәйләр сихәтле ул, агаем. Без бит һәр үләннең мең дә бер хасиятен беләбез. Менә бусы зәгъфран. Аннан бер чеметем он ясар өчен ике йөз илле чәчәкнең бөресен өзәләр. Шуңа күрә анда ике йөз илле чәчәк куәте бар! Илегезгә кайткач мактанып сөйләрсез».

Инде бу вакытта Галимнәрнең кабат Казанга җыенулары мәгълүм иде. Чәйнең төрледән-төрлесен эчереп карады Анаргөл. Бер керүендә чәй касәсен каплап куюга сәер җөмлә әйтеп ташлады:

– Галим агаем, без синең белән охшашканбыз түгелме? Синең дә күзләрең зөбәрҗәт кебек яшел, чәчләрең дулкын-дулкын… Минеке дә. Галим агаем, калдыр миңа бер малай!

– И-и, Анаргөл, бәгырькәем, миннән кызлар гына туа бит. Беренче хатынымда да кызым үсә минем. Син мине гөнаһ эшкә ымсындырма. Мин хатынымны бик яратам. Аның белән ике арага хыянәт кертәсем дә килми. Син әле яшь. Ходай сезнең үзегезгә малай бирер.

Галимнең нәсыйхәте һавада эленеп калды. Анаргөлнең иңнәренә дулкын-дулкын таралган кара бөдрә чәчләре, оялып, инәлеп баккан күзләре аның акылын алды. Анаргөл, Анаргөл! Иңеңне кочкан чәчләреңне аралап, кигән ефәгеңнән дә нәфис тәнеңә бармак очы белән генә кагыласы иде дә бит. Ярамый! Ярамый! Ул бер хатынны елатып, кызын ятим итеп калдырды инде иләндә. Аның ташлап киткән Гөлфирәсе янына Ригадагы ике улын ятим итеп кайткан егет латыш хатынында үзеннән туган ике татар баласын ятим иткән, диләр. Бу чылбырны бүтән дәвам итәргә ярамый. Югыйсә Анаргөл эчергән тылсымлы чәйнең канын уйнатканын да сизеп тора…

– Һич юк, агаем, хыянәт итмәс. Ядкарь генә Сездән…

– Бар, чык, Анаргөл. Ялгыш…ма! Ялгыш…

Сүзен төгәлли дә алмый калды. Шул мизгелдә Анаргөл, җитез җәнлек сыман аның алдына менеп тә кунаклады. Кайнар, дәртле тыны белән куырып та алды. Чишенеп тә тормады бугай ул. Ефәгенә төреп, ирнең һушын алды да Галим исенә килгәнче чыгып та югалды. Аның артыннан һавада татлы хуш-исләр белән өртелгән ефәк җиле генә эленеп калды. Менә сиңа оялчан, тыйнак Шәрык кызы!

Андый «ялгышу» тагын ике тапкыр кабатланды. Шуннан соң Галим китәргә кирәк дигән фикерендә чынлап торып ныгыды. Чөнки азагы хәерле бетмәсен чамалый. Югыйсә инде Анаргөл дә кереп йөрүләрен кинәт туктаткан иде. Очрашкан чакларда да, башын иеп кенә, ваемсыз гына исәнләшеп йөри башлаган иде.

Менә шул заманнан соң тагын утыз алты Нәүрүз бәйрәме узган да киткән. И-и гомеркәйләр, диген!

Галим Шәмсуаров «Нәүрүз бәйрәм» картинасыннан теләр-теләмәс кенә аерылып, каршы дивардагы картина янына килде. Килсә… Аннан аңа Анаргөл карап тора! «Бадахшан кызы яки Әнием портреты». Ядегәр Бәхтияр задә. Шунда ук рәссамның фотосурәте дә бар. Яшел күзләр, дулкын чәчләр. Галим әфәнде катты да калды. Ядегәр, димәк Ядкарь. Галимнең Анаргөлгә ядкаре. Әмма Бәхтияр задә – Бәхтияр баласы, димәк. Эстәгәнеңә ирешкәнсең икән, Анаргөл! Арада хатлар йөрешмәүнең дә, кунакларга барышмауның да сере шушы егет инде алайса. Димәк ки, Ефәк Юлында Галим Шәмсуаровның да орлыгы калган!

Бик вакытында киткәннәр икән Канибадамнан. Озагракка торып калган булсалар, Анаргөлнең язмышы да, Ядегәрнең язмышы да, Зәмирә белән игез кызларның язмышы да бүтәнчә булуы ихтимал иде бит. Бәхтиярның кылыч күзе Анаргөл белән Галим арасында зөбәрҗәт күз белән дулкын чәчтән башка охшашлыклар да күреп алган булыр иде. Бик ихтимал. Ә болай, мөгаен, ул да күз угыннан югалган иргә үч саклап тормагандыр. Акылы җиткәндер. Бәлки, аңышмагандыр да. Ни генә димә, Бәхтиярның варисы бар. Ул, әнә – Бәхтияр задә! Танылган рәссам. Галим Шәмсуаровның матур яңгырашлы фамилиясен мирас итеп алыр варисы юк. Кызлар кызлар инде ул. Алар – кеше кешесе.


Галимнең өзелеп-өзелеп Анаргөлне күрәсе, аның хан-атластан тегелгән күлмәгенә, ефәктәй тиреле муенына борынын төртәсе килде. Бигрәк тә аның белән озак-озак итеп чәй эчәсе, талантлы уллары хакында озак-озак итеп сөйләшеп утырасы килде.

Ул, күргәзмәне оештыручылардан автор турында берәр төрле мәгълүмат белеп булмасмы икән дип, берара тулганды да кабат «Бадахшан кызы» каршына килде. Нигә Бадахшан кызы микән соң аның Анаргөле? Әллә ире серне белеп алып, хатынын талак кылды микән дә, ул туган-үскән йортына кайтып китте микән? Бадахшаннан мин, дигән иде бугай ул бер сөйләшеп утырганда. Әллә ире вафат микән? Ул чагында күрешер өчен юллар ачылыр кебек. Юктыр, алай түгелдер. Сурәттәге Анаргөл бик бәхетле күренә ләбаса. Бәхете түгәрәктер аның. Шулай гына була күрсен!


Күргәзмәдән чыгып барганда Галим әфәндeнең күзе бер игъланга төште. Күргәзмәгә эшләре куелган кайбер рәссамнар белән матбугат конференциясе узасы икән. Әллә?..













Муса ҖӘЛИЛ
«Моабит дәфтәрләре»
Муса ДЖАЛИЛЬ
«Моабитские тетради»

Әлеге китапта татар халкының бөек каһарман шагыйре Муса Җәлилнең атаклы «Моабит дәфтәрләре» татар һәм рус телләрендә тәкъдим ителә. Җыентык шагыйрьнең тууына 110 ел тулу уңаеннан чыгарылган. «Бәлки, аны үлем җәзасына хөкем итәрләр. Ул үләр. Ә аның әсирлектә һәм тоткынлыкта язган 115 шигыре бар. Ул шулар өчен кайгыра», – дип яза шагыйрь үзе турында. Шигырьләре – аның безгә васыяте.

Мәсгуд ГАЙНЕТДИН
«Йосыф Акчура»

Бу китап Йосыф Акчураның биографиясен һәм иҗатын өйрәнүгә багышланган шактый зур күләмле хезмәтнең бер бүлеге. Биредә күрсәтелгәнчә, Й. Акчура XX гасыр башы революцияләре чорында сәясәт өлкәсендә дә, татар әдәбиятында да күренекле урын тота. Аның соклангыч иҗаты – үзе бер дөнья. Китапта Акчура тормышының аеруча үзенчәлекле, кискен борылышлы мизгелләре, аның фикерләре, тарихи дәвер белән бәйләнеше турында да сөйләнә.

Асия ЮНЫСОВА
«Алкалы чәчәкләр»

Өегезгә нур булып кечкенә бәби кайттымы? Димәк, бу китап сезнең өчен! «Алкалы чәчәкләр»не укый-укый бәби карарга өйрәнәбез хәзер: гел елмаеп торсын дип аңа май каптырырга, тәмле телле булсын дип – бал каптырырга, күз тимәсен өчен маңгаена сөрмә сөртергә, исем кушу тәртибенә... Бәбине бергәләп су коендырабыз, торналар аңа – тәпи, тургайларның тел китергәненә сөенәбез. Аннары нәниләр белән бергәләп дөньяны «ача» башлыйбыз.

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА
«Бала күңеле — ак кәгазь»

Укучыга шигърияте белән таныш булган язучының әлеге китабына төрле елларда иҗат ителгән туган тел, горефгадәтләребез, китап, туган җир язмышы турындагы уйланулары, әдәбият-сәнгать әһелләре, аларның иҗади эшчәнлеге турындагы публицистик язмалары, очерклары тупланган. Аларда – кичәге һәм бүгенге мәктәп сулышы, укучы тормышында үрнәк булырлык язмышлар, әдәп-тәрбия мәсьәләләрендә өлге итеп алырлык мисаллар.

Сөмбел ГАФФАРОВА
«Чынга ашачак хыял»

Балалар өчен язылган фәлсәфи-аллегорик бу повесть малайларга-кызларгамы, әллә аларның әти-әниләренә күбрәк ошармы? Һәр икесенә дә кызык булыр, мөгаен. Әкиятләр укырга яратмый торган Суфия исемле кыз беркөнне Онытылган Хыяллар һәм Хатирәләр урманына эләгә... Китап – аның шул урманда күргәннәре турында. Бүләкле китап бу – анда әле сезне өстәл уены көтә.

Җ. ХӨСӘЕНОВ
«Кызыклы география»

Планетада ике шәһәр ике дөнья кисәгенә урнашкан. Болар нинди шәһәрләр? Ярларын өч океан суы юган өч дәүләтне атагыз. Казакъстанда бер өлеше тозлы, ә икенче өлеше тозсыз күл бар. Бу нинди күл? Балыкларның гомере озынмы? Иң эссе диңгез, иң кечкенә диңгез, иң тирән күл, иң зур утрау, иң тирән ташкүмер шахтасы, иң борынгы шәһәр, иң тар урам, иң озак җәяүләп сәяхәт итүче кеше... Кулыгызга «Кызыклы география» китабы эләксә, бу сорауларга һичшиксез җавап табарсыз!

ТӘЭСИР.



Альбина БӘШИРОВА, җырчы – алып баручы:



Хәзерге вакытта, бик тәэсирләнеп Алексей Толстойның «Петр Первый» дигән әдәби-тарихи романын укыйм. Роман, нигездә, документаль чыганакларга таянып язылса да, әдәби чаралар да оста кулланылган, шуңа күрә бик җиңел укыла. Берничә сюжет линиясе үзара үрелеп, бик мавыктыргыч, кызыклы әсәр барлыкка килгән. Бу романны Алексей Толстой, Сталинның махсус заказы буенча яза башлаган, һәм билгеле булганча, ул аны язып бетерә алмаган, шуңа күрә роман «тәмамланмаган» статусында яши. Заказ белән язылган булуына карамастан, монда әдәби-тарихи роман жанры кысалары рөхсәт иткән кадәр төгәллек белән чынбарлык тасвирлана. Төп герой – Петр Беренчегә һәм башка персонажларга карата ниндидер симпатия һәм антипатия хисләре юк, вакыйгалар, укучыга, ничек бар – шулай тәкъдим ителә. Тагын бер нәрсәгә исем китә – роман XVII–XVIII гасырларны тасвирласа да, күтәрелгән проблемалар шул дәрәҗәдә актуаль, хәтта, мәсәлән, халык тормышын сурәтләгән өлешләрне абзацы белән цитаталап, бүгенге көн вазгыятен характерларга мөмкин булыр иде. Байлар һәм ярлылылар каршылыгы, чит илләр белән мөнәсәбәтләр, гади халык белән хакимият арасындагы каршылык – болар барысы да гасырдан-гасырга ияреп килеп, шушы көннәргә кадәр хәл ителмәгән мәсьәләләр икән ләбаса! Роман эпик рухта язылган булса да, чынбарлыкның бизәкләнмичә, беренчел халәтендә бирелүе чыннан да кызыксыну һәм ышаныч уята. Әйткәнемчә, бу заказ белән язылган әсәрләр өчен типик хәл түгел. Киләчәгеңне беләсең килсә – үткәнеңне өйрән, диләр бит. Яхшы тарихчы-язучының әсәрен укып кына тарихны төпләп өйрәнеп булмаса да, анда тасвирланган чорга караган вакыйгаларның эзлеклелеген, халыкның тормыш рәвешен, кәефен күзаллап була.

Татарстан китап нәшрияты кибетләре:
Казан шәһәре, Бауман урамы, 29/11; Бауман урамы, 19; Декабристлар урамы, 2.

PRESSA.RU

һәр гамәлнең үз сәгате

26 яшендә дөньядан киткән газиз балам — улым Фәритнең якты истәлегенә багышлыйм

Нурания
ТӨХБӘТУЛЛИНА

ҺӘР ГАМӘЛНЕҢ ҮЗ СӘГАТЕ

(Хикәя)

Юлдан Ана бара. Ул бик ашыга бугай. Аңа ничек тә кичке бишкә кадәр йөз чакрым ераклыктагы район үзәгенә барып җитәргә кирәк. Ник бер машина туктап утыртсын! Ул инде ике сәгатьләп көзге ачы җилләр кочагында басып торды. Хәерсез! Төбәк рәссамнарының эшләреннән күргәзмә оештырыласы икән. Ул бу турында бүген иртән генә белде.

Аннары төшкә кадәр авылдан машина эзләп йөдәде. Яллап бармакчы иде, ризалашучы табылмады. Хәер, моңа гаҗәпләнәсе дә түгел. Җитмешкә җиткән карчыкның кемгә сүзе үтсен? Һичберәүнең аңа йомышы төшәсе, гозерләнеп киләсе юк. Югыйсә күрше өлкәдән юллама белән килеп, утыз алты ел шушы авыл балаларына белем бирде ул. Бирсә ни соң, бушка түгел бит, эшләгәненә акча алды. Үпкәләрлеге юк. Әйе, гомеренең иң матур еллары шушы авылда узды. Татар телен, әдәбиятын укытты ул. Яратып, теләп, җан рәхәте табып, эшен сөеп башкарды. Кечкенәдән рәсемгә һәвәслеге булу сәбәпледер, өйрәнелә торган әдәби әсәрләргә багланышлы рәсемнәрне үзе ясап алып килә иде. Әле дә хәтерли, бигрәк тә Әмирхан Еникиның «Матурлык», Аяз Гыйләҗевның «Язгы кәрваннар» хикәяләренә уңышлы килеп чыккан иде рәсемнәре. Ә аннан инде, пенсиягә чыгып, вакыты иркенәйгәч, ул зур бер рәсем ясарга җөрьәт итте. «Ферма янында» дигән гади генә картина иде ул. Әйе, гади генә, бәлкем, аның сәнгатилеге дә шулкадәр генә булгандыр. Тик ул картина өлкәнәйгән укытучыны ярты авыл белән дошманлаштырды да куйды. Картинада ферма ишеге тирәсендәге бер төркем сыер савучылар сурәтләнгән. Өсләренә кара халат, аякларына резин итекләр кигән алҗау чырайлы хатыннар төркеме. Зәңгәр кан тамырлары бүртеп торган кулларында сәнәк, көрәк, бидон, саву аппараты, он тутырган капчык, бау ише нәрсәләр күренә. Уртада – потлы чиләкләр белән су күтәргән олы яшьтәге апа. Ферма яны баткаклык булгангадыр, «Лексус» маркалы җиңел машина читтәрәк – сыер савучыларга каршы якта туктап калган. Аның ачык ишегеннән таза, тук чырайлы ир-ат төшеп килә. Күз иң әүвәл аның җиргә басаргамы-юкмы дип торган затлы, ялык-йолык килгән туфлиләренә, аннары гына кабартма кулларына төшә. Ир-атның бөтен килеш-килбәте: «Мин кем дә, сез кем?» – дип тора. Әйтерсең лә, ул нәкъ шушы мизгелдә йөзендәге әдәп-әхлак битлеген салган да, чын холкы – тәкәбберлеген, ертлач-

лыгын «киеп куйган». Картинада телгә алып гаепләрлек нәрсә дә юк кебек. Тик машинадан төшеп килүче ир-атны (бу рәсем татарча чыгучы журналларның берсендә дөнья күргәч) авылдашлар үзләренең хуҗалык җитәкчесенә охшатты. «Очлы күзләре белән бездәй тишеп каравы тач шуныкы инде», – диештеләр. Хәер, кайберәүләр рәсемдә районның икенче бер түрәсе сурәтләнгән дип тә таптылар. Менә шуннан китте инде ыгы-зыгы...

Ана бу юлы күргәзмәгә улының – бәгырь кисәгенең картинасын алып бара. Аның улы да рәсем сәнгате белән мавыкты. Әле институтта укыган елларында ук «Кичке уен» дигән зур картина язган иде. Биш ел эшләде ул аны. Халкыбыз тарихы, мәдәнияте турында күпме китап укыгандыр, шушы темага материаллар эзләп, интернетта ничә төннәр утыргандыр. Яратып, мавыгып, ләззәтләнеп язды ул картинасын.

Улының картинасында елга буе, яшел калкулык, шунда кичке уенга җыелган яшьләр сурәтләнгән. Әсәр гаҗәеп лирик килеп чыккан! Ул төсләр уены дисеңме, ул түгәрәк ясап биюче егет-кызларның, гармунчының сыгылмалы хәрәкәтләре, кием-салымның күреклелеге, тирә-як манзараның матурлыгы дисеңме – бар да искиткеч! Рәсемгә карагач, туган якның йолдызлы зәңгәр күгенә, салмак кына агып яткан елгасына, аяк астында баш төртеп килүче үләннең зөбәрҗәт келәменә карап бер рәхәтлек чиксәң, егет-кызларның затлы киемнәренә икенче сокланасың. Алтын җепләр белән үлән, чәчәк шәкелендәге нәфис бизәкләр чигелгән бәрхет калфаклар, түбәтәй-кәләпүшләр, өрфия яулыклар, постаудан, бохар тукымасыннан тегелгән кәзәкиләр; яшел, алсу, зәңгәрсу төстәге ситсы, йон, ефәк күлмәк итәкләренең дулкыны; ахак, яшма, якут, фирәзә кебек асылташлар тезелгән куш беләзекләр, көмешне бөртекләп ясалган алкалар, алтын йөгертелгән яка каптырмалары, бай бизәкле хәситәләр, чылтыр чулпылар, чиккән чүәкләр, чәмчәле, савырлы читекләр – бар да чын сәнгать дәрәҗәсендә!

Рәссам, егет-кызларның яшьлек гүзәллеге белән балкыган төс-битләрен, зифа сыннарын, бәйрәмчә кием-салымнарын гына сурәтләп калмыйча, аларның эчке дөньяларын да чагылдыра алган. Тыйнак, оялчан кызларның әдәпле генә елмаюлары, егетләрнең үзүзләренә ышанган тәвәккәл карашлары, бер-берләренә ягымлы күз кысып, каш сикертеп куюлары – үзе бер тамаша. Монда хәтта кемнең күзе кемгә төшкәнен дә чамалап була. Әнә гармунчы бөтен барлыгы белән түгәрәк уртасындагы чая кызга омтылып уйный, анысы исә, тыпырдап биегән килеш, назлы карашын түгәрәк читендәрәк уйчан гына басып торучы бөркет карашлы, кара кашлы, кара күзле, киң күкрәкле егеткә юнәлткән.

Улы гаҗәеп бу картинасын район музеена бүләк иткән иде. Ана исә күргәзмәгә газизенең «Инеш буенда» дигән әсәрен алып бара. Аның фикеренчә, бу картина да чын сәнгать әсәре, һәм ул күргәзмәдә тиешле бәясен алыр сыман иде.

Тәгәрмәчләрен ачы чиелдатып килеп туктаган машина тавышына карчык сискәнеп китте.

– Син нәрсә юл уртасына чыгып бастың?

Ачулы җикерү апаны бөтенләй айнытып җибәрде. Ул машина йөртүче янына атылды.

– Район үзәгенә кадәр алып бармассыз микән? – диде карчык ялынычлы кыяфәттә.

– Утырыгыз соң. Тик бу нәрсәгезне кая урнаштырырга соң әле?

– Арткы утыргычка сыяр ул.

– Минем пассажирлар аласым бар, багажникка урнаштырыйк булмаса.

Күпер төбендә ике ир-атны утырттылар. Балыкчылар, ахры. Алар кызып-кызып сөйләшәләр, бәхәсләшеп тә алалар. Сүзләре һаман шул балык тирәсендә икән.

– Әйтәм бит мин сиңа, чуртаннар алар. Ә безгә, маймычларга, нишләргә кала? Безне бит санга сугучы юк, – дип сорый яшьрәге ярсыган тавыш белән.

– Нишләргә, нишләргә? Агым уңаена йөзәргә, – ди йомшак бәрхет тавышлы өлкәнрәге.

– Шулай йөзеп, чуртан авызына барып керергәме?

– Анысын әйтә алмыйм инде, кемгә ни язган! Син хаклы, дөреслектән уттан курыккандай куркабыз шул. Менә сугыш бетәр дә, «Известия» – дөрес хәбәр, «Правда» хакыйкать язар дип хыялланган солдат кебек син. Хыялланма, дус кеше, талантыңны юкка әрәм итмә. Дон Кихот!

– Син нәрсә? Кайбер корсак коллары кебек борынны җил уңаена тотып язаргамы?

– Шулай язмый булмый да... Кем әйтә аны утыз җиденче ел бетте, ул кабатланмас, дип. Форсат кына чыксын, явыз сәясәткә ярдәмгә килергә әзер каләм кыштырдатучылар да, ура-патриотлар да табылыр. Такташ абзаң язган бит: «Яшәсенгә килгәч сынатмадык, / Бүрек чөеп «Ура!» кычкырдык» дип... Шомалар күбәйде, шомалар... Ә маймычлар... алар шунда калалар инде, аяк астында изелеп.

Әңгәмә-бәхәс шул рәвешле тагын озак дәвам итте. Болар, өлкән апаның аңлавынча, балыкчылар да, үзләре әйткәнчә чуртаннар, маймычлар да булмаенча, ниндидер газетаныңмы, журналныңмы хезмәткәрләре иде бугай.

Аллага шөкер, вакытында килеп өлгерде бит. Рәхмәт яугыры, картиналарны күргәзмәгә сайлап алучы комиссия әле эшли иде. Карчыкның кулыннан картинаны бер бүлмәгә алып кереп киттеләр. Бераздан күзлекле ир-ат чыгып, карчыктан әсәрнең исемен, авторның исем-фамилиясен, адресын язып алды. «Ничек соң?» – дигән кыюсыз гына сорауга: «Искиткеч!» – диде дә бүлмәгә кереп китте.

Тик картинаны күргәзмәгә алмадылар. Ике сәгатьләп көткәннән соң, бер юантык хатын бүлмә ишегеннән башын тыккан килеш кенә: «Җитәрлек санда картиналар куелган, урын юк», – дип белдерде.

Башына сугып миңгерәйтелгән кешедәй, Ана картинаны – йөрәк парәсенең кадерле ядкарен бәзгә төреп,

PRESSA.RU

күкрәгенә кысып урамга атлады. Ә анда инде караңгы төшкән. Бераз туктап уйланып торды. Инде кая барырга? Аның юллык кына акчасы бар, хәзерге кунак йортларында төн кунып чыкканга түләрлек түгел. Катканакларга абына-тибенә, карчык вокзалга юнәлде.

Авылына икенче көнне кичкә таба гына кайтып җитә алды ул. Юл чатларында машиналар көтә-көтә салкын тидергәнме шунда, әллә артык борчылуданмы, өч көн урын өстендә ятты. Юкә чәчәге, үги ана, каен яфрагы төнәтмәсе, мәтрүшкәле чәй, борыч салып кайнаткан сөт эчә торгач, терелде тагын, узгынчы чир генә булган, шөкер. Инде өч көн ризык җыймаганы исенә төште дә, döге бәлеше пешерергә тотынды. Бәлеш пешеп чыгуга, чакырып китергәндәй, кунак та пәйда булды. Күрше кызы икән, юл сәдакасы керткән. Китәр вакытлары җиткән, санаулы көн тиз уза шул. Бу бала дизайнерга укып чыккан иде, инде биш-алты ел Франциядә яши, шунда кияүгә чыкты. Ире дөньяның эре банкларына программалар урнаштыра торган фирмада эшләгәнлектән, еш кына аны бик озакка башка илләргә, күбесенчә Гарәп Әмирлекләренә, командировкаларга җибәрәләр. Җеп инәдән калмый дигәндәй, хатыны да аның белән йөри. Дөньяны урадылар инде. Мөмкинлекләре бардыр, монда да елына икешәр тапкыр кайтып китәләр.

Нишләрсең, бармаклар да тигез түгел шул. Кемнәргәдер байлыкта, муллыкта коенырга, кемнәргәдер очын-очка ялгап яшәргә язган. Әй, әле шушы барлы-юклы тормышына да бик канәгать булыр иде, әгәр дә... әгәр дә... газизе-улы исән булса. Юк бит, юк. Ходай шул бәхетен дә күпсенде. Егерме җиде яше дә тулмаган йөрәк парәсе – баһадир гәүдәле, кызларның һушын алырлык чибәр йөзле улы инде бишенче ел кара җир куенында ята. Карчыкның алтын баганасы ауды, кояшы сүнде. Шушы фаҗигадән соң ул ниндидер соры, авыр дөньяда яши, аны берни шатландырмый, берни тетрәндерми кебек. Ә инде улыннан да алда гүр иясе булган ирен ул оныткан диярлек, бары тик намаз арты догаларында гына искә ала аны.

Күрше кызын, кыстап, чәй өстәле артына утыртты. Кунак, җимеш исләре аңкып торган дөге бәлешен мактый-мактый ашады.

Кыз инде чыгып китим дигәндә генә аның игътибарын, бәзгә төрелеп, диван аркасына терәтеп куелган кыса җәлеп итте.

– Картинамы әллә? – дип кызыксынды ул. – Карарга ярыймы? – дип рөхсәт алгач, бәзне чишеп, түбән иелде, аннан бераз читкәрәк китеп, картинага текәлде.

– Класс! – диде ул бераздан. – Бу соң безнең инеш буе бит! Карасана, суының сафлыгын! Төбендәге ташларына кадәр ялтырап күренә. Бәй, ташлар арасында маймычлар да йөзә икән ич. Без аларны балачакта яулык белән сөзә идек. Ә шомыртлар соң?! Ак күбеккә батканнар. Хуш исләрен сизәм. Кара, кара, монда шәмәхә чыклы сиреньнәр дә бар! Челтер чишмәбез дә шәйләнә ич монда! Инеш аша сузылган тар басмада кер чайкаучы үсмер кыз кем икән? Күрче, аның ялан тәпиләре, ак куллары, нәфис йөзе – бар да теп-тере кебек. Һавада чәчрәгән су тамчылары кояшта ничек җемелдиләр! Гаҗәеп матурлык! – дип сөйләнгән күрше кызын Ана моңсу гына тыңлады.

Ахырдан кыз күрше апасына:

– Чит илдә рәхәттә яшәсәм дә, туып-үскән җир сагындыра. Җирсү – ностальгия мине генә читләтеп үтми шул. Юкка гына елына икешәр тапкыр кайтып киләммени! Сез туган җирдә яшәүчеләр, бу хисне аңлап та бетмисездер... Менә бу картина чит-ят җирдә миңа зур юаныч булыр иде... Сат әле, апа!

– Юк, сата алмыйм, улымның ядкаре ул.

– Бик аңлыйм, – диде кыз. Аннан, бераз уйланып торгач, өстәп куйды, – бәлки, улыгызның тагын бирәр картинасы бардыр, сезгә истәлек өчен, дим.

– Әйе, «Урман аланында» дигән картинасы бар аның, умарталыкны сурәтләгән ул анда.

– Шулай булгач, – диде кыз, җанланып.

Стена буендагы шкафның зур бүлегеннән картинаны алдылар. Кыз бу картинага да шактый озак әсәрләнеп карап торды. Аннан карчыкка:

– Менә бит, истәлек өчен бу әсәре яхшырак та әле. Ул монда үзен дә сурәтләгән. Битлеге аша йөзе аермачык күренмәсә дә, умарта өстенә иелгән гәүдәсе гел үзе бит.

– Юк, – диде карчык, сүзен бирергә теләмичә, – бу картинасы төгәлләнеп бетмәгән аның.

– Нишләп алай дисез? Кай җире төгәлләнмәгән? – дип гаҗәпләнде кызыкай.

– Имза куймаган бит, димәк әсәре язылып бетмәгән, – диде ана.

– Куймаса да. Картина төгәл аныкы икәнен беләсез бит, шул җитмимени?

Кыз анадан «Инеш буенда» дигән картинаны сатуын инәлеп, тегесе ризалашмыйча, шактый озак сатулаштылар алар. Ниһаять, карчык, инде гомер кышларына кереп баруын искә төшерепме, әллә инде картинаны калдырып китәрдәй, аның кыйммәтен, кадерен аңлардай кешесе юклыгын уйлапмы, көч-хәл белән ризалашты. Кыз, куанып, рәхмәтләр әйтә-әйтә, чыгып йөгерде дә шул арада ирен ияртеп алып керде. Кияү безнеңчә, ягъни ни татарча, ни русча белми. Тәрҗемә аша аралаштылар. Ул картинаны озак кына карап торды. Аннан, телен шартлатып, кызга: «Etonner! Mystique!» – диде дә кызу-кызу ниләрдер әйтте. Кыз безнеңчәгә әйләндерде.

– Ул: искиткеч, ди, мистика, ди.

– Нинди мистика? – диде карчык, гаҗәпсенеп.

– Ә менә картинадагы хәрәкәт. Сәер бит, су ага, вак дулкыннар йөгерешә кебек, агач яфраклары, чәчәкләр, үләннәр тирбәлешеп тора сыман, хәтта кызның чапылдатып кер чайкаганы да ишетелә.

Берара кыз тагын кияве белән сөйләшеп алды. Картинаның бәясе турында киңәшләшәләр икән.

– Биш йөз мең аз булмасмы? – диде кыз.

– Сез нәрсә? – дип гаҗәпләнде карчык. – Ул кадәр акча миңа нәрсәгә?

Кыз көлемсерәп куйды да:

– Ярый алайса, менә шул биш йөз меңне санап алыгыз.

– Юк, юк, – диде карчык, – йөз мең дә ташып ашкан. Акча сезнең үзегезгә – яшьләргә кирәк.

Кияү төргәкләнгән биш йөз меңне өстәлгә салды да картинага үрелде.

– Ашыкмагыз, – диде карчык, – баламның иҗат җимешенә тагын бер кат карап калыйм. Бите буйлап тәгәрәгән ачы күз яшьләре аша ана картинага текәлде. Ул шулай күпме басып торгандыр, күрше кызы, аны сак кына җилкәсеннән кочып, кәнәфигә китереп утырт-ты. Бераздан берәр чынаяк сөтле чәй эчкәч, күршеләр, картинаны алып, хушлашып чыгып киттеләр.

Төштән соң почтальон килде. Ул карчыкның ун мең сум пенсиясен һәм район газетасын китергән иде.

Карчык газетаны караштыра башлады. Әһә, әнә теге күргәзмә турында тулы бер битне биләгән мәкалә басылган. Авторы да таныш. Күрше авылда озак еллар укытып, мәктәп ябылгач, редакциягә эшкә күчкән әдәби иҗатка сәләте булган хатын. Әле мәктәптә укыт-канда ук көн кадагына суга торган шигырь, мәкаләләр бастыра килде ул. Ниләр язды икән? Карчык мәкаләне игътибар белән укып чыкты. Әйтерең бармы, бик оста язган. Күргәзмәгә куелган картиналар, тамашачылар фикере турындагы өлешләре аеруча шәп. Тик... нәрсә бу? Күргәзмә залы тулы булмаган икән бит. Егермеләп картина булыр дип көтсәләр, унике генә эш килгән. Ә аны бит, картинага урын юк, дип кайтарып җибәрделәр. Нигә инде?.. Нишләп инде?.. Ярар, аның үзен «Ферма янында» дигән рәсеме өчен түрәләр читкә какты да, ди. Ул бит улының картинасын алып килгән иде, аның ни гаебе бар?

Автор күргәзмәгә катнашмаган рәссамнар турында да бик тәфсилләп язган. Рәсем сәнгате белән мавыга гына башлап, картина-мазар иҗат итәргә өлгерми бу дөньядан киткән яшьләрне дә искә алырга онытмаган. Анысы өчен рәхмәт. Газизләрен мактап искә алу ата-ананың яралы йөрәгенә бер генә тамчы булса да бәлзәм бит. Тик ни бу?.. Карчыкның улы бу исемлектә дә юк. Автор белмәгәндер, дисәң, әле күптәнме ул район музеендагы экспонатлар турында язып чыкты. Картинаны күрмәгәндер дисеңме? Хәер... тукта, ул мәкаләдә дә улы, аның картинасы турында бер сүз дә юк иде бит. Улы кемгә комачаулаган, кемгә зыяны тигән? Карчык кылт итеп әле мәктәп елларында ук укыган «Үлгәннәр дә үч алды» дигән хикәяне исенә төшерде. Гаҗизләнеп, мәкаләне тагын бер тапкыр укып чыкты. Автор анда рәсем сәнгате белән мавыккан кешеләрнең исемнәрен берәмтекләп телгә алган иде. Төрле конкурсларга плакатлар ясап җибәргән мәктәп укучылары да онытылмаган, һәрберсе исем-фамилиясе белән искә алынган. Арада аның улы гына юк. Юк!.. Юк!..

Карчык, газаплы уйларыннан арынырга теләп, улының «Урман аланында» дигән картинасы каршына килеп басты. Бик озак сагышланып карап торды ул аңа. Нишләптер, юлда очраган балыкчыларның сүзләре хәтеренә килде: чуртаннар һәм маймычлар... «Маймычлар... алар шунда калалар инде, аяк астында изелеп». Кинәт карчыкка улы да башын калкытып аңа – әнисенә карап тора кебек тоелды. «Улым! – диде карчык, өзелеп, кипкән иреннәрен көчкә кыймылда-тып, – без маймычлар икән!» Шул вакыт ниндидер сәер кыштырдау һәм улының: «Юк, без кешеләр!» – дигәне ишетелде. Карчык бер мәлгә һушы китеп катып калды да бераздан, хәлсезләнеп, диванга ауды. Кояш баеп, өйгә кичке караңгылык иңә башлады.

...Ә ул иртәгәсен уянганда Ананың өе нурга күмелгән иде. Бу нурдан «Умарталык» та, анда тыз-быз бал ташып йөргән бал кортлары да терелгән иде. Рәсемдәге улының иләк-битлек астыннан чалынган йөзендә дә елмаю бар иде. Дөрес әйткән күрше кызы. Улы янында икән ич, әнә генә икән. Юк, улым, без маймычлар түгел, бал кортлары! Кәрәзгә мәңге бозыл-мас бал ташучылар...

Ана улының әсәрләре әле Париж күргәзмәсенә дә куелачагын, аның исеме илгә данга күмелеп кайтача-гын белми иде...

Әгерҗе районы,
Кадыбаш авылы.



Рәсем: Наталья Васильева

PRESSA.RU

«Шагыйрь мәхәббәте»



Бу опера моннан ун ел элек тамашачы җанын яшендәй айкап алган иде. Халык шагыйре Ренат Харис үзенең Тукай турындагы драматик поэмасына нигезләнеп язган либреттога композитор Резеда Ахиярова искиткеч музыка иҗат итте. Шулай итеп татар театр дөньясында күтелмәгән премьера пәйда булды! Әкияти матурлык. Сихри моң. Күңелләрне айкый торган аһәңле, җанга ятышлы милли музыка. Тукай шигырьләре. Җанны телгәли торган нәфис мәхәббәт тарихы. Шагыйрь, фәрештә, юламан итеп күрсәтеп, бөек Тукайның күңел дөньясын төшләр аша ачу. Бай динамика...

Эльмира ЗАКИРОВА

Романтик Тукай – нечкә күңелле егет, мәхәббәт утында янучы гашыйк буларак ачыла. «Тәфтиләү» көе ишетелгәндәй була. Күз алдыннан төрле манзаралар уза. Тукайның нәни Апуш чаклары. Печән базары. Кырлай урманнары. «Болгар» номерлары. Шәрык клубы... Тамашачы, күз яшьләреннән дә тарсынмыйча, яшерен, өметсез һәм фаҗигале мәхәббәт турындагы бәян кебек кабул итеп утыра...

Шагыйрь Ренат Харисның «Минем дә бар үз Тукаем!»ын ачасы, сүтәсе, шуңа үз Тукаебызны ялгыйсы килә. Ул үзе менә ниләр сөйли:

– Минем «Үз Тукаем» – мин аңлаган, мин яраткан Тукай ул. Без һәрнәрсәгә үз тәҗрибәбез аша карыйбыз. Бүгенге көн кешесе өчен Тукай – бөек шагыйрь, тирән философ, кыю публицист, үтергеч сатирик, пәйгамбәр, татар халкының йөз аклыгы, визит карточкасы.

Минем Тукаем – даһи, поэмада әйтелгәнчә – «яшүсмер аксакал», ягъни акыл иясе, олы тормыш тәҗрибәсе туплаган кеше. Ә бит асылда Тукайның биографиясе, гомер юлы кыска һәм бик гади, анда киләсе буыннар гыйбрәт алырлык берни дә юк кебек. Тукай университетларда, царскосельский лицейларда укымаган, чит илләрне күрмәгән, зур урыннарда эшләмәгән, чиннарга ия булмаган, сугышларда катнашмаган, хәтта гаилә корырга, бала-чага үстерергә дә өлгермәгән. Шуңа да карамастан, аның иҗаты байлыгы ягыннан озын-озак гомер кичергән, күпне күргән дөнья әдәбияты классикларыныкыннан әллә ни аерылмый. Аның иҗаты йөз яшәр әдипләрнеке кебек бай һәм югары! Менә шуңа соклану бөек шагыйребез турында поэма язарга этәрде мине. Бигрәк тә аның мәхәббәтенә соклану!

Ә нигә мин Тукайның мәхәббәтенә сокландым соң? Чөнки аның сәер мәхәббәте миңа бик тә үзенчәлекле булып күренде. Хәтта мин аны үзем өчен «Тукай мәхәббәте» дип атадым. Тукай үзенең бу дөнья кешесе түгеллеген, бакыйлыкка иртә китәчәген белгән, шуңа күрә Зәйтүнәне аяган, толлык бәхетсезлегенә дучар итәргә теләмәгән. Тукайның кешелек сыйфатлары, зирәк акылы янартаудай хисләрен баса алган. Сөеклесе бәхетле булсын өчен! Мин «Тукай мәхәббәтен» шулай аңладым һәм поэмамда да, «Шагыйрь мәхәббәте» операсында да шулай аңлатырга тырыштым. Композитор Резеда Ахиярова бу фикерне үзенең гаҗәеп матур, тетрәндергеч хисләргә

бай музыкасы белән тагын да куәтләп җибәрде.

Зәйтүнә Мәүледова – реаль шәхес. Укымышлы гаиләдә үскән Чистай кызы белән Тукайны «Әлислах» газетасы редакциясендә Фатих Әмирхан таныштыра. Истәлекләргә караганда, бу чибәр туташка шагыйрь бер күрүдә гашыйк була, аңа багышлап шигырьләр дә яза, аларны газеталарда да бастыра. Зәйтүнә дә шагыйрьгә битараф түгел. Ләкин «Тукай мәхәббәте» бу кавышуны бәхетле итәргә ирек бирми. Соңыннан Зәйтүнә Мәүледова Кадыйр Рәсүлев дигән дин әһеленә кияүгә чыга. Бу гаиләдә күренекле язучыбыз Атилла Расих дөньяга килә. Атилла аганың кызы Фәридә Рәсүлева да язучы, берничә шигырь китабы авторы. Зәйтүнәнең куен дәфтәрен (аны «Шәкерт дәфтәре» дисәң дә ярыйдыр – *Р. Х.)*, Казандагы Тукай музеенда күрергә була.

Татарстанда опера театры барлыкка килгәннән бирле Тукай турында композиторлар, драматурглар, шагыйрьләр опера язу теләге белән яшәгәннәр. Тотынып та караганнар. Ләкин Тукай хакында сәхнәдә яшәрлек опера тумый калган. Моның сәбәпләре күп. Шуларның иң беренчесе – Тукайны опера герое итеп язылган либретто булмау. Либретто авторларының барысы да шагыйрьнең биографиясе белән чикләнгәннәр, ә аның тормыш юлы, алда әйтелгәнчә, зур вакыйгаларга ярлы. Мин дә бөек шагыйребезнең сәхнә образын иҗат итәргә җөрьәт итмичә озак йөрдем. Элгәргеләремнән аермалы буларак, шагыйрьнең тәрҗемәи хәленнән бигрәк, аның эчке дөньясын күрсәтәсем килде. Зәйтүнәнең аңа гашыйк икәнен, үзенең дә аны бөтен йөрәге белән яратуын белгән хәлдә дә, иртә үлемгә дучар ителгәнен аңлаганга күрә, Тукай аны үзенә якынайтмаслык көч таба. Операның доминанты менә шул. Опера хисләр давылыннан, киеренке бәрелешләрдән гыйбарәт. Әйткәнемчә, поэмам нигезендә дә, опера либреттосында да – Тукайның эчке дөньясы, ә бу дөнья тирән һәм гүзәл булган. Шуны күрсәтергә теләгәнгә мин либреттоны яздым. Ул композитор Резеда Ахиярովага да, театр җитәкчелегенә дә ошады. Тукай белән Зәйтүнәнең фаҗигасен тирән аңлап, Резеда беркемне битараф калдырмый торган музыка язды.

Премьерадан алып бүгенге көнгәчә Тукай ролендә – Россия Федерациясенең атказанган, Татарстанның халык артисты Әхмәт Агади. Опера сәнгате дөньясында Тукай партиясе катлаулылардан санала. Югары ноталарга бик мул партияне башкарып чыгар өчен зур тәҗрибә һәм осталык, өстәвенә, бик күп көч тә кирәк. Әхмәт Агади гәүдәләндергән Тукай үзенең драматизмы белән йөрәккә үтеп керә.

Резеда Ахиярова 1986 елда оркестр һәм орган өчен «Моңлы сазым» поэмасын яза. Тагын да колачлырак проектын гамәлгә ашыру өчен ул 2002 елда кабат Тукайга мөрәҗәгать итә. Опера иҗат итү ике елга сузыла, тамашачыга юлы да шуның кадәр вакытны ала. Композитор үзе бу хакта болай искә төшерә:

– Опера – иҗатның тагын да югарырак баскычы ул. Бу жанр композиторга тагын да тулырак ачылырга, музыка ярдәмендә бик күп сәхнә образлары иҗат итәргә этәргеч бирә. Авыр, ләкин мавыктыргыч шөгыль. Шагыйрь Ренат Харисның бөек Тукай турында опера язу идеясен мин кабул иттем. Аның кызыклы либреттосына рәхәтләнеп музыка яздым. Чөнки Тукай шигъриятенә кечкенәдән гашыйкмын. Операның музыкаль телен табу җиңел булмады. Ул милли дә, Европа традицияләрен дә исәпкә алган, заманча да булырга тиеш иде. Иң соңгы фаҗигале финалдан тотынып яза башладым. Тукай яратып йөргән кызы белән хушлаша: Зәйтүнә Чистайга китә. Икесе дә бүтән беркайчан да күрешмәячәкләрен аңлыйлар. Мәхәббәт очкыны, кабынырга да өлгермичә, сүнә... Зәйтүнә партиясен беренче булып Венера Ганиева җырлады. Ул партияне нәкъ менә Тукай премиясе лауреаты Венера Ганиевадан җырлатасым килде. Аның тавышы – нәфис колоратур сопрано. Яшь кыз Зәйтүнә дә шундый нәфис, челтерәп торган тавышлы булгандыр. Романтик рухлы кыз чынлап та Венерага якын, аңлаешлы иде ул чакта. Ул бик яратып, бөтен барлыгын биреп башкарды бу рольне. Венерага җырлап күрсәтәм, ул үз фикерен әйтә, мин аңа яраклаштырып үзгәрешләр кертәм. Мелизмнар белән баетам. Икебез өчен дә кадерле роль булды ул. Соңрак бу партияне Башкортстан җырчысы Әлфия Кәримова башкарды, аннары бөтен дөньяга танылган Альбина Шаһиморатова җырлады. «Шагыйрь мәхәббәте» һаман яши! Ул һаман сәхнәдә! Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры сәхнәсендә җәй көне кабат барачак. Тамашачылар аны бераз яңартылган вариантта күрер, яңа сценография, яңа режиссура булачак анда, матур күренешләр... Режиссерыбыз шул ук – Мәскәүдәге Зур театрдан атаклы Михаил Панджавидзе. Зәйтүнә партиясен күренекле яшь җырчы Гөлнора Гатина җырлаячак. Моңарчы ул Зәйтүнәнең дус кызы Бәдриҗамал ролен башкарган иде. Иң беренче Тукаебыз – Санкт-Петербургның Мария театры солисты Әхмәт Агади. Шушы роль өчен ул Россиянең «Алтын битлек» милли премиясенә лаек булган иде. «Тышкы кыяфәтем белән түгел, эчке дөньям белән Тукайны ачарга омтылдым, аның шатлыкларын, сагышларын күрсәтергә теләдем. Музыкасы шундук җәлеп итте. Аны халык көе кебек җырларга кирәкми, Европача, итальян музыкасы сыман башкарырга кирәк», – дигән иде Агади бер интервьюда. Тукай ролендә Илһам Вәлиевне дә күрәсем килә минем. Ул да бу рольдә үзен сынап караган иде инде. Кемнәр генә җырламады ул операда!.. Айдар Фәйзрахманов, Руслан Дәминов, Альберт Әсәдуллин Шүрәлене башкардылар, Мөнир Якупов коеп куйган Фатих Әмирхан иде!.. Операны татар халкы гына түгел, башка халыклар да яратып кабул итте. «Европа традицияләре саклап язылган», – дигән фикерләр әйтелде. Менә бит музыка нинди илаһи көчкә ия!

PRESSA.RU



ШОМЫРТ ЧӘЧӘГЕ АК КЫНА



Рамилә ХӘМИТОВА

«АК КАЛФАК» БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ «ГАИЛӘДӘ ҺӘМ ҖӘМГЫЯТЬТӘ ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЫНЫҢ УРЫНЫ» ДИГӘН ТЕМАГА БӘЙГЕ УЗДЫРДЫ. БЕЗ БҮГЕН СЕЗГӘ ШУЛ БӘЙГЕДӘ БЕРЕНЧЕ УРЫННЫ АЛГАН ЯЗМАНЫ ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ.

Чәчләремне җил тузгыта, ә мин акрын гына күзләремне йомам. Күз алдыма синсез калган көн килә. Хәлсез генә түрдә, караватта ятасың: өстеңдә ап-ак күлмәк, башыңда аксыл яулык: киемнәрең дә үзең, күңелең сыман ап-ак! Әмирхан Еники әсәрендәге Ак әби син инде ул! Үлем белән тартышкан мәлең бит бу. Юк, инде тартышмыйсың да бугай, фани дөньядан бакыйлыкка күчәргә күптән әзер идең инде син. «Күрәсен күрдем, яшисен яшәдем, шөкер Ходаема!» – дип бик еш кабатлый башлаган идең. Бары бер үкенечең генә калды бугай: оныгыңның сабыен сөяргә өлгермәдең. Ул кыз бала синең төсең кебек, синең сыман зәп-зәңгәр күзле, аксыл чәчле булып дөньяга туды.

Бүген сине сагынуга чыдашлы түгел. Кара-каршы утырып, дөнья хәлләрен сөйләшүләр, үгет сүзләрең, авыр чакта аркамнан кагып сөюләрең җитми миңа...

...Ул үзен бәхетле гаилә баласы дип искә ала иде. Ишле гаилә булуга карамастан, мул тормыш кичергән алар. Мул яшәүнең сере – хезмәттә. Аерым хуҗалык булып яшәп, хезмәт белән көн күргәннәр. Ике егет һәм алты кыз тату, бердәм булып, туганлык хисен тоеп үсәләр. Тик сугыш афәте чыгып, тормышларын тар-мар итә. Берәм-берәм бәхетле нигез ниргәләре ишелә башлый.

Иң әүвәл олы абыйлары сугышта хәбәрсез югала. Бу хәсрәт аларны тәмам аяктан ега: әти-әниләре күзгә күренеп картая, чәчләргә чал өстәлә, маңгайга тирән сырлар уела. «Мине Пермь өлкәсенә ташкүмер бушатырга җибәрделәр. Өстә иске күлмәк, аякта чабата. Дүрт ел чамасы бер сынык икмәк хакына бил бөктек, – дип сөйләүләрең әле дә колакта, күзләреңдә мөлдерәп торган яшьләрең бүгенгедәй күз алдында. – Сугыш тәмам, без дә авылга әйләнеп кайттык. Нинди генә авырлыклар кичерсәк тә, тормыш дәвам итә бит, яшәргә тырыштык. Көндез эшлибез, ә кичләрен яшьләр, җыелышып, кичке уенга чыгабыз. Минем дә сөйгән егетем бар иде, армиягә озаттым мин аны.

Бүгенгедәй истә: кич утырган җирдән, бер төркем яшьләр мине дәшеп алды. Имеш, энекәшем егетләр белән бәйләнешкән, аны кыйныйлар, диделәр. Тик бу минем энекәшемне коткарырга йөгереп чыгуым гына булмаган, ә зур, катлаулы тормыш арбасына җигелергә ашыкканмын... Урладылар мине шул кичтә. Әйләнеп кайту теләгем дә бар иде, булачак ирем Әхмәтнең: «Көтүдән качып кайткан сарык диярләр сине!» – дигән сүзләре генә күндерде. Шулай яши башладык: кайнана, дүрт каенсеңел, мин. Кеше күз яшьләре төшми калмый диләр, дөрес икән, мин дә татыдым аның ачысын. Барлы-юклы акчаларны җыйнап туйлар итүгә бер-ике атна вакыт үтте микән, армиядән сөйгән егетем кайтты. Ә мин, көтәргә вәгъдә биргән «сөйгән яр» инде ир хатыны идем... Шулай бер көнне бертуган энеләрем кунак җыйды. Авыл. Кич. Тынлык. Әхмәт белән парлашып киләбез, ә рәшәткә читенә басып, ул – Галим җырлый...

Аксыл күлмәкләр тектердем,
Үлчәтеп буйларыма.
Уйладым, ирешә алмадым,
Уйлаган уйларыма...

Ул җырлый, мин елыйм. Юк, мин түгел, йөрәк елый, тик акыл гына боера: «Сабыр бул!» – ди. Түздем. Галим дә тормышлы булды, авылдагы иң чибәр кызны үзенә яр итте, ул үстерделәр. Без дә яши бирдек, тик озакка түгел. Кайгы мине тәмам үз итеп өлгерде бугай, янәдән ишеккә килде.

Кеше язмышы сынаулардан гыйбарәт, бигрәк тә хатын-кыз ниләр генә күрми.

Ирем ындыр табагы мөдире булып эшли иде, яла яктылар аңа. Бер ялгыз карчыкка, ярты капчык икмәк китерүдә гаепләделәр – 7 ел төрмә! Гаеплеләр дә табылды югыйсә. Суд булган көнне яхшы хәтерлим. Әхмәт китте, ә мин көне буе кер удым, үзем уам, үзем елыйм. Җәяүләп район үзәгенә барырга җыендым, ә кайнана җибәрми: «Эш күп өйдә, кичкә кайтарырлар әле үзен», – ди. Күпме көтсәк тә, ул кайтмады...

Икенче көн иртән, район үзәгенә киттем, сорашам, ә аны инде озатканнар, карар чыккан. Каравылчы миңа эндәшә: «Кызыл чалбар кигән, чабаталы бер ир кичкә кадәр кемнедер көтте, чыга да карый, чыга да карый!» Өч яшеннән әтисез калып, тормышның ачысын-төчесен татыган, 14 яшендә мөһаҗирлеккә чыгып китәргә мәҗбүр булган Әхмәтне генә түгел, мине дә билгесезлек, газап, ялгызлык утына ташлап сынады язмыш. Төрмәдән Әхмәт хат салды: «Сиңа ике үтенечем бар: балага узып калган булсаң, зинһар, төшертә күрмә. Ничек кенә авыр булса да, төп йорттан мин кайтканчы китмә!»

Әлеге сүзләрнең соңгысына каенсеңелләр каршы булды: «Абый югында артык кашык булып яшәмә!» Көндем, инде бергә яшәргә чыдап булмый башлагач, әниләргә кайтырга карар кылдым: күздә яшь, ә карынымда бер гөнаһсыз бала... Озата чыктылар. Саубуллаштык. Күңел әрнеп елый, сиздермәскә тырышам. Ике йорт чамасы үттемме икән, каенсеңелләр елаша ук башладылар: «Кайт!» – диләр. Соңлап булса да, хәлемә керделәр, ахрысы, тик мин инде кире борылмадым.

Кыз бала таптым. Кендек әбисе сорый:

– Кайсы авыр, балам, тулгак тотумы, ир китүме?

– Ир китү...

Ике айлык чагы иде, баламны әниләр белән өйдә калдырып, чишмәгә киттем, ә мин кайтканчы ул җан биргән иде. Бусы иң ачы хәсрәт иде! Бала хәсрәтен күрергә язмасын...

«Туган йортта». М. Хаҗиев эше.

PRESSA.RU

Әхмәтнең кайткан көнен яхшы хәтерлим: бар авыл халкы болынлыкка чыгып каршылады аны. Нахакка рәнҗетелүе көн кебек ачык иде бит. Тынлык. Болын буйлап бер ялгыз ир кайтып килә. Нахак яла ягылган, кыерсытылган ир. Исәнләште. Хатын-кызлар елый. Аның урынына утырырга тиешле өч ир-ат та бар арада. Әхмәт сүз башлады:

– Йә, ничек, братлар, кемдә булды гаеп: миндәме, сездәме?

– Бездә иде шул гаеп...

Сүзләр артык иде монда. Әхмәт, горур атлап, өйгә таба китте.

Матур яшәдек без. Бер ул, бер кыз үстердек, Аллага шөкер, чын кеше итеп тәрбияли алдык балаларны. Әхмәт телгә оста иде, бәйрәм саен миңа багышлап җыр җырлар иде:

Йөгерә-йөгерә тота алмадым,
Күлдә йөзгән үрдәкне.
Гомеремдә дә оныта алмамын,
Синнән күргән хөрмәтне.

«Яраларны вакыт төзәтә, диләр...» Син калдырган яра гына нишләптер төзәлергә ашыкмый, һаман яңару эзли.

Авыр чаклар да күп булгандыр, әмма, шөкер, кайнана белән тату яшәдек без. Каенсеңелләрне бер-бер артлы кияүгә биреп, бергәләп туйлар иттек. Бианамны да ахыргы көнгә кадәр үзем тәрбияләп, соңгы юлга озаттым.

Инде тормышлар җайланды гына дигәндә, бертуган апам югалды. Дүрт бертуган кыз идек без. Иң олысы – Зөһрә апа. Арабызда иң уңганы, иң чибәре. Тик нигәдер, тормышка чыгарга гына насыйп булмады аңа. Без гаиләле булгангадыр инде гомер буе кимсенде, бичара. Төпчек энекәшебез белән төп йортта яшәп калды. Тик энекәшебез өйләнү белән апабызга йортта көн бетте. Авыл читендәге ялгыз өйгә чыгып яшәргә мәҗбүр булды. Бу хәлне күреп җан әрнеде, йөрәк үксеп елады... Төн чыгарга курыкмасын дип, бик еш кунарга бара идем. Әллә ялгызлык ачысы, әллә язмыш шаяруы, апабыз төнлә урманга чыгып китеп адаша.

Дүрт көн, дүрт төн эзләдек без аны. Кышка авышкан көндә, Зөһрә апабыз күлмәкчән килеш, кара урман туфрагын тырнап, агач төбендә җан биргән. Аның агарган йөзе, куркып зурайган күзләре күз алдыннан китми».

Кинәт син тынып калдың... Күз яшьләреңне инде тыя алмыйсын, җаның белән елыйсың...

Мин тиз генә сиңа елыштым. Аңлатып бетерә алмаслык җылылык, татар әбиләренә генә хас булган нур бар синдә. Сүзеңне дәвам итәсең, ачылы-төчеле, сикәлтәле тормыш юлыңны сөйлисең...

Менә шулай икәүдән-икәү серләшкән чакларыбызга көн дә әйләнеп кайтам мин. Җанга рәхәт чаклар, файдалы киңәшләр, үгет-нәсыйхәтләр, өйрәнелгән яңадан-яңа догалар. Ничә яшькә җитсәк тә, без, оныкларың, синең өчен мәңге бала булып калдык. Инде буй җитеп, югары уку йортларына укырга кердек, ә син һаман да безнең кайтканны сагынып көтеп тора идең. Киткән чакта капка баганасына сөялеп, догалар пышылдап, озата калдың.

Май башы. Кинәт телефон шалтырый: «Әбиең авырып китте, врач дәштек». Бар балаларың җыелды ул чакта. Шул мәлдә син, уйчан карашыңны безгә төбәп, җыр көйләдең:

Зиратта ике мичкә,
Ватып ягыйк бер мичкә.
Ziratka киткәннәрне
Кайтармыйлар бер кичкә.

Сыкрап чыккан күңел авазың иде әлеге җырда. Соңгы көннәр яшәвеңне дә сиздең бугай. Үз хәлең хәл, ә син килененә эндәшәсең:

– Намазым кала, ничекләр укыйм икән?

– Борчылма инде, әни, терелгәч җыеп укырсың.

– Киткәч, җавап бирәсем бар бит...

– Яткан килеш укы, әни, догаларың гына.

Ризалаштың, ахрысы, баш селкедең, ә үзең пышылдап дога сүзләрен кабатлыйсың. Кинәт тагын көйли башладың:

Атымның дагасы алтын,
Дагасын салдырмагыз.
Әрвахларны искә алганда,
Мине дә калдырмагыз.

Син көйлисең, без елыйбыз. Юк, без, балаларың, оныкларың гына түгел, бар табигать елады ул көннәрдә. Дөрес, соңгы арада синең хәлең бераз җиңеләеп киткәндәй булды. Миңа больницага китәргә туры килде, син мине үз аягыңда озата чыктың:

– Кызым, син озаккамы?

– Юк, әби, кайгырма, тиз әйләнеп кайтырмын.

Тиз генә кайтырга насыйп булмады шул, ун көн вакыт үтте. Мин больницадан чыктым, ә син җан бирдең... Җир убылды бугай, яшәү бер мәлгә тукталгандай булды. Тормыш мәгънәсен югалттым. Дөньядагы иң гадел, иң газиз кешем юк булды... Синең алда бер үкенечем калды, тиешенчә кочып, рәхмәт әйтә белмәдем бугай. Соңгы юлга озатырга да килә алмадым, гафу ит, зинһар! Начар хәтерлим мин ул көнне: «Карынында баласы бар, күрсә – чыдый алмас!» – дигән сүзләрен хәтерлим, калганы томан эчендә. Кичкырын, бераз җайлаша төштем, кайттым. Туп-туры бүлмәңә юнәлдем: урының буш...

Юк, урының, бүлмәң, син яшәгән йорт кына түгел, бар дөнья буш калды хәзер синсез. Өстәлеңдә шомырт чәчкәләре. Синең истәлегең. Синең күңелең сыман ап-ак чәчкәләр...

Казан



НУРМӨХӘММӘТОВА Раушания

Казан дәүләт университеты (1992)

Кияүдә, бер бала анасы.

Карьера:

Казан федераль университеты, гомуми һәм төрки тел белеме кафедрасы доценты.

Тормыш шигаре: «Эшең дә, сүзең дә, гамәлең дә берәүгә дә авырлык китермәсен».

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Халык мәдәнияте тарихы – ризыкларында

Кытайдан, Өремчедән килгән студент – Өмет исемле уйгур егете укый миндә. Мәдәниятләрен бөртекләп саклый торган халык алар! Былтыр студентларның йомгаклау конференциясендә уйгур ризыклары турында татарча сөйләде. Быел татар һәм уйгур халкында ашау культурасы белән бәйле үзенчәлекләрне өйрәнде. Уйгурларда нанның (икмәк) 90 лап төре бар ди. Татар ягы сай – ак ипи дә кара ипи... Үзем эзләнә башладым. Таптым! Күәс чиләген кырып җыйган камырдан ипи ризыгы – игәрче пешергәннәр, мәсәлән.


Гыйбрәт алыйм дигәннәргә...

«Ана теле» онлайн дәресләрен өченче ел алып барабыз. Татар телен өйрәнергә теләүчеләрнең географиясе шаккаттыра. Бернард Монот (Испания) илче булып торган. Рус, төрек, гарәп, испан, француз телен белә, инде менә татарча өйрәнә. Елена Зимина (Иваново) узган ел Казанга да килеп китте, институтта булды. Марат Хәкимов Лондонда яши һәм эшли. Тумышы белән Ригадан. Әтисе – Кыргызстанда туып-үскән татар, әнисе – белорус. Әтисе татар телен начар белә, Маратка исә 17 яшендә татар теленнән репетитор яллаган. Марат һаман белемен арттыра.


Безгә тылмач кирәкми!

Казакъстанда, төрки дөньяны өйрәнүгә багышланган Халыкара симпозиумда катнаштым. Казакълар аны үз телләрендә генә алып барды. Алай икән... Кайттым да, төне буе докладымны татарчага тәрҗемә иттем. Чыгышымнан соң кыргыз һәм төрек профессорлары, монгол телләре өйрәнүче бер кыз сорау бирделәр. Туган телемне аңлап утыруларын күрү җанга шундый рәхәт булды... Ярый әле татарча сөйләдем дип куандым!

сөендерде









көендерде

сөендерде








көендерде

сөендерде



көендерде

Табуы җиңел, саклавы авыр

Яңа гына «Студентлар язы» булып узды. Безнекеләр белән бер көнне булачак журналистлар да чыгыш ясады. Аларның «Услышь» дигән композициясе уйландырды: эш, тормыш мәшәкатьләре белән моңарчы аралашып яшәгән кешеләребезне югалтабыз, диде алар. Артка карадым да... миндә дә шул хәл! Элеккеге кебек бер-береңә кунакка йөрү, утырып сөйләшүләрне онытып барабыз. Аралашу – телефон аша... Дуслыкны саклар өчен дә күп көч кирәк шул. Ә югалтканны инде тергезү бик авыр.

Мөнәсәбәт гаиләдә башлана

Туган көнгә барган идем. Бер әни: «Шул проклятый татар теле аркасында балам бу чиректә «отличница» булмады», – ди. Үзе татар, ире татар! Ә туган теле – «проклятый»! Шөкер, кызыбыз Айзилә татарча сөйләшә... Телләр язмышы турында лекциям бар минем. Студентларга әйтәм: «Телләр саны бүген 6 мең чамасы. Берничә елдан уннан бере генә калачак, диләр. Шул 60 тел арасында туган телебез булырмы, юкмы?!» Булдырасылары килә, билгеле. Туган телне саклау юллары күп икәнен белсәләр дә, кызганыч, файдаланмыйлар...

Һәлакәткә бер адым

2050 елда Җир йөзендә ачлык көтелә. Телевизордан яңгыраган бу хәбәр мине генә сискәндермәгәндер... Сәбәбе дә билгеле – без ризыкны бик күп исраф иткәнгә килеп чыгачак икән бу хәл. Мин ризык атамаларын өйрәнү белән шөгыльләнәм. Ризыкны әрәм итүдән бик куркам. Бер генә ипи телемен дә ташлаганым юк! Сыңар алма, сыңар кишерне... Кошларга чыгарырлык ризык та артып калганы юк бездә. Бәлки, бу темага керешүем дә шушының белән бәйледер. Фараз гына дисәк тә, халык шундый зур бит бу сүздә. Күпләр аны кисәтү дип кабул итсә икән.

PRESSA.RU

16+

ВАК-ТӨЯКТӘ ЧИГЕНӘ БЕЛ!



Рәшит МИНҺАҖ,
журналист.
өйләнгән;
гаилә стажы — 15 ел;
ике бала атасы.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызда нәрсәгә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Кайда ничек бит. Урамда – атлап йөрешенә. Ничек язган әле Дәрдмәнд: ымтылган иләк кебек йөрешләре, дигәнме?! Автобуста – кулларына, бармакларына. Гадәттә, куллар кеше турында бик күпне сөйли.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Күп сөйләшүен, күп көлүен... Билгеле инде, үзеңне яраткан һәм бик бәйләнми, йөдәтми генә шуны сиздереп торган, сөйкемле сөягә булган затларның шактый кимчелегенә күз йомыла.

3 Ә нәрсә өчен Сез бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Шарт фигыльне яратып бетермим. Нинди вазгыятьтә нәрсә эшләячәген адәм баласы кайдан белеп бетерсен?!

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручылар...

– Алиһә – гарәп теленнән кергән, мәҗүсилектән калган гыйбарә. Бәлкем, матриархат заманында кулланылгандыр. Ислам динендә хатын-кыз Алла юк. Дөрес, татар шигъриятендә бу сүз очрый. Әмма шагыйрьләр үзләре дә алиһәләргә ышанып бетми дип беләм. Шуңа күрә безне – татар ирләрен – хуҗабикәләр илһамландыра. Аннан килеп, ни генә дисәләр дә, ир-ат йөрәгенә юл барыбер ашказаны аша.

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Хатынга гына сөйләп була ала торган яки дуслар белән генә уртаклашырга мөмкин булган серләр бар. Ә кайбер серләреңне хатынга да, дусларга да сөйләргә ярамый. Йөзгә кызыллык китерерлек кырын гамәл булса, ачылмавың бигрәк тә хәерле. Чөнки хәерсез эшне искә төшерү, сөйләп йөрү шуны арттыру, ишәйтү сыман килеп чыга. Аны йөрәккә күмүең, онытуың мәгъкулрәк.
Ир белән хатын – бер бөтеннең ике яртысы ул, дигән гыйбарә белән дә килешеп бетмим. Бер-береңә бөтенләй ачылып бетсәң, ни кызыгы кала?! Аннан соң берәү бөтенләй ачылып бетә икән, ярыннан да, гадәттә, шуны көтә. Тегесенең ачыласы килмәсә, монысы үпкәли.

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганны хәтерлисезме?

– Без аның белән троллейбуста таныштык. Беренче күрүдә үк ошады миңа Гүзәлия. Әмма исемен әйтмәде. Ә мин аптыратмадым. Бәйләнчек булырга да ярамый бит. «Ярый, мин сине озакламый барыбер күрәчәкмен», – дип төшеп калдым. Чынлап та, бер атна да үтмәде, тагын очраштык. Бу юлы исемен дә, телефонын да белдем инде... Ялгышмасам, өченче күрешүдә үк тәкъдим ясадым. Әмма без шактый елдан соң гына кавыштык. Төрле сәбәпләре булгандыр инде... Һәрхәлдә, хатын: «Хәзер кая китте синең көнчеллегең?!» – дип аптырый.

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый, диләр, шулаймы?

– Бик үк дөрес гыйбарә түгелдер бу – әниеңә өйләнеп булмый бит инде. Миңа калса, әниләре хуҗа булган гаиләдә үскән ир-атлар шулай эшли. Ир-ат булгач та, аларга әни ышыгын алыштыра алырлык кеше кирәк. Шуңа күрә алар яшь кызларга түгел, үзләреннән олырак, дөнья күргән (баласы булса да ярый дип), тәҗрибәлерәк затларга өйләнә.

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Баш бирмәскә, күбрәк акча эшләргә тырышырга! Инде мал табулар килеп чыкмый икән, һичьюгы өйгә

вакытында кайтырга, хуҗалык эшләрендә күбрәк ярдәм итәргә тиештер.

9 Гашыйк булуын хатын-кыз үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Егет җебегәнрәк булса, хатын-кызга тагын нишләргә кала?! Әмма мин хатын-кызның гашыйк булуын үзе башлап белдерүенә тискәре карыйм. Әйе, миңа да килеп мәхәббәт аңлатканнары булды. Андый вакытта, уйлыйм әле, дисең, бәйләнүне дәвам итсәләр, бөтенләй качу, югалу ягын карыйсың. Ир-ат аучы бит ул, ошаганын үзе яулап алырга тиеш, ә монда сине «эләктермәкчеләр»...

10 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип санныйсыз?

– Буй-сыны, хатын-кызга мөгамәләсе. Өс-баш һәм аяк киеме дип әйтүчеләр дә бар. Хәзер инде машинасы нинди маркалы, кесәсе калынмы, фатиры бармы дип карый башладылар бугай.

11 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүен көтәсез?

– Бу хакта уйлап караганым юк... Гомумән алганда, киңәш сорап килсәләр, күңелле инде: тәҗрибә, белем, зәвык та бар сыман.

12 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта.

– Артык чибәр, көчле зат икән, дип, сүз катырга кыенсынып йөргән чаклар булмады бугай... «Чибәр хатын-кыз – кантур ишеге кебек: һәркем килеп ябышырга тырыша», – дип әйтә бер дустым. Билгеле, акыллы хатыннар белән саграк булырга тырышасың. Тик чибәр дә, акыллы да булганнары сирәк, минемчә.

13 Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар. Алар, сезнеңчә, бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?

– Хатын-кыз, гадәттә, уратып-уратып уйлый. Ир-ат исә кирәген күп вакыт турыдан ярып әйтә. Урау юллар эзләп тормый. Хатын-кыз аннан соң, шуны да белмәде, сизмәде, күрмәде, игътибар итмәде, дип үпкәләп йөри. Гүзәлия дә еш кына: «Чәчемне төзәткән идем, яңа күлмәк алдым бит: күрмисең дә», – дип битәрли. Бер яктан караганда, мондый игътибарсызлык зур бәла түгел шикелле. Икенче яктан караганда, журналист кешенең күзәтүчәнлеге, төпченүчәнлеге канга сеңгән булырга тиеш тә бит... Тик өйгә кайткач, һөнәри сыйфатлар ял итә, күрәсең.

14 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңлаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен, үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Хатын-кыз белән ир-ат арасындагы аермадырмы, төрле тәрбия нәтиҗәсеме, белмим: аш-су бүлмәсенә керүгә, телевизорны сүндереп куям. Сез ашаганны шайтан ашый бит, дип орышып та алам. Минемчә, аш-су бүлмәсендә, гомумән, телевизор булмаска тиеш. Өйдәгеләрнең моның белән килешәсе килми. Бәһиҗәтелҗинан әбиебез: «Хәерче тәрәзә төбе саен ипи тезеп чыга да, шуннан барып алып ашамаса, тамагы туймый икән, тиләнчеләрдән үрнәк алмагыз, йөреп ашамагыз», – дип өйрәтте безне. Шуңа күрә компьютер янында чәй эчкәннәрен күрсәм дә кисәтү ясамый калмыйм.

15 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный...

– Мондый очракта дәшми калуың хәерлерәк. Сүз озынга китәчәк. Иң әйбәте: ризалашкан булып, үзеңчә эшләп куюың. Билгеле, мин-минлеккә тия башласалар, дәшми калып булмый. Французлар, вак-төяктә чигенә бел, төп-мөһим нәрсәләрдә баш бирмә, дисәләр дә, килешүе кыен. Тормыш, нигездә, вак-төяктән тора шул.

16 Шундый очракны күзаллыйк әле: арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин арыдым, дип, диванда кырын ятып тора.

– Пешерә башлаган юк инде анысы... Суыткычтан нәрсә дә булса алып, тамак ялгап алу ягын карыйсың. Эш бит, эштә ни булмас дисең. Бөтен кеше дә арый, талчыга.

17 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...

– Шул чагында мин кулыма китап алам... Портфельдә укылмаган күпме гәҗит җыелган. Вакыт җиткереп булмый.

18 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Хатыннан ниндидер бүләк көткәнем юк югын. Әле менә февраль аенда: «Син «Эхо Москвы»ны тыңларга яратасың, юлда уңайлы», – дип, кечкенә генә радио бүләк итте. Гомумән алганда, бүләккә исем китми. Гадәттә, Гүзәлия: «Сиңа килешергә тиеш», – дип, күлмәк ала. Элек үзенә дә күлмәкләр алгалый идем. Әмма ошаганын табу кыен. Аннан килеп Казан кибетләрендә озын итәкле һәм матур гына тегелгән күлмәкләр юк дәрәҗәсендә аз. Итәге өстерәлеп йөри торган, капчык шикелләләрен саталар сатуын, тик андыен аласы килми. Әле бит ул аңа ярыймы-юкмы?! Әмма Гүзәлия ошамаган чакта да сиздерми. Һәрхәлдә, ачыктан-ачык, ошамый дип әйткәне юк. Күлмәк дигәннән. Согудиядән кайтышлый, Мәдинә шәһәре кибетләрендә йөргәндә бер кызыклы хәл булды. Бер сәфәрдәшебезнең хатынына күлмәк сайлавына тап булган идем. Гәүдәсе минем төслерәк, дип, киеп-киеп карый бу. Ат башы хәтле алтын бирәбез дисәләр дә, хатын-кыз күлмәге киеп карамас идем мин. Яраса – ярый инде, ярамаса – сата яки берәрсенә бүләк итә. Иң мөһиме: бүләк белән кайтуың. Ә бүләк алып кайтырга яратам!

PRESSA.RU

Һәр яңалык — ул бик нык онытылган борынгылык, диләр. Әле кайчан гына музейда яки сәхнәдә генә күрергә мөмкин булган калфак, изү, чулпы, читек кебек борынгы милли киемнәребезне хәзер япь-яшь кенә кызлар заманча кием белән яраклаштырып, рәхәтләнеп киеп йөри. Шундый килешә үзләренә! Борынгы үрнәкләр белән тегелгән мондый милли киемнәрне әлегә кибетләрдән сатып алып булмый, аны тегә белгән осталар да санаулы гына. «Хатын-кыз галәме» рубрикасының бүгенге кунагы Рамилә ГАЙНЕТДИНОВА — әнә шул санаулы осталарның берсе. Ул Казан шәһәренең халык сәнгате һөнәрләре техникумында кисү-тегү серләренә өйрәтә. Алтын куллы кыз ничә калфак чиккәнен, ничә изү теккәнен инде хәтерләми дә. Мөгаен, йөзгә туладыр. Ә ул теккән күлмәкләр! Ә чигүле пәлтәләр! Чулпылар, алкалар, хәситәләр, билбаулар, кушаклар... Җитмеш һөнәр егет кешегә генә фарыз димәгез, безнең Рамилә кебек җитмеш кенә түгел, җиде йөз җитмеш җиде һөнәр белгән кызларыбыз да бар. Бүгенге мастер-класста ул безне җиңел генә кулдан изү тегәргә өйрәтәчәк. Бу изүне бертөсле генә тукымадан тегелгән теләсә кайсы күлмәк яки водолазка белән кияргә мөмкин. Башкалардан аерып, үзенчәлекле итеп күрсәтәчәк ул сезне.



ИЗҮЛӘРЕМ ЧИГҮЛЕ







Кирәк:

- буе – 30 см, иңе 50 см булган тукыма. Без көлсу тукыма алдык. Ул күп төсләргә килешә;
- шул ук зурлыктагы дублерин;
- пайетка һәм сәйләннәрдән тезелгән әзер аппликация (кибетләрдә бар). Аппликация урынына изүне чигәргә, ташлар һәм тәңкәләр белән бизәргә мөмкин – монысына инде фантазия һәм рәссамлык сәләте дә кирәк;
- тукыма төсенә ярашлы тегү җебе;
- көмешсыман тар тасма (киңлеге – 8 мм).

Эш барышы:

■ Изүнең формасы (түгәрәкме, шакмаклымы, өчпочмакмы яки безнеке кебек – почмаклары йомрылаҥып килгән формадамы) бизәктән чыгып билгеләнә. Тукыманы кисәргә керешкәнче бизәк сайлана. Аны интернеттан да табарга мөмкин, китаплардан карарга, сәләтең булса, үзең ясарга... Без исә эшне күпкә җиңеләйттек: кибеттән әзер аппликация сатып алдык, бу очракта башка төрле бизәк өстәү, ташлар, сәйләннәр беркетү ихтыяҗы юк.

■ Өстәлгә бер катлап җәелгән тукыма өстенә аппликацияне тигезләп куеп, тукымага акбур белән бизәкнең контурын төшерәбез. Мөһим әйбер: контур бизәктән бераз читкәрәк китеп сызыла, ягъни бизәк изүнең читенә үк терәлеп тормый, бераз ара калдырыла. Безнең очракта кырыйлардан 3 см, аскы һәм өске яктан 4 см ара бар. Акбур эзеннән соң 1 см чамасы тегү өлеше калдырырга онытмыйбыз.

■ Кул белән сызып, симметрияне саклау кыен. Изүнең формасы тигез











булсын өчен, тукыманы урталай бөкләп, ике читен дә бер эздән тигезләп кисәбез. Монысы изүнең өске ягы булды. Нәкъ шушы ук зурлыкта, шушы ук тукымадан изүнең аскы ягын да кисәргә кирәк.

■ Ике катлы тукымадан гына тексәк, изү юка була, рәвешен сакламый. Шуңа күрә аның өске катына ике кат дублерин ябыштырыла. Ул да нәкъ изү формасында киселә. Аны тукымага ябыштыру тәртибе түбәндәгечә: үтүкләү тактасына тукыманы сул ягы белән өскә каратып салып, өстенә бер кат дублерин куябыз һәм дымлы чүпрәк аша кайнар үтүк белән бастырабыз. Аннары шуның өстенә үк тагын бер кат дублерин ябыштырыла. Дублеринны тукымага кытыршы ягы белән ябыштырырга кирәк.

■ Дублерин ябыштырганнан соң, изүгә бизәкнең үзен тегәбез. Тегәргә керешкәнче аны тукымага чукмарбашлы энәләр белән беркетеп куярга кирәк булыр. Югыйсә урыныннан күчеп, авыш итеп тегелергә мөмкин. Бизәк кулдан гына тегелә. Әгәр дә термоаппликация дигәненен алсагыз, аны кайнар үтүк белән ябыштырып кына да куеп була. Шулай да энәҗеп белән тегеп кую ышанычлырак. Пөхтә итеп тегәргә тырышыгыз – җөй уң яктан күренергә тиеш түгел.

■ Хәзер безгә изүнең өске ягы белән аскы ягын бергә тегеп тоташтырырга кирәк. Аларны бер-берсенә уң яклары белән каратып, кырыйдан машина җөе салып чыгабыз. Өске яктан 10 см араны текми калдырабыз. Анысы – уң якка әйләндерү өчен.

■ Кулга үткен кайчы алып, изүнең өске почмагындагы тегү өлешен кыйгачлап кисеп алабыз. Түгәрәкләнеп килгән урыннарында кисемнәр (надсечкалар) ясыйбыз һәм тегү өлешен 3-5 мм чамасы гына калдырып, артыгын кисеп алабыз. Уң ягына әйләндергәч, калын булып күпереп тормасын өчен эшләнә бу.

■ Изүне уң ягына әйләндереп, кырыйларын ныгытып тигезлибез. Аны яхшылап үтүкләргә дә кирәк булачак. Ә үтүкләргә керешкәнче аскы һәм өске якларны тигезләп, кырыйдан гына кул белән типчеп чыгабыз. Бу җөй изүне үтүкләгән вакытта аскы һәм өске яклар берберсенә тигез ятсын өчен хезмәт итә. Үтүкләп бетергәннән соң аны сүтеп алабыз.

■ Изү тирәли көмеш сыман тасма тегеп чыгабыз. Ул да күренми торган җөй белән кулдан гына тегелә. Игътибарлы булыгыз: җөегез изүнең аскы ягына чыгарга тиеш түгел. Муенга бәйләү өчен тасма очлары озынрак итеп калдырыла (38-40 см).

PRESSA.RU

НАРШӘРАБЛЫ КУЫРМА

«Сөембикә»нең бүгенге кунагы — җырчы ДиләНИГЪМӘТУЛЛИНА. Мари Иленең Бәрәңге районында туып-үскән кыз мәктәптә укыганда ук «Ак җилкәннәр» ансамблендә җырлап йөрсә дә, икътисад белгечлеген сайлый. Әмма язмыш аны барыбер дә иҗат дөньясына кайтара. Тормышындагы зур борылыш уйламаганда гына була: бәрхет тавышлы чибәр кызны Казанга — «Ягымлы яз» конкурсына җибәрәләр... һәм ул анда беренче урынны яулый. Мари дәүләт университетының беренче курсын тәмамлаган Дилә, ике уйлап тормый, документларын алып Казанга юл тота. Бүген инде Дилә Нигъмәтуллина исемен ишетмәгән кеше юктыр. Талантлы җырчыбыз аш-суга да бик оста. «Мин беркайчан да тәм-томны кибеттән сатып алмыйм. Вакытым никадәр генә аз булмасын, барысын да үзем пешерәм. Әле менә кичә генә кызымның туган көне иде, бик тәмле торт пешердем», — дип каршы алды ул безне. Бүгенге мастер-класста танылган җырчыбыз анар соусында маринадланган бәрән ите пешерергә өйрәтәчәк. Бу соус бәрән итенә генә түгел, сыер, тавык итенә дә килешә.



Кирәк:

- 1 кг бәрән ите;
- 2 зур помидор;
- 4-5 тырнак сарымсак;
- 4 аш кашыгы анар (гранат) соусы (наршәраб);
- бөбрия (розмарин), кинза;
- 1 кузак ачы борыч;
- 1-2 уч анар төше;
- ярты бал кашыгы лимон суты;
- зәйтүн мае (көнбагыш мае да ярый);
- тәменчә тоз-борыч.








Эш барышы:

■ бәрән итен зуррак кисәкләргә турап, табакка бушатабыз. Кабыгы әрчелгән помидорны изеп, ит янына салабыз. Шунда ук 3 аш кашыгы зәйтүн мае, изелгән сарымсак, тоз-борыч, 4 аш кашыгы наршәраб (азрак яки кимрәк тә була ала, кем ничек ярата бит) һәм лимон суты өстибез. Бәбрия белән кинзаны да турап салырга онытмыйбыз. Кинза белән саграк булыгыз: аның тәме көчле һәм ул кайсыбер кешегә ошап та бетми. Зәһәр борычны исә турамый гына салабыз.

■ Итне тәмләткечләр белән катнаштырып, бер төнгә суыткычка куябыз – яхшылап маринадлансын.

■ Хуш ис бөркеп торган итне үләннәрдән арындырып, үсемлек маенда кыздырабыз. Һәр ягы да кызаргач, калган маринадны өстибез. Үләннәрне алып ташласагыз да була, алар инде үз тәмен иткә биргән. Телгән кеше үләннәрне дә сала ала, әмма кинза тәме бик нык сизеләчәк.

■ Капкач каплап, ит әзер булганчы томалап пешерәбез. Пешеп җитәрәк бер-ике уч анар төше сибәбез. Сүндерер алдыннан тагын бер тапкыр тозын тикшереп карау зыян итмәс, аз булса, өстәргә кирәк булыр. Берәр кашык наршәраб өстәргә мөмкин, ул иткә әчкелтем баллы – искиткеч тәм һәм каракучкылт матур төс бирә.

■ Итне яшелчә белән ашарга кирәк. Шуны истә тотып, тиз генә яшелчәләр пешереп алыйк. Кемгә нинди яшелчә ошый, шуны пешерсен, без исә ташкабак, баллы борыч, бәрәңге әзерлибез. Ташкабакны юып, юка гына итеп буйга теләбез, баллы борычны зуррак кисәкләргә бүләбез, кабыгы чистартылган бәрәңгене тәгәрмәчләп турыйбыз да, барысын бергә кушып, төменчә тоз һәм кара борыч өстибез.

■ Витаминнары югалмасын өчен аларны мичтә генә пешерәбез. Моның өчен коры табага фольга җәеп, яшелчәләрне бер кат итеп кенә тезәбез. Һәрберсенең өстенә яртышар бал кашыгы сары май салып чыгабыз. Сары май булмаса, атланмай салырга мөмкин. 180 градуслы кайнар мичтә алар 40 минут чамасы пешә.

■ Зур тәлинкә тирәли пешкән яшелчәләрне тезеп, уртага ит кисәкләрен куябыз. Ит өстенә анар орлыклары сибеп, аштәмләткеч үләннәр белән бизибез һәм кайнар килеш табынга чыгарабыз.

Наршәраб

Беренче ысул

Өлгергән анарны берничә җирдән тишкәләп, кул белән кысып сутын сыгабыз да бер сәгать буе талгын утта кайнатабыз. Сүндерергә 5 минут кала, кара борыч өстибез. Әзер соусны пыяла савытка агызып, суыткычта саклыйбыз.

Икенче ысул

Анар орлыкларын эмаль савытка салып, тукмак белән төябез һәм сүрән утка куеп, төшләре агарганчы пешерәбез. Аннары сутны иләк аша сөзеп, кибет каймагы кебек булганчы кайнатабыз. Төбе тиз көеп китүчән, гел болгатып торырга кирәк.



PRESSA.RU

Безнең якта физалисны үстерүчеләр әлегә сирәк. Шулай да бу җимеш бакчаларда үз урынын яулый бара. Шулай булмыйча соң, һәрберсенең эченә берәр кояш яшеренгән алтынсу сары кыңгыраулар (сортына карап, аның кызгылт сарысы да була) бакчага ямь өсти, көз көне тәмле җимешләре белән сөендерә.



КОЯШ ТӨЙМӘЛӘРЕ

Физалисның берничә төре бар – декоратив (анысын ашамыйлар), яшелчә физалис, баллы физалис. Яшелчә физалисны икенче төрле Мексика физалисы дип тә йөртәләр. Бакчадан гына өзеп ашау өчен тәме әллә нәрсә түгел, ә менә тозласаң, маринадласаң, кайнатмасын ясасаң, телеңне йотарлык була. Баллы сортлары шул көе генә дә ашарга тәмле.

Урта полосада физалис уҗымга чәчеп үстерелә (яшелчә физалисны май башында туфракка гына да чәчүчеләр бар икән). Түтәлгә чыгарып утыртканда уҗымнар 50 көнлек булырга тиеш. Май кыраулары узгач утыртырга уйласагыз, орлыкларны апрель урталарында чәчәргә кирәк. Шытымнар бер атнадан күренә башлый. Бер ай дигәндә инде алар түтәлгә чыгарып утыртырлык булып өлгереп җитә. Уҗымнар суны сирәк, ләкин мул итеп сипкәнне ярата.

Түтәлгә күчереп утырту эшенә кичке якта яки болытлы көнне тотынсаң яхшы. Физалис әче туфракларны яратмый. Әгәр дә туфрак әчерәк булса, аңа бераз известь кертәләр. Узган ел кыяр, кәбестә үскән түтәлләргә утыртсагыз, уңарсыз. Физалис кояшлы җирдә иркенләп үсәргә ярата: рәт аралары 70 см, рәттәге үсемлек аралары 50 см булсын. Аны бәйләргә дә, артык ботакларын өзәргә дә кирәкми.

Кибетләрдә физалисның күптөрле сортлары бар. Шулай да Грибовский яшелчәчелек станциясендә чыккан сортлар безнең җирлектә үстерү өчен яхшырак җайлашкан.

Чылатылган физалис

Җимешләрне кузагыннан арындырып, кайнар су белән юалар – җилеме калмасын! Парландырылган пыяла банкаларга тутырып, өстеннән тозлык коялар һәм өстенә йөк бастырып бер атна-атнадан артык булмә температурасында тоталар. Аннары банкаларны полиэтилен капкач белән каплап, суыткычка куялар. Тагын бер айдан ашарга ярый. Тозлык өчен 1 л су, 35 г шикәр, 10 г тоз алына.

Маринадланган физалис

Юылган физалисны 1 минутка кайнап торган суга чумырып пешеклиләр. Аннары суытып, ярты литрлы банкаларга тутыралар. Банка төбенә дарчин, канәфер, хуш исле борыч, дәфнә яфрагы салып калдыралар. Физалис өстеннән кайнар маринад коеп, су «мунчасында» 10 минут кайнаталар һәм калай капкач белән томалыйлар. Маринад өчен 1 л су, 50 г шикәр комы, 40 г тоз, 30 г аш серкәсе алына.

Физалистан кайнатма

Әйбәтләп юылган һәм җилеменнән арындырылган физалисны 2-3 минут кайнар суда пешеклиләр дә, табакка бушатып, өстеннән кайнар ширбәт коялар. 1 кг физалиска 610 г шикәр комы һәм 610 г су алына. Шушы ширбәттә 3 сәгать тоткач, 1 кг физалиска 500 г нисбәтеннән тагын шикәр комы өстәп, утка куялар. Кайнап чыккач, утны кысып, 10 минут чамасы пешерәләр. Аннары утны сүндереп, 10 сәгать тоталар. Икенче тапкыр утка куеп, тәмам өзер булганчы кайнатып бетерәләр. Кайнатманы парландырылган пыяла банкаларга тутырып, калай капкач белән каплыйлар.


КУЧКАР. Тормышның яңа этабы башлана. Ният, хыялларыгызны тормышка ашыру өчен җай чыгачак. Уйламаган җирдән керем көтелә. Үзегезне бөтенләй дә белмәгән яктан ачарсыз.


ҮГЕЗБОЗАУ. Язның соңгы ае яңа вакыйгалар белән истә калыр, мөгаен. Ниятләгән эшләрегезнең барып чыгуы тирә-юньдәгеләрнең тырышлыгына бәйле булачак. Моңарчы «йокымсырап» яткан энтузиазмыгыз уяныр, теләсәгез, таулар күчерә алырсыз.


ИГЕЗӘКЛӘР. Йә язмыш – сезне, йә сез язмышны үзгәртәчәксез. Айның беренче яртысында тормышыгызны үзгәртердәй вакыйга көтелә. Уңыш сезнең якта, тәвәккәлләр отачак. Иң мөһиме: булачак авырлыклардан куркып калмау.


КЫСЛА. Үзегезне тиешенчә бәяләмәүчеләрнең «борынына чиертү» өчен менә дигән форсат чыгар. Рухи көчегез артыр, моңа кадәр тотынырга куркып торган эшләрегез булса, һич икеләнмичә тотыныгыз.


АРЫСЛАН. Күңелегездә зилзилә купса да, эшләрегез бик уңышлы барыр. Һөнәри өлкәдә яңа үрләр яуларсыз, ихтирам казанырсыз. Киләчәктә бик тә файдалы булачак кеше белән танышырсыз.


СӨМБЕЛӘ. Көчегез, гайрәтегез ташып тора. Эшне дөрес оештыра белүегез, үҗәтлегегез карьерагызны ныгытырга ярдәм итәр. Җитәкчелек куйган таләпләрне тиешенчә башкарып, үзегезгә карата булган фикерне үзгәртә алырсыз.


БИЗМӘН. Игътибар үзәгендә булырсыз. Хезмәттәшләрегезнең генә түгел, моңа кадәр сезне дошман күреп йөргән кешеләрнең дә дустанә мөнәсәбәтен яуларсыз. Җаныгызда бәхет хисе өстенлек итәр, башкаларга ярдәм итү теләге уяныр.


ЧАЯН. Ыгы-зыгылы булса да, эштә зур уңышлар вәгъдә итә торган ай. Эчке сиземләвегез шулкадәр көчле ки, нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар булуын бик тиз абайларсыз. Шәхси тормышыгызда яхшы үзгәрешләр көтелә.


УКЧЫ. Көчле холкыгызны һәм ихтыяр көчегезне күрсәтергә туры килер. Кирәксә үҗәт тә була алуыгызны расларсыз. Әмма чамадан тыш зур амбицияләрегез үзегезгә үк комачауларга мөмкин.


КӘҖӘМӨГЕЗ. Көтелмәгән вакыйгаларга бай ай. Тормышта яңа кыйммәтләр табарсыз, бу исә күп нәрсәгә фәлсәфи карарга ярдәм итәр. Күптәннән борчып йөргән проблеманы җиңел генә хәл итү мөмкинлеге килеп чыгар.


СУКОЯР. Бөтенесенә өлгерерсез – көчегез мулдан. Тыныч, ипле саналган Сукоярларга кайсыбер очракта холыкларын да сиздереп алырга туры килер. Аның каруы, нәтиҗәсе шунда ук күренер. Яңа эш табуыгыз ихтимал.


БАЛЫК. Бөтенесен үз кулыгызга алу теләге көчле булыр. Берсеннән-берсе яхшырак идеяләр туар. Әмма вакыйгаларны ашыктырмый тору хәерлерәк. Эчке сиземләвегез уңышка ирешергә ярдәм итәчәк. Гаиләгезгә күбрәк игътибар бирегез.

апрель дә кабынган йолдызлар

Татарстан



Мәрьям АРСЛАНОВА (8.04.1926) – **диктор, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.**

Кемерово өлкәсенең Сарсаз авылында туа. Әтисе Казанга укырга киткән җиреннән башкага өйләнә. Олы кызын алырга кайткач, аларга биш яшьлек Мәрьям дә ияреп. 1937 елда әтиләре кулга алынып, Мәрьям кабат әнисе янына кайта. Сугыш башлангач, заводта эшли. 1945 елны Казанга килеп, театр училищесына секретарь-машинистка булып урнаша. Берочтан шунда укый да. Икенче курста аларга талантлы, чибәр егет – Айрат Арсланов килеп кушыла. 1949 елда укуны тәмамлап, Айрат кызны үзләренә Сабантуйга чакыра. Егетнең әти-әнисе шул кайтудан аларга никах та укытып куя. 1963 елдан 1982 елга кадәр Мәрьям Арсланова Татарстан радиосында диктор булып эшли. Озак еллар «Тел күрке – сүз» тапшыруын алып бара.

Россия



Мария СКВОРЦОВА (4.04.1911–1.12.2000) – **актриса**

Тула өлкәсендә туа. Абыйлары янында Мәскәүдә үсә. Кечкенәдән чиркәү хорына йөрсә дә, буем кыска дип, сәхнәгә чыгарга ояла. Шулай да язмыш аңа сәхнә тормышы юллый. 1930 елда дус кызына ияреп кенә Бөтенсоюз радиокомитетына кастингка килә һәм радиокомитет каршындагы курсларга кабул ителә. Сугыштан соң Царицынодагы Яшь тамашачы театрында эшли. Зур экранга тәүге тапкыр 62 яшендә генә чыга: В. Шукшинның «Кызыл балан» фильмында уйный. «Әкияттә кунакта», «Ералаш» чыгарылышлары аша да таныш.

Чит илләр



Шарлотта БРОНТЕ (21.04.1816–31.03.1855) – **язучы.**

Бөекбританиядә алты балалы гаиләдә туа. Әниләре яшьли үлә. Рухани әтиләре кызларын дини мәктәпкә укырга бирә. Ике апасы шушында үпкә чире йоктырып, гүр иясе була. Шарлотта һәм аның туганнары кечкенәдән шигырьләр яза. Шарлотта ул шигырьләрне китап итеп бастырып чыгара. Тагын бер елдан романнар җыентыгы дөнья күрә. Бу җыентыкка аның – «Учитель», сеңелләре Эмилинең – «Грозовой перевал», Энн Бронтеның «Агнес Грэй» романнары керә. 1847 елда Шарлотта «Джейн Эйр» романын тәмамлый. Соңгы әсәре – «Шерли» романы вафатына санаулы гына көннәр калганда язылып бетә. Шарлотта Бронте 39 яшендә, йөклелегенең соңгы аенда үпкә чиреннән вафат була.

PRESSA.RU



ШӘҖӘРӘ

Төрки халыкларда нәсел-нәсәбеңне барлау – борын-борыннан килә торган гадәт. Юк, гадәт кенә түгел – изге бер йола бу. Кадерләп, берәмтекләп төзелгән нәсел агачын төрки халыклар шәҗәрә, диләр.

Лира Сөләйманның сәнгать дөньясына аяк басуы да нәкъ менә шуңа – шәҗәрәгә бәйле. Аның гади генә тарихы да бар. Тормыш иптәше Ринатның әтисе – Лираның кайнатасы олы юбилеена әзерләнә. Менә шул юбилейга килене белән улы эксклюзив бүләк әзерлиләр – Сөләймановлар ыруының нәсел агачын ясыйлар. Аны эшләү өчен дә гадәти булмаган материал сайлана. Үзләре генә белгән ысул белән агачны һәм пергаментны эшкәртеп, фәкать табигый буяулар гына кулланып ясалган ул шәҗәрә яңа авторлык технологияләренең башлангычы була да инде.

Хәзерге көндә исеме иҗатчылар арасында шактый нык танылып өлгергән Лира ханым «Сөләйман» исемле остаханә ачып җибәргәннән соң, иҗатының алга таба нинди юнәлеш алачагын да ачыклап куя. Моңа кадәр үзен Европа косметика чараларын тарату, аннары йорт җиһазларын бизәкләү, ягъни декор юнәлешләрендә сынап караган, декор эшенә зур осталардан өйрәнгән Лира Сөләйман агач материалын чын-чынлап яратып китә.

Мебель фабрикасы эшләп чыгарган игезәк йорт җиһазларын гына күреп үскән совет балаларына шкаф-өстәлләрне, диван-сервантларны кабатланмас һәм бердәнбер итеп бизәү сәер дә тоела торгандыр. Ә менә Лира Сөләйман – шул сәерлекне сәнгать итүгә ирешкән сирәк осталарның берсе.


Агачның табигый фактурасын фольклор мотивлары белән бизәп җибәргәч, сак кына итеп буяу төсмерләре өстәгәч, могҗиза туа икәнен белә ул. Шул матурлыкка агачны уеп, чокып төшерелгән бизәкләр дә өстәп җибәрсәң, кешеләрнең өйләренә яңа җиһаз белән бергә бәйрәм керәсен көт тә тор! Кыйммәтле агачларны эшкәртүнең гасырлардан килгән сере бар. Аларны белсә дә, музыка уен коралларын ясаучылар гына нечкәләп белә торгандыр. «Сөләйман» остаханәсендә шул нечкәлекләрне янәдән барлап, инде бүтән юнәлештә – шәҗәрәләр, шәмаилләр ясау, язу юнәлешендә дә файдаланып карыйлар. Чыннан да, моңа кадәр пыялага, кәгазьгә ясалган изге сүзләр хасиятләп эшкәртелгән пергамент һәм агач йөзенә төшкәч, гел бүтәнчә, борынгыдан ук килгән әманәт кебек кабул ителә башлыйлар икән. Әнә шул рәвешле аның остаханәсендә пергамент ясау кебек безнең эрага кадәр үк гамәлдә булган һөнәр тергезелә. Пергамент ул беренче китап сүзе язылган гаҗәеп чыдам һәм озын гомерле материал. Аны кәгазь дип кенә аңлау тамырдан хата. Пергамент вак терлек тиреләрен нечкәләп эшкәртү юлы белән ясала. Лира Сөләйманның пергаментка төшерелгән шәмаилләре, шәҗәрәләре аңа танылу да китерде. Ул – «Ислам дөньясы сәнгате» фестиваленең икенче дәрәҗә көмеш медале иясе. Уңышлар рухландыра. Хәзер Лира Сөләйман танылган татар шәхесләренең шәҗәрәләре сериясен булдыру хыялы белән дәртләнеп йөри. Бу ниятен тормышка ашыру өчен ул хәзер архивлардан, мәчетләрдән, музейлардан кайтып керми. Шулай итеп, үткәнгә, ягъни тарихка юнәлтелгән хезмәте аның үзен алга, югарыга әйди.

Рәмзия КАШАПОВА















ЛИРА СӨЛӘЙМАН

PRESSA.RU

1 апрельдән 2016 елның икенче яртыеллыгы өчен газета-журналларга язылу башланды



ИГЪТИБАР!
«Сөембикә» журналының индексы үзгәрде

«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча
ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ЯҢА ИНДЕКСЫ П2204



ТАШЛАМАЛЫ БӘЯДӘН ЯЗЫЛЫРГА АШЫГЫГЫЗ!

Татарстаннан читтә яшәүчеләр әлегә «Роспечать» каталогындагы элеккеге индекс буенча языла алалар: 73002

Журналыбызга онлайн режимда :
http://podpiska.pochta.ru сайтында (регистрация узып) яки безнең сайтыбызның онлайн язылу бүлегендә дә язылырга мөмкин



Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була.
iPad һәм iPhone кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала.
Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була (www.syuyumbike.ru).

16+